***Казан (Идел буе) федераль университеты***
***Журналистика һәм социология факультеты***
***Татар журналистикасы кафедрасы***

# Р.Л.Зәйни

# Журналистиканың хокукый нигезләре

***Уку ярдәмлеге***

УДК 070

*«Казан (Идел буе) федераль университеты»*
*журналистика һәм социология факультетының*
*методик комиссиясе (протокол №4, 2011 елның 10 марты)*
*һәм татар журналистикасы кафедрасы (протокол №8, 2011 елның 2 феврале)*
*карарлары буенча басыла*

*Фәнни редактор*
филология фәннәре докторы, проф. В.З.Гарифуллин

*Рецензентлар:*
филология фәннәре кандидаты Фәттахов И.Ф.
филология фәннәре кандидаты Галиәхмәтова А.Ф.

"Журналистиканың хокукый нигезләре" курсы, фундаменталь университет белеме бирүнең бер өлеше буларак, журналистика белгечлеге һәм юнәлеше студентлары өчен уку планында каралган. Әлеге уку ярдәмлеге массакүләм мәгълүмат чараларын хокукый яктан көйләүнең төп аспектларын үз эченә ала. Лекцияләр өчен материаллар дисциплина программасы, әдәбият исемлеге, семинар дәресләр өчен сораулар, биремнәр, шулай ук белешмә аппарат белән баетылган.

Югары уку йортларының журналистика факультетлары һәм бүлекләре студентлары, журналистлар өчен адреслана.

© Казанский университет, 2011
© Зайни Р.Л., 2011

# Эчтәлек

**Кереш** ........................................................................................... **4**
I бүлек. Курсны өйрәнү барышында эшне оештыруның формалары, алымнары һәм методлары ........................................... 6
II бүлек. “Журналистның хокукый нигезләре” курсы программасы.....9
*Төп әдәбият* ............................................................... 12
*Өстәмә әдәбият* .......................................................... 13
*Имтихан өчен сораулар* ................................................. 15
III бүлек. Журналистиканың хокукый нигезләре. Лекцияләр һәм практик дәресләр өчен материаллар ........................................... 18
*1 нче тема. Россиядә массакүләм мәгълүмат хокукының барлыкка килүе һәм үсеше*................................................ 18
*2 нче тема. Массакүләм мәгълүмат чараларын оештыруга таләпләр* ............................................................... 31
*3 нче тема. Журналист һәм мәгълүмат* ........................... 41
*4 нче тема. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм реклама* ........................................................................ 49
*5 нче тема. Матбугат иреге һәм кеше хокукларын яклау* ........................................................................... 55
*6 нчы тема. Журналист хокуклары һәм бурычлары* ........ 76
*7 нче тема. Журналист сайлаулар вакытында* .................. 87
*8 нче тема. Журналист һәм авторлык хокукы* .................. 96
IV бүлек. Мөстәкыйль эш формалары ........................................ 103
*Реферат темалары* ......................................................... 103
*Массакүләм мәгълүмат чараларына кагылышлы законнардан өземтәләр* .................................................... 104
*Журналистикага кагылышлы хокукый төшенчәләрнең кыскача аңлатмалы сүзлеге* ........................................... 119
*“Журналистиканың хокукый нигезләре” фәненнән белемнәрне тикшерү өчен үрнәк тест сораулары* ........... 123

# Кереш

Без үзебезне хокукый дәүләттә яшибез, дип саныйбыз. Матбугатка бәйле хокукларыбызны тәэмин итәргә тиешле законнар гамәлдә йөри. Аларның беренчесе – Россия Федерациясе Конституциясе. Анда шәхеснең башка төрле хокуклары һәм иреге белән беррәттән, “шәхси тормышының кагылгысызлыгы”, “хат язышу сере хокукы”, “фикер һәм сүз иреге”, “теләсә кайсы законга сыешлы юл белән мәгълүмат эзләү, алу, тапшыру, җитештерү һәм тарату хокукы”, “массакүләм мәгълүмат иреге” гарантияләнә. Бер үк вакытта Конституциядә кайбер төр ирекләрне чикләү дә бар. Мисал өчен, “аерым кешенең шәхси тормышы турындагы мәгълүматларны аның рөхсәтеннән башка җыю, саклау, файдалану һәм тарату”, “мәҗбүриләп кемнән дә булса фикерен һәм ышануларын әйттертү яки алардан баш тартырга үгетләү” тыела. Төп Закондагы бу гарантияләр һәм тыюларның журналист һәм аудитория, журналист һәм материалларның геройлары, журналист һәм хакимият органнары арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләүгә, җайга салуга кертә торган өлеше зур. Моннан тыш, массакүләм мәгълүмат чараларының эшчәнлеген көйләү процессында Гражданлык һәм Җинаять кодекслары да катнаша. Һәм, әлбәттә, төп урынны РФнең “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” Законы алып тора.

Менә шул саналып киткән законнар журналистлар өчен төп хокукый таләпләрне билгели дә инде. "Журналистиканың хокукый нигезләре" дигән курсны өйрәнү барышында ул законнарның журналист һөнәренә кагылышлы маддәләре өйрәнелә, аларны үтәү яки үтәмәүдән килеп чыгарга мөмкин булган нәтиҗәләр тикшерелә, конкрет мисалларга тукталына.

"Журналистиканың хокукый нигезләре" курсы, фундаменталь университет белеме бирүнең бер өлеше буларак, журналистика белгечлеге һәм юнәлеше студентлары өчен уку планында каралган.

Әлеге курсның **максаты** һәм **бурычлары** – массакүләм-мәгълүмати хокукның үзенчәлеген һәм ролен ачыклау. Әлеге максат ул хокукны массакүләм мәгълүмат чараларын барлыкка китерү, тарату һәм материалларын куллану барышында барлыкка килә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, редакторлар һәм журналистларның һөнәри эшчәнлекләрен, массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую, эшләтү һәм ябуны тәртипкә салучы нормалар берлеге буларак

күзаллау барышында тормышка ашырыла. Гомумиләштереп әйткәндә, максат массакүләм мәгълүмат өлкәсендәге хокук принциплары һәм нормаларын студентлар тарафыннан комплекслы рәвештә үзләштерүгә ирешүдән гыйбарәт.

Курсны үзләштеру барышында гомуми мәгълүмати хокукның бер өлеше дә, шул ук вакытта үзе аерым мөстәкыйль өлкә дә буларак, массакүләм мәгълүмати хокукның эчтәлеген ачу; студентларда массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлеге өлкәсендәге хокукый мөнәсәбәтләрне көйләүче  Россия законнарының юнәлеше, характеры, эчтәлеге һәм үзенчәлекләре турында тулаем күзаллау тудыру; массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге хокукый мөнәсәбәтләрне көйләүче нормаларның эчке бәйләнешен ачу күз алдында тотыла.

Максатка ирешү һәм бурычларны үтәү барышында, рус телендәге берничә китап-дәреслек белән беррәттән, әлеге уку ярдәмлеге дә хезмәт итәр. Курс **бакалаврлар** әзерләү планы буенча алып барылганда, аны үзләштерү ахырына студентларга аерым таләпләр куела.

“Журналистның хокукый нигезләре” дисциплинасын өйрәнү процессы түбәндәге **компетенцияләрне** формалаштыруга юнәлдерелгән: хокукның демократик җәмгыятьтә тоткан урынын аңлау, Россиядә массакүләм мәгълүмат чараларының эшчәнлеген тәэмин итүче халыкара хокук нигезләрен һәм хокукый нормаларны, шул исәптән, журналистның хокукларын һәм бурычларын, авторлык хокукын белү (дәүләт стандарты буенча ОК-6, ОК-7, ОК-14, ПК-11 пунктлар).

Курсны өйрәнү ахырында **студент**:

- массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы халыкара хокук нигезләре, Россиядә массакүләм мәгълүмат чараларының эшчәнлеге, журналистның хокуклары һәм бурычлары, авторлык хокукын көйләүче хокук нормалары буенча  **белемле булырга**;
- хокукый культурага **ия булырга**, хокукый белемнәрен редакциядә эшләү вакытында **куллана белергә**, гражданнарны кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итү барышында үзенең һөнәри хокукларын куллану һәм яклау, җәмгыять тормышында хокукның өстенлеген пропагандалау **күнекмәләренә ия булырга тиеш**.

Курс проблемалары буенча студентлар реферат, курс эшләре яза. Курс имтихан белән тәгәлләнә.

# I бүлек. Курсны өйрәнү барышында эшне оештыруның формалары, алымнары һәм методлары

**Лекция** – укытуның бер методы, укыту процессының төп формаларының берсе. Ул укыту процессында кулланыла торган башка чаралардан иң алда килә һәм яңа уку материалын актуальләштерү өчен хезмәт итә.

“Журналистның хокукый нигезләре” курсы буенча укыла торган лекцияләр дисциплина буенча белемнәр формалаштыра, фәнни материалны дәлилләп аңлатырга өйрәтә, һөнәри белемнәр һәм гомуми культура дәрәҗәсен формалаштыра һәм үстерә, әлегә кадәр дәреслекләрдә һәм уку ярдәмлекләрендә басылып чыкмаган материал белән тәэмин итә.

Лекциянең функцияләре:

- мәгълүмати;
- юнәлеш бирүче;
- тәрбияви.

Лекцияләрнең нәтиҗәлелеген үстерү өчен түбәндәге моментларны үтәү мөһим:

- дәрес башында теманың һәм дәреснең структурасын ачык һәм анык күрсәтү;
- һәр бүлектә материалны бертигез бүлеп җиткерү;
- лекция барышында гади, аңлаешлы, мисаллар һәм чагыштырулар белән баетылган образлы тел куллану;
- күрсәтмә материаллар, схема, таблицалар куллану;
- материалны аңларга ярдәм итә торган риторик яки төгәлләүче сораулар кую;
- укытуның техник чараларына мөрәҗәгать итү.

Лекцияләрнең темалары укыту программалары һәм занятиеләрнең тематик планы буенча ачыклана.

Лекциянең планы эш программасының эчтәлегенә туры килергә һәм аны ачарга, ә лекцияләрнең эчтәлеге уку вакыты кысаларына сыярга тиеш.

Лекция башында алдагы лекция эчтәлеге буенча кыскача күзәтү ясалса яхшы. Болай эшләү мәгълүматның озак вакытлы хәтергә сеңеп калуына һәм уку курсын системалы рәвештә кабул итүгә ярдәм итә.

Әлеге күзәтүне студентлардан телдән яки язма рәвештә сорауларга җавап бирү формасында да уздырырга мөмкин.

Яңа материалны аңлата башлар алдыннан, лекциянең планын бирү, бу материалның аңа кадәр булган яки соңрак буласы темалар белән бәйләнешен күрсәтү, аның иң әһәмиятле аспектларына игътибарны бирү мөһим. Интригага корылган сорау бирү яки бик кызыклы мисал китерү студентларның игътибарын үзенә юнәлтәчәк.

Студентлар лекцияне тыңлап кына калмый, аның эчтәлеген конспектлап та бара. Төп төшенчәләр, идея, тезисларны тактага язып куярга яки проектор аша күрсәтергә дә мөмкин. Болай эшләү материалны үзләштерергә дә ярдәм итә, конспектлауны дә җиңеләйтә, терминнарны хаталы язуны кисәтә. Ә төп кагыйдәләр, нормаларны әйтеп яздыру кирәк.

**<u>Семинар дәресләр</u>** – аерым бүлек материалын үзләштерүне төгәлләүче звено, комплекслы укыту формасы, ягъни укытучы һәм студентларның чыгышлары белән алып барыла. Семинар дәресләренең үзенчәлеге шунда ки, бу вакытта һәр студент та тикшерелә торган сорауны ачыклауда тигез хокукта актив катнаша ала.

Семинар дәреснең функцияләре:

- дисциплинаның аерым бер бүлеген тирәнрәк үзләштерергә ярдәм итү, белемнәрне ныгыту;
- аналитик фикерләргә, гомумиләштерергә, нәтиҗәләр чыгарырга өйрәтү;
- фәнни гыйлемнәрне практикада куллану күнекмәләре бирү;
- тикшерелә торган мәсьәләләр буенча кыска, дәлилле һәм ачык итеп фикер әйтергә өйрәнү.

Семинар дәрес – ул фикер алышу. Ул укытучының кереш сүзеннән башлана, анда укытучы тикшереләчәк теманың әлеге дисциплина системасында нинди урын алып торганлыгын, әһәмиятен аңлата. Шуннан соң сорауларга җавап бирү башлана. Сөйләшүнең ахыры укытучының йомгаклау сүзе белән төгәлләнә.

Уку төркеме кысаларында үткәрелгән семинар дәресләр тикшерелә торган проблемаларда барлык студентларга да катнашырга мөмкинлек бирә. Укытучының максаты – пассив студентларны да игътибардан читтә калдырмау, өстәмә сораулар ярдәмендә фикер алышуга кушылырга этәрү.

Фәнни проблеманы тикшерү белгәнне сөйләп чыгуга, мәгълүмат алмашуга гына әйләнеп калмаска тиеш. Студентлар мәсьәләгә карата үз фикерләрен белдерергә өйрәнергә тиеш.

Семинар вакытында укытучы һәм студентлар төрле ярдәмче кулланмалардан файдалана ала, алар исемлегенә китаплар, дәреслекләр, газет-журналлардан кисеп алынган материаллар, аудио-, видеоматериаллар, интернет сайтлары керә.

Семинар дәреснең нәтиҗәле узуы укытучының проблеманы чишү процессын оештыру белү осталыгына, барлык студентларны да фикер алышуга катнаштыра белүенә бәйле. Катнашучылар составы, студентларның дәрескә әзерлек дәрәҗәсе, лекция материалы гына түгел, тәкъдим ителгән уку ярдәмлекләре, дәреслекләр һәм фәнни әдәбиятны үзләштерү дәрәҗәләре дә семинарның уңышлы узуына ярдәм итә.

Эчтәлеккә кире кайтырга!

## II бүлек. “Журналистның хокукый нигезләре” курсы программасы

| Темалар һәм аларның төп эчтәлеге | көндезге уку бүлеге | читтән торып уку бүлеге |
|---|---|---|
| ***1 нче тема. Россиядә массакүләм мәгълүмат хокукының барлыкка килүе һәм үсеше***<br>Журналистика эшчәнлегенең хокукый нигезләре. Матбугат иреге һәм кеше хокукын саклау. Сүз ирегенең хокукый яктан рәсмиләшүе. Массакүләм мәгълүмат чараларының җәмгыятьтә тоткан хокукый урыны. Россия Федерациясенең “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” законы. Аның төп положениеләре. Закондагы төп төшенчәләр.<br>Матбугат турындагы законнар. Россиядә “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” законның бәхәсле урыннары. Яңа закон проектлары. Алар өчен хас сыйфатлар. | 2 (лекц.) | 1(лекц.) |
| ***2 нче тема. Массакүләм мәгълүмат чараларын оештыруга таләпләр***<br>ММЧ оештыруның хокукый нормалары. Гамәлгә кую хокукына ия булу. ММЧны гамәлгә кую механизмы. Теркәү органнары. Теркәү өчен әзерләнә торган документлар. Текрәүгә каршы килү очраклары.<br>ММЧ эшчәнлеген билгеләүче редакция уставлары һәм башка документлар. Гамәлгә куючы һәм редакция коллективы. Редакция һәм техник хезмәткәрләр. | 2 (лекц.)<br>2 (практ.) | 1(лекц.) |
| ***3 нче тема. Журналист һәм мәгълүмат*** | 4 (лекц.) | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| “Журналист”, “мәгълүмат”, “массакүләм мәгълүмат чарасы” төшенчәләре.<br>Мәгълүмат – хокукара мөнәсәбәтләр объекты. Мәгълүмат төрләре. Мәгълүмат алмашу субъектларының хокукара мөнәсәбәтләре буларак, җәмгыятьтә мәгълүмат җитештерү һәм аннан файдалану. Һәркемгә ачык мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм тарату.<br>Бар кешегә дә ачык булмаган мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм тарату. “Дәүләт сере”, “хезмәт сере”, “тикшерү сере” һәм “суд сере”, “коммерция сере”, “һөнәри сер”, “дин тоту сере”, “гаилә сере”, “яшерен мәгълүмат” төшенчәләре. Хәрби яки дәүләт серен, сату-алуга кагылышлы яшерен мәгълүматны саклау. Дәүләт төзелешен көч кулланып җимерүгә чакыруга, башка җинаять эшләренә карата билгеләнә торган җәзалар.<br>Журналистның (редакцияләрнең) аудитория, хакимият, иҗтимагый оешмалар, реклам бирүчеләр һ.б. белән ике арадагы мөнәсәбәтләрен көйләүче хокукый нормалар. | 4 (практ.) | (лекц.) |
| ***4 нче тема. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм реклама.***<br>“Реклама” төшенчәсе. Рекламаның бурычлары. Массакүләм мәгълүмат чараларындагы рекламга куела торган таләпләр. Россия Федерациясенең “Реклама турындагы” законы. Реклама эшчәнлегенең халыкара кодексы. Рекламага бәйсез экспертиза уздыручы орган - Россиянең реклама буенча иҗтимагый берлеге. | 4 (лекц.), 2 (пр.) | 1 (лекц.) |
| ***5 нче тема. Матбугат иреге һәм кеше хокукларын яклау***<br>Журналистларның закон белән беркетелгән хокуклары һәм бурычлары. Журналист хокуклары. Дәүләт оешмаларында, | 4 (лекц.) 4 (практ.) | 1 (лекц.) |

| | | |
|---|---|---|
| предприятиеләрдә булу хокукы. Техник чаралар кулланып, аудио яки видеоязмалар әзерләү хокукы. Төрле чараларда катнашу хокукы. Яшерен чаралар. Мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм тарату хокукы.<br>Журналистның (редакцияләрнең) басылган материалларының геройлары белән ике арадагы мөнәсәбәтләрен көйләүче хокукый нормалар. Шәхес намусын, абруен саклау. Намус һәм абруй турындагы күзаллауларның тарихи-юридик аңлатмасы. Шәхес хокукларын бозган, гайбәт тараткан һ.б. очраклар өчен суд җаваплылыгы.<br>Журналистикада милләтара килешүчәнлек һәм ызгышлар мәсьәләсе. “Этник журналистика” һәм “этник мәгълүмат” төшенчәләре. Уңай этник мәгълүмат башкарган функцияләр. Массакүләм мәгълүмат чараларындагы этник мәгълүматның ызгыш китереп чыгару мөмкинлекләре. Тискәре этник мәгълүмат. Этник мәгълүматны килешүчән яки ызгышлы итү ысуллары. | | |
| ***6 нчы тема. Журналист хокуклары һәм бурычлары***<br>Журналист хокуклары һәм бурычларының өч төркеме. Журналистның мәгълүмат табу белән бәйле эшчәнлегенә бәйле хокуклары һәм бурычлары. Журналистның мәгълүмат җитештерү һәм массакүләм мәгълүмат чарасын чыгару белән бәйле хокуклары һәм бурычлары. Мәгълүматның дөреслеген тикшерү шарты.<br>Журналистлар өчен аккредитация кагыйдәләре. Хезмәт вазыйфаларын үтәү барышында кулланырга мөмкин булган мәгълүмат каналлары. Массакүләм мәгълүмат иреген кысу очраклары.<br>Журналистлар һәм суд органнары | 4 (лекц.)<br>4 (практ.) | 1 (лекц.) |

| | | |
|---|---|---|
| арасындагы хезмәт мөнәсәбәтләре. Суд таләп иткән материаллар белән таныштыру бурычы. Гаепсезлек шартын саклау. Суд утырышларын яктырту таләпләре. | | |
| ***7 нче тема. Журналист сайлаулар вакытында*** Хакимият органнары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары. Сайлаулар вакытында массакүләм мәгълүмат чаралары һәм журналистлар таяна торган законнар. Сайлау вакытында массакүләм мәгълүмат чараларын классификацияләү. Сайлау алды агитациясе һәм журналистлар. Сайлау кампаниясе һәм журналист хокуклары. Сайлауларга бәйле рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларының хокукын чикләү очраклары. | 2 (лекц.) 2 (практ.) | 1 (лекц.) |
| ***8 нче тема. Журналист һәм авторлык хокукы*** Авторлык хокукларына бәйле законның төп положениеләре. Интеллектуаль хокук төшенчәсе. Интеллектуаль хокук объектлары. Эргәдәш хокуклар – интеллектуаль эшчәнлекнең берничә нәтиҗәгә китергән катлаулы объектларга бәйле хокуклар. Редакциягә килеп кергән материалларга, укучы хатларына карата авторлык хокукы. Авторлык хокукы объекты булмый торган материаллар. | 4 (лекц.) 2 (практ.) | 1 (лекц.) |

## *Төп әдәбият*

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.

### *Өстәмә әдәбият*

Гражданский Кодекс РФ (Часть 4) от 18.12.2006 N 230-ФЗ (принят ГД ФС РФ 24.11.2006) // http://www1.fips.ru/wps/wcm/connect/content_ru/ru/documents/russian_laws/codeks_rf/gkrf_ch4

Воронкова М.А. Гаврилов Э.П. Охрана авторских прав в СССР. М, 1974.

Ворошилов В.В. Журналистика. Учебник. 3-е изд. / В.В.Ворошилов. – С-Пб.: Изд-во Михайлова В.А., 2001.

Батурин Ю.М., Федотов М.А., Энтин В.Л. Закон о СМИ: на перекрестке веков и мнение. – М.: Издание Союза журналистов России, 2004.

Бережной А.Ф. Царская цензура и борьба большевиков за свободу печати (1895-1914) / А.Ф.Бережной. - Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1967.

Временные правила о повременных изданиях. – Казань: Лито-типография И.Н.Харитонова, 1906.

Законадательство и практика средств массовой информации. – Ежемесячный журнал центра “Право и СМИ”.

Законы и практика СМИ в Европе, Америке и Австралии / Пер. с англ.; 2-е изд., испр. и доп. - М.: Права человека, 2000. - С. 160-171, 187-189, 203-205.

Законы о печати. Настольная справочная книга. - М.: Тип-ия Т.Рис, 1873.

Европейский Суд по правам человека и защиты свободы слова в России: прецеденты, анализ, рекомендации. - М.: Институт проблем информационного права. - Т.1, 2002; Т.2, 2004.

Законодательство Российской Федерации о средствах массовой информации: Науч. -практ. комм. проф. М.А. Федотова. М., 1999. С. 480–496.

Как СМИ избежать ответственности за содержание распространяемой им предвыборной информации? Комментарий Центра «Право и СМИ» // ЗиП. 2000. № 12. С. 25–29.

Кравченко Ф.Д. Предвыборная агитация. Вопросы не исчерпаны // ЗиП. 2000. № 1. С. 19–21.

Комментарий к Гражданскому кодексу Российской Федерации (учебно-практический). Части 1, 2, 3, 4 / под ред. Степанова С.А. – М.: Проспект, Институт частного права, 2009 г.

Конституция Российской Федерации. Научно-практический комментарий / Под. ред. Б. Н. Топорнина. 3-е изд. - М.: Юристъ, 2003.

Комментарий к Уголовному кодексу Российской Федерации / Отв. ред. В. М. Лебедев- 3-е изд., доп. и испр.. - М.: Юрайт-издат, 2004.

Комментарий к ФЗ "О средствах массовой информации" // http://prozakon.su/a50?id=33709

Корконосенко С.Г. Основы журналистики: Учебник для вузов / С.Г.Корконосенко. – М.: Аспект Пресс, 2001.

Копылов В. А. Информационное право. Учебник. 2-е изд., перераб. и доп. - М.: Юристъ, 2002.

Кудрявцев М. А. Право СМИ в современной России: проблемы и перспективы // ЗиП. - 1999.- № 3. - С. 11-18.

Моргунова Е.А. Авторское право: учебное пособие / Е.А. Моргунова; отв. ред. В.П. Мозолин. — М.: Норма, 2008.

Липцик Д. Авторское право и смежные права = Droit d'auteur et droit voisins. — Пер. с фр.; Предисл. М.А. Федотова. — М.: Ладомир; Изд-во ЮНЕСКО, 2002.

Обсуждение проектов закона о СМИ. - М.: Институт проблем информационного права, 2003.

Основы права. Учебное пособие для факультетов и отделений журналистики. – Коллектив авторов. Российский фонд правовых реформ. – М.: Правовое просвещение, 1999.

Панкратов Ф.Г. Рекламная деятельность: Учебник для студ. высш. и ср. спец. уч. зав-ий / Ф.Г.Панкратов, Т.К.Серегина, В.Г.Шахурин. – М.: Информационно-внедренческий центр «Маркетин», 1998.

Право на информацию: российское законотворчество о СМИ в 1999-2000 гг. в контексте западноевропейских стандартов свободы слова. - М.: Институт проблем информационного права, 2001. - С. 7-241.

Правовые проблемы индустрии СМИ // ЗиП. -2002.-№ 6. - С. 3-8.

Прохоров Е.П. Введение в теорию журналистики: Учебное пособие / Е.П.Прохоров. – М.: Изд-во РИП-Холдинг, 2002.

Прохоров Е. П. Свобода СМИ и журналистской деятельности на демократических принципах. - М.: Пульс, 2001.

Регистрация средств массовой информации в регионе ОБСЕ / Специальный докладПредставителя ОБСЕ по вопросам свободы СМИ. - Вена, 2006. - http://osce-fom.cjes.ru/docs/?did=7

Русская печать и цензура в прошлом и настоящем. Статьи В.Розенберга и В.Якушкина. – М.: Изд-во М. И С. Собашниковых, 1905.

Рихтер А. Г. Правовые основы журналистики : Хрестоматия. - М.: Институт проблем информационного права, 2004.

Рихтер А . Г. Свобода массовой информации на постсоветском пространстве. - М.: Издательство «ВК», 2007.

Свобода выражения мнений в Европе: Судебная практика применения статьи 10 Европейской конвенции по правам человека. - Страсбург: Совет Европы, 2007.

Свобода самовыражения, свободный поток информации, свобода средств массовой информации: Основные положения СБСЕ/ОБСЕ, 1975-2007. - Вена, 2007.

Судебная палата по информационным спорам при Президенте Российской Федерации: 1994–1996. Нормативные акты. Практика. Комментарии / Под ред. А.Б. Венгерова. М., 1997.

Федотов М. А. Право массовой информации в Российской Федерации. - М.: Междунар. отношения, 2002.

## ***Имтихан өчен сораулар***

1. “Ирек” төшенчәсе һәм аның шартлары.
2. Матбугат иреге һәм кеше хокукын саклау.
3. Сүз ирегенең хокукый яктан рәсмиләшүе.

4. Массакүләм мәгълүмат чараларының җәмгыятьтә тоткан хокукый урыны.
5. Россия Федерациясенең “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” законы. Аның төп положениеләре.
6. “Журналист”, “мәгълүмат”, “массакүләм мәгълүмат чарасы” төшенчәләрен юридик яктан аңлату.
7. Массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую хокукы.
8. ММЧ эшчәнлеген билгеләүче редакция уставлары һәм башка документлар.
9. Гамәлгә куючы һәм редакция коллективы.
10. Мәгълүмат – хокукара мөнәсәбәтләр объекты. Мәгълүмат төрләре.
11. Мәгълүмат алмашу субъектларының хокукара мөнәсәбәтләре буларак, җәмгыятьтә мәгълүмат җитештерү һәм аннан файдалану.
12. Һәркемгә ачык мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм тарату.
13. Бар кешегә дә ачык булмаган мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм тарату.
14. “Дәүләт сере”, “хезмәт сере”, “тикшерү сере” һәм “суд сере”, “коммерция сере”, “һөнәри сер”, “дин тоту сере”, “гаилә сере”, “яшерен мәгълүмат” төшенчәләре.
15. Хәрби яки дәүләт серен, сату-алуга кагылышлы яшерен мәгълүматны саклау.
16. Дәүләт төзелешен көч кулланып җимерүгә чакыруга, башка җинаять эшләренә карата билгеләнә торган җәзалар.
17. “Реклама” төшенчәсе. Рекламаның бурычлары.
18. Массакүләм мәгълүмат чараларындагы рекламага куела торган таләпләр. Россия Федерациясенең “Реклама турындагы” законы.
19. Реклама эшчәнлегенең халыкара кодексы.
20. Рекламага бәйсез экспертиза уздыручы орган - Россиянең реклама буенча иҗтимагый берлеге эшчәнлеге.
21. Журналист хокуклары. Дәүләт оешмаларында, предприятиеләрдә булу хокукы.
22. Техник чаралар кулланып, аудио яки видеоязмалар әзерләү хокукы.
23. Төрле чараларда катнашу хокукы. Яшерен чаралар.
24. Мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм тарату хокукы.
25. Шәхес намусын, абруен саклау.

26. Шәхес хокукларын бозган, гайбәт тараткан һ.б. очраклар өчен суд җаваплылыгы.
27. Журналистикада милләтара килешүчәнлек һәм ызгышлар мәсьәләсе.
28. “Этник журналистика” һәм “этник мәгълүмат” төшенчәләре.
29. Уңай этник мәгълүмат башкарган функцияләр.
30. Массакүләм мәгълүмат чараларындагы этник мәгълүматның ызгыш китереп чыгару мөмкинлекләре.
31. Массакүләм мәгълүмат чаралары сайлаулар вакытында.
32. Сайлаулар алдыннан ММЧларның шартлы төркемнәре һәм аларның эшчәнлеге.
33. Авторлык хокукы. Авторлык хокукларына бәйле законның төп положениеләре.
34. Интеллектуаль хокук төшенчәсе. Интеллектуаль хокук объектлары.
35. Эргәдәш хокуклар.
36. Редакциягә килеп кергән материалларга карата авторлык хокукы.
37. Авторлык хокукы объекты булмый торган материаллар.
38. Плагиат өчен билгеләнгән җаваплылык.
39. Россиядә “Матбугат турындагы” законның бәхәсле урыннары.
40. Яңа закон проектлары.

Эчтәлеккә кире кайтырга!

## III бүлек. Журналистиканың хокукый нигезләре.

## Лекцияләр һәм практик дәресләр өчен материаллар

### *1 нче тема. Россиядә массакүләм мәгълүмат хокукының барлыкка килүе һәм үсеше*

***Беренче рәсми хокукый очраклар.*** Хокукый нормалар Россиядә матбугат белән бергә барлыкка килгән, дип санала. Рус телендәге беренче газета – “Ведомости” өчен әзерләнгән кульъязмалардагы, шулай ук әзер газета кәгазе кырыендагы кайбер язмалар хокукый тыюлар яки рөхсәтләрнең тәүгеләре булган дияргә мөмкинлек бар. Гомумән, әлеге газетаның дөньяга килүе үк хокукый акт нигезендә билгеләнүе белән игътибарга лаек: ул 1702 елның 15 декабрендә Петр I чыгарган указ нигезендә басыла башлаган. Әлеге указда “Мәскәү һәм аның тирәсендәге дәүләтләрдә булган хәрби һәм башка төрле вакыйгалар турында хәбәрләр җыярга һәм бастырып чыгару өчен тиз арада Монастырский приказга китерергә”, – диелгән була. Күрәсең, Петр ул карарны яңа басыла башлаган газета хәбәрләр кытлыгы кичермәсен өчен чыгаргандыр.

XVIII-XIX гасырларда дәүләт матбугатка игътибарын арттырырга мәҗбүр була, чөнки матбугатның җәмгыятьтә тоткан урыны торган саен үсә барган. Норматив актларга охшаш документлар кабул ителә. Әйтик, 1720 елның октябрендә ташка басылган сүзне контрольгә алу максатыннан, газеталарны бастырыр алдыннан цензура тикшерү үткәрелә башлый. Берничә айдан тагын бер документ – Духовная коллегия регламенты – матбугат турындагы Россия законнарының беренчесе кабул ителә. Екатерина II идарә иткән чорда, төгәлрәк булсак, 1783 елны Ирекле типографияләр турында указ кабул ителә. Бу указны тарихчылар Россиянең цензура һәм матбугат турындагы беренче җыелма законы буларак бәяли.

Матбугат турындагы законнарга XIX гасырда аеруча зур игътибар бирелә. Цензура уставы (1804, 1826 һәм 1828 еллар), Цензура буенча вакытлы кагыйдәләр (1862, 1865 һәм 1882 еллар), Вакытлы басмалар турында вакытлы кагыйдәләр (1905 ел), Хәрби цензура турында вакытлы положение (1914 ел) һ.б. документлар үз чорында матбугатка кагылышлы хокукый мәсьәләләрне чишү өчен хезмәт иткән.

Исемнәреннән күренгәнчә, алар хөкүмәт тарафыннан күпчелек очракта тыю, ирекне кысу, цензура максатында кулланылган.

Сүз дә юк, матбугатка кагылышлы законнар Россиядә акрынлап озак еллар буе формалашып килгән. К.А.Арсеньевның 1903 елда Санкт-Петербургта чыккан “Законодательство о печати” дигән китабында барысы 265 бит булуы да ул чакта матбугатка кагылышлы законнарның күптөрлелеге турында сөйли.

***Совет чорындагы матбугат турындагы законнар.*** Шул ике гасыр дәвамында барлыкка килә барган законнар 1917 елның 27 октябрендә Совнарком кабул иткән Матбугат турындагы декрет белән юкка чыгарылды. Әмма бу документның закон белән бертигез мөмкинлекләргә ия булмавын искәртеп китәргә кирәк. Чөнки хокук белгечләре белдерүенчә, аны закон чыгарырга тиешле орган түгел, ә башкарма орган – хөкүмәт чыгарган.

Әлбәттә, Париж коммунасының уңышсызлыкка очрау сәбәпләрнең берсе булып дошман матбугатын юкка чыгармау торганлыгын Ленин яхшы аңлаган, шуңа да әлеге Декретка кул куйган. Әмма Декретның озын гомерле булмаячагына, альтернативасы, каршы фикердә торучылары булмаган матбугатның җәмгыятькә зуррак зыян китерәчәгенә дә төшенмәгән түгел. Шуңа да Декретның ахырында: “Яңа тәртип ныгып китүгә, ... аның өчен (матбугат өчен) иң алдынгы законнар нигезендә, суд тыйганнардан гына тыюлуны таләп итеп, калган яктан тулы ирек урнаштырылачак”, - диелгән була бит.

Әмма журналистларга вәгъдә ителгәнне 73 ел көтәргә туры килде. Закон урынына большевиклар партия цензурасын булдырды. Никадәр генә кызганыч булмасын, соңгы вакытларга кадәр безнең илдә матбугат турындагы законга туарга язмаган. Дөрес, РСФСРның Гражданлык кодексындагы намус һәм дәрәҗәнең кагылгысызлыгы турындагы 7 нче, Җинаять кодексындагы гайбәт, мыскыллау, дәүләт серләрен халыкка тарату, плагиат турындагы 130, 131, 75, 141 нче маддәләрне матбугат һәм матбугат өлкәсендә эшләүчеләр өчен дә кулланырга мөмкин булды булуын, әмма ул маддәләр буенча журналистларга җинаять эше кузгатылган очракларны хокук белгечләре хәтерләми диярлек. Чынлыкта закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятен үз кулында тоткан партия аппараты матбугатны да үз кулына алды, үзенчә җәза бирде, үзенчә аклады.

Дөрес, вакыт-вакыт совет хөкүмәте дә матбугат турындагы законны эшләү белән мавыгып алгалаган. XX гасырның 60 нчы еллар уртасында шул чор өчен ярыйсы гына демократик рухтагы проект та эшләнелә. 1968 елның көзендә аны КПСС Үзәк Комитеты утырышында тикшергән вакытта, шул чорның төп идеологы М.А.Сусловның: "Чехословакиядә цензура бетерү белән совет танклары кертелү арасында нибары берничә ай үтте. Минем шуны беләсем килә, безгә танкларны кем кертер икән?" – диюе җитә кала. Чехословакиядә булган вакыйгалардан коты алынган партия эшлеклеләре проектка катгый каршы чыга.

Тагын бер проект 1976 елны дөньяга килә. Анысы СССР территориясендә Гражданлык һәм сәяси хокуклар буенча халыкара пакт үз көченә керүе белән бәйле. Әлеге проектны шул пактны тормышка ашыруның бер дәлиле итеп күрсәтү максаты белән барлыкка китерәләр дә. "Коммунистик" һәм "совет" сыйфатлары белән шыплап тутырылган әлеге документ кабул ителә калган очракта да мәгълүмат һәм сүз ирекен тәэмин итә алмаган булыр иде. Чөнки даими басмаларны булдыру мөмкинлеге элеккечә партия, дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмаларга гына рөхсәт ителгән, ә мәгълүмат алу хокукы "дәүләт, җәмгыять һәм гражданнарның интереслары" дигән төгәл генә аңлашылмаслык киртәләр белән чикләп куелган. Әмма хәтта шундый гомуми декларацияләрдән генә торган әлеге закон да кабул ителмәгән: ансыз яшәү дә бик уңай әле, дип уйлаучылар соңгы минутта да табылган.

***Гамәлдәге законның барлыкка килү тарихы.*** Үзгәртеп кору башланган гына елларда матбугат турындагы закон законнар төзү планына кертелә, һәм 1986-1987 елларда яңа проект барлыкка килә. Ул да, КПСС Үзәк Комитеты эчендә барлыкка килүе сәбәпле, моннан алдагы проектны кабатлый.

Бу рәсми концепциягә алмаш һәм альтернатива рәвешендә 1988 елның җәендә өч хокук белгече – Ю.М.Батурин, М.А.Федотов һәм В.Л.Энтин тарафыннан тагын бер проект төзелә. Аңа хас булган төп билгеләр цензураның тыюлуы, аерым гражданнарга да массакүләм мәгълүмат чаралары ачу мөмкинлеге бирү, редакцияләрнең һөнәри һәм икътисадый бәйсезлеген тәэмин итү, журналист статусы һәм мәгълүмат алу хокукларын билгеләү, ышанычка нигезләнеп бирелгән мәгълүмат чыганагының исемен ачмау шартыннан гыйбарәт.

Әлбәттә, хакимият әлеге проектны күрмәмешкә салыша, Үзәк Комитет аны рәсми вариантка альтернатива итеп караудан баш тарта, бастырып чыгаруны яшерен ысуллар белән тыя.

Бер сүз белән әйткәндә, цензураны тыючы закон проектын бастырып чыгару өчен иң элек шул цензураны юкка чыгарырга кирәк була! Шунысы коткара: Балтыйк буе республикаларында цензура торган саен йомшара барган вакыт була бу. Эстония Журналистлар берлегендәге шәхси элемтәләргә таянып, эстон телендәге "Спордилехт" дип аталган спорт газетасының 1988 елгы 14 октябрь санында проектны бастырып чыгаралар. Бер атна үтүгә, ул рус телендә "Молодежь Эстонии" газетасында да дөнья күрә. Менә шуннан соң гына проект башка совет газеталары һәм журналларында да басыла.

СССР Халык депутатларының I съездында бу проектны, бер меңнән артык данәдә брошюра итеп бастырып алып кереп, яшерен рәвештә генә тараталар. Шундагы илледән артык журналист-депутат Съезд секретариатына тапшырганнан соң, әлеге проект законлы тәкъдим сыйфатын ала.

1989 елның җәендә СССР Югары Советында матбгугат турындагы закон проекты буенча эшче төркем оештырыла. Яңа законга нигез итеп әнә шул башта тыелган, Эстониядә бастырылып, съездга яшереп алып кереп таратылган авторлык проекты алына.

24 ноябрь Парламент палаталарының берләштерелгән утырышында аны беренче кат уку көне итеп билгеләнә. Әмма бер көн кала, депутатларга тикшерү, үз фикерләрен белдерү һәм тавыш бирү өчен, тышкы яктан шуңа охшаган булса да, чынлыкта бөтенләй башка документ таратыла. Закон проектын эшләүдә катнашкан депутатлар ялганны сизеп алалар. Тавыш куба. Икенче көнне тавыш бирү вакытында парламент бу ялган вариантны кире кагып, эшче төркем проектын бертавыштан диярлек кабул итә. Тавыш бирү нәтиҗәсе түбәндәгечә була: 376 депутат – "әйе", 8 е "каршы" дип җавап бирә, 13 е төгәл генә фикергә килә алмый кала.

Ялган вариантның чыныннан аермасы шул була: анда, беренчедән, үз массакүләм мәгълүмат чараларын булдыра алучылар исемлегеннән аерым гражданнарны сызып ташлыйлар, икенчедән, массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә куючылар һәм нәширләренә редакция эшенә катнашу - материалларны алдан алар белән килешеп кенә бастырып чыгару, кайберләрен тыю, аерым өлешләрен кисеп ату

мөмкинлеге тудырыла. Мондый үзгәрешләр белән документның бөтенләй башка төс алачагы көн кебек ачык була.

Шулай итеп, 1990 елның 12 июнендә СССРның "Матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" Законы кабул ителә, һәм ул 1 августта гамәлгә керә. Һәм шуннан соң акрынлап әлеге закон эшли башлый, моңа кадәр илне аерым кысаларда тотып торган тоталитар системаны җимерү эшенә керешә. Әлеге законнын 7 нче маддәсе массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую хокукын “...халык депутатлары Советы һәм башка дәүләт органнары...” белән беррәттән, сәяси партияләр, иҗтимагый, кооператив, дини оешмалар, хезмәт коллективлары, шулай ук 18 яше тулган СССР гражданнарына да бирә. Әлеге нормаларны башта сагаебрак кабул иткән редакцияләр акрынлап аны эшчәнлектә куллана да башлыйлар. Беренче булып “Октябрь” журналы бәйсезлек ала – аның хезмәт коллективы гамәлгә куючы булып теркәлә. Аның артыннан “Знамя”, “Иностранная литература”, “Волга”, “Дружба народов”, “Юность”, “Огонь” журналлары, “Смена”, “Литературная газета”, “Мегаполис-Экспресс” газеталары да гамәлгә куючыларын үзгәртә.

1991 елның 27 декабрендә бу законга алмашка Россия Федерациясенең "Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" Законы килә. Ул СССР законы нигезендә һәм шул ук авторлар тарафыннан төзелә.

Бу законнарның беренчесе матбугат ирեген игълан итсә, икенчесе инде аны матбугатның гадәти хәле итеп белдерә. Әгәр беренчесендә, мәсәлән, милек, гамәлгә куючы, редакция, нәшир турындагы урыннарында заманына ярашлы рәвештә әйтеп бетермәү, ике төрле аңларлык итеп бирүләр очраса, Россия Федерациясе законы инде ул ак тапларны юкка чыгару юлы белән төзелә. Чынлап та, СССР законы өчен язылып та, үз вакытында кабул ителмәгән урыннар Россия Федерациясе законында кулланылыш таба.

Дөрес, Югары Совет әгъзалары тарафыннан да аңа 79 төзәтү тәкъдим ителеп, шуның 26 сы кабул ителә. Кабул ителер алдыннан, ягъни 1991 елның 19 декабрендә ул тагын берничә үзгәреш кертелүгә дучар ителә. Аларның икесе законның демократик мөмкинлекләрен киметә, матбугат ирегенә янаучы сыйфатын ала.

Төзәтүләрнең беренчесен В.Г.Степанков фамилияле прокурор кертә. "Конфиденциаль мәгълүмат" турындагы 41 нче маддәдә,

тикшерү органнары таләп иткән очракта, мәгълүмат чыганагын күрсәтү шарты турында була ул. Баштагы вариантында журналистның мәгълүмат чыганагын беркемгә дә ачмаска хакы бар, дип билгеләнсә дә, әлеге прокурор тәкъдиме белән маддә үзгәртелә. Бу хәл закон шул маддәсе белән гамәлдәге Җинаять кодексы арасында каршылык килеп чыкмасын өчен, дип аңлатыла. Әмма шуннан алдарак депутатлар, дин хезмәтендәгеләргә мәгълүмат чыганагын ачмау мөмкинлеген биреп, законнан искәрмә ясауларын исәпкә алсак, журналистларга да ул хокукны бирә алган булырлар иде, югыйсә, дигән фикер туа.

Икенче төзәтүне В.Р.Веремчук фамилияле адвокат кертә. Анысы 50 нче маддәдәге яшерен рәвештә аудио- һәм видеоязмалар ясый алу мөмкинлегенә карый. Бу хокук журналистлардан бөтенләй алып ташлана. Монысын төзәтү тәкъдим итүче түбәндәгечә аңлата: хәтта җинаять тикшерүчесе дә сорау алганда җинаятьчедән андый язмалар ясау өчен рөхсәт сораганны, журналистларга андый хокук бирергә ярамый, ди ул.

Бу ике төзәтү дә зур тавыш чыгуга сәбәпче була. Беренче төзәтү аркасында редакцияләрдә тентү уздырулар, журналистларны милициягә һәм прокуратурага чакырулар гадәти хәлгә әйләнәчәк, дип саный күпләр. Ә икенче төзәтү журналистларга бөтенләй дә эшләрлек, эфирга чыгарлык мөмкинлек калдырмый, дигән фикер яңгырый. Чөнки митинг барган вакытта төшереп алынган кадрларны, андагы меңләгән кешенең ризалыгын алмый торып, эфирга чыгарырга ярамый булып чыга бит.

Илдә күтәрелгән тавыш нәтиҗәсендә, бу төзәтүләр кабат карала. Ул көнне башка сораулар да күп булу сәбәпле, утырыш сәгать кичке 9 га якынлашып килгәндә генә әлеге маддәләргә килеп җитәләр. Арган депутатлар бертавыштан диярлек ул төзәтүләрне юкка чыгара һәм проектның беренче вариантын закон итеп кабул итә. 1991 елның 27 декабре була бу. Рәсми төстә басылып чыкканнан соң, 1992 елның 8 февралендә ул үз көченә керде.

***Массакүләм мәгълүмат чараларына кагылышлы яңа закон проектлары.*** Инде шактый еллар эшләүче әлеге законны төптән үзгәртү, реформа үткәрү турында сөйләшүләр алып барылуын да билгеләп китик. Чынлап та, андый сөйләшүләр гамәлдәге закон кабул иткәннең икенче көнендә үк башланган. Сәбәпләре дә аңлашыла кебек. Берәүләргә журналистларга бирелгән ирек артык күләмле булып

тоелса, икенчеләр, киресенчә, закон журналистларның иреген кыса, дип аңлаткан.

Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законны төптән үзгәртүгә юнәлдерелгән беренче адым 1990 еллар уртасында Дәүләт Думасының Мәгълүмати сәясәт буенче дәүләт комитеты тарафыннан ясала. Бу закон проекты тарихка “Депутат проекты” дигән исем белән кереп калган. Аның авторлары гамәлдәге законның базар мөнәсәбәтләренә туры килеп бетмәвен, кайбер маддәләренең Гражданлык кодексы белән каршылыкка керүен тәнкыйтьләгән. Мисал өчен, алар фикеренчә, законда “ММЧның милек иясе” төшенчәсенең булмавы тавыш чыгуга, чишелмәслек мәсьәләләр килеп чыгуга китергән. Шул сәбәпле гамәлгә куючы, редакция һәм нәшир арасындагы милеккә бәйле мөнәсәбәтләр бөтенләй дә көйләнелмәгән.

Төрле үзгәртүләр белән яңа кыяфәт алган закон проекты 1998 елның 14 гыйнварында Дәүләт Думасы утырышында тикшерүгә алынган, әмма, кабул ителмичә, киләсе елның 17 февралендә икенче укылышта кире кагыла. Әмма аның нигезендә Дәүләт Думасы һәм Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы тарафыннан бер-берсенә бик охшаш вариантлар барлыкка килә. Бүгенге көндә инде бу проект белән эшләү туктатылган. Тик белгечләр фикеренчә, ул проект шактый уңышлы дип табыла. Дөрес, аны яңарткан очракта да проектны аннан соңрак кабул ителгән РФ Конституциясе һәм Гражданлык кодексы белән тәңгәлләштерү таләп ителер иде.

Тагын бер проектны “Россия Журналистлар берлеге проекты” дип атыйлар. Ул 2000 елда М.А.Федотов белән Ю.М.Батуринның уртак эшчәнлеге нәтиҗәсендә, исеменнән үк аңлашылганча, Россия Журналистлар берлеге канаты астында барлыкка килә. Максатларының беренчесе ММЧ турындагы законны гамәлдәге башка төп законнар белән тәңгәлләштерү була.

Әлеге проект гамәлгә куючы белән редакция арасындагы мөнәсәбәтләргә бөтенләй башка күзлектән карый. Иң әһәмиятлесе – журналистикага эшкуарлык төре итеп түгел, ә җәмгыять алдындагы бурычны үтәү эшчәнлеге итеп карау гамәлгә керергә тиеш була. Шуңа бәйле рәвештә, хокукый өлкәгә кагылышлы тезарус яңадан карап чыгыла, “нәшир”, “редакция” кебек төп төшенчәләргә яңа аңлатма бирелә.

Бу проект Дәүләт Думасына 2002 елның 4 июлендә кабул ителә. Әмма Россия Хөкүмәте тарафыннан 2003 елның 30 июнендә бирелгән Рәсми бәяләмә һәм шул ук елның 1 декабрендә кул куелган Йомгак әлеге проектның норматив хокукый актлар җавап бирергә тиешле таләпләргә туры килмәве турында хәбәр итә.

Шул вак вакытта тагын бер закон проектының эшләнүе билгеле. 2002 елның 19-20 июне көннәрендә Мәскәүдә "ММЧ үсеше: реформалар юнәлеше" (журналистлар телендә – "индустриаль конференция") дигән чара уза. Аның ахырында Россиянең эре массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләрен берләштергән "ММЧларның индустриаль комитеты" яңа закон проекты өстендә эш башлап җибәрә. 2003 елның 15 апрелендә "индустриаль комитет" аны раслый һәм Парламентка тапшыра. Алга таба проект белән эшләү РФ Президентының Баш дәүләти-хокукый идарәсе белгечләре кулында күчә. Бүгенге көндә әлеге закон проектының язмышы билгесез.

***Массакүләм мәгълүмат чаралары системасына кагылышлы закон актлары.*** "Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" закон кабул ителгән көннән алып, илдә законнар өлкәсе һаман да үсештә яши. Дөрес, формаль рәвештә журналистлар өчен төп булган законның өстенлеге саклана, ягъни ММЧга кагылышлы федераль яки җирле закон актлары аңа каршы килми, ярашырга тырыша. Димәк, ул башка законнарны системада тотучы төп акт. Инде араларында каршылыклар килеп чыккан очракта да бәхәс "Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" закон файдасына чишелергә тиеш.

ММЧларның аерым типларына, төрләренә һәм эшчәнлек өлкәсенә караган бик күп закон актлары кабул ителде. Мәсәлән, 1995-2005 нче елларда гамәлдә булган "Массакүләм мәгълүмат чараларын һәм китап бастыруга дәүләт яклавы турындагы" ("О государственной поддержке средств массовой информации и книгоиздания"), "Район (шәһәр) газеталарын икътисади яклау турындагы" ("Об экономической поддержке районных (городских) газет") законнар бар. ММЧларның статусына кагылышлы таләпләр "Дәүләт сере турындагы" ("О государственной тайне", 1993), "Мәгълүмат, мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны саклау турындагы" ("Об информации, информатизации и защите информации", 1995-2006), "Элемтә турындагы" ("О связи", 2003), "Реклама турындагы" ("О рекламе", 1995), "Таможня тарифлары турындагы" ("О таможенном тарифе", 1993),

“Документларның мәҗбүри данәләре турындагы” (“Об обязательном экземпляре документов”, 1994), “Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау гарантияләре турындагы” (“Об основных гарантиях избирательных прав граждан Российской Федерации”, 1994-1997) һәм аны алмаштырган “Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау һәм референдумда катнашу гарантияләре турындагы” ("Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации", 1997-2002, 2002) законнарда да очрый. Әлбәттә, РФнең Гражданлык, Җинаять эшләре, Административ хокук бозулар турындагы кодексларын да искә алырга кирәк.

Законнардан кала, ММЧларның федераль дәрәҗәдәге статусын Президент, Хөкүмәт, Үзәк сайлау комиссиясе карарлары һәм күрсәтмәләре дә билгели. Федерация субъектлары тарафыннан чыгарылган карарлар бик сирәк күренеш. Аларның да Россия законнары белән каршылыкка кермәскә тиешлеге бәхәссез.

***“Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” Законның төзелеше.*** Гамәлдәге “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” Закон (алга таба кыскартып "ММЧ турындагы" Закон диярбез) 1991 елның 27 декабрендә кабул ителгәннән соң, аңа 1995 елның 13 гыйнвары, 6 июне, 19 июле, 27 декабрендә, 1998 елның 2 мартында, 2000 елның 5 августында, 2001 елның 4 августында, 2002 елның 21 мартында, 25 июлендә, 2003 елның 8 декабрендә, 2004 елның 22 августында, 2005 елның 21 июлендә, 2006 елның 16 октябрендә, 2008 елның 25 декабрендә һәм 2009 елның 9 февралендә кайбер үзгәрешләр кертелгән.

Әлеге Закон барысы 7 бүлектән, 62 маддәдән тора. Алга таба бу маддәләрне ныклап өйрәнергә туры килер, ә хәзергә аларның кыскача эчтәлеге белән танышып чыгыйк.

Беренче бүлек “Төп положениеләр” дип атала. Анда законда кулланылган “массакүләм мәгълүмат”, “массакүләм мәгълүмат чаралары”, “редакция”, “журналист”, “нәшир” кебек төшенчәләргә аңлатма бирелә, массакүләм мәгълүмат чаралары ирекле дип игълан ителә, цензураның, массакүләм мәгълүматны явыз ният белән файдалануның тыюлганлыгы турында сөйләнә.

Икенче бүлек “Массакүләм мәгълүмат чараларының эшчәнлеген оештыру” исеме астында бирелгән. Ул “гамәлгә куючы” төшенчәсенә

аңлатма бирә, массакүләм мәгълүмат чараларын исәпкә алу (регистрацияләү) тәртипләре, гамәлгә куючы, редакция, нәшир статусы, редакция уставы, үзара төзелә торган килешүләргә булган таләпләрне ачыклый.

“Массакүләм мәгълүмат чараларын тарату” дигән өченче бүлектә сүз газета-журналларны бастыруга, радио- һәм телетапшыруларны эфирга чыгаруга куелган таләпләр, массакүләм мәгълүмат чараларында реклам тарату тәртипләре, шулай ук эротик басмалар эшчәнлеге турында бара.

Дүртенче, “Массакүләм мәгълүмат чараларының гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәте” дип аталган бүлек мәгълүмат эзләү, табу, алу шартлары, яшерен мәгълүмат төшенчәсе, массакүләм мәгълүмат чараларында чыккан мәгълүматка каршы җавап бирү хокуклары турында сөйли.

Бишенче бүлек - "Журналистның хокуклары һәм бурычлары" - тулысы белән журналистның хокукый статусын билгели.

Алдагы бүлек “Массакүләм мәгълүмат өлкәсендә дәүләтара хезмәттәшлек” дип атала һәм чит ил массакүләм мәгълүмат чараларының һәм чит ил хәбәрчеләренең Россиядәге хокук һәм бурычлары белән таныштыра.

Җиденче бүлектә исә сүз әлеге законны бозган өчен, әйтик, массакүләм мәгълүмат иреген кыскан яки аны явыз ният белән файдаланган, матди зыян китергән өчен билгеләнергә мөмкин булган җәза төрләре турында бара.

Бүгенге көндә гамәлдә йөргән бу законда күп кенә хокук өлкәсе белгечләре һәм журналистлар заман журналистикасының кайбер бәхәсле очраклары чагылмый, дип саный. Шуңа күрә яңа закон проектлары да төзелә тора.

***Төп төшенчәләр.*** Алдан әйткәнебезчә, гамәлдәге "ММЧ турындагы" Законның беренче бүлеге журналист хезмәтендәге төп төшенчәләргә аңлатма бирә. Иң элек без дә шул төшенчәләрне истә калдырырга тырышырбыз. Аларны белү Закон таләпләрен, хокуклар һәм бурычларны билгеләгәндә кирәк булачак.

*Массакүләм мәгълүмат* - ул чикләнмәгән күләмдәге кешеләр өчен әзерләнеп, кәгазьгә басылган, аудио-, аудиовизуаль яки башка төрле хәбәрләр, материаллар. *Массакүләм мәгълүмат чаралары* дип басма, радио-, теле-, видеопрограмма, кинохроника, массакүләм

мәгълүмат таратучы башка чаралар аталганын сез беләсез инде. Инде аларның һәркайсына законда күрсәтелгәнчә аңлатма бирик.

*Даими басма* дип даими исеме, саннарының тәртип номеры булган һәм елына бер тапкыр булса да дөнья күрүче газета, журнал, альманах, бюллетень яки шундый башка чара атала. Мисалга, бөтен дөньяга таралучы "Комсомольская правда" газетасы да, Мәскәүдәге "Хокук һәм ММЧ" үзәге бастырып килүче "Законодательство и практика средств массовой информации" журналы да, Татарстанда гына түгел, Россия территориясендә яшәүче татарларның яраткан газетасы "Татарстан яшьләре" дә, дайджест газета "Юлдаш" та, "Сөембикә", "Идел" журналлары, безнең факультетта елына 2-3 тапкыр басылучы "Тонус" альманахы да – барысы да периодик басмалар.

*Радио-, теле-, кинохроникаль программа* дигәндә исә елына бер мәртәбә булса да эфирга чыгучы, даими исеме булган периодик аудио-, аудиовизуаль хәбәрләр, материаллар күз алдында тотыла. ТНВ радиоканалындагы "Мәйдан" тапшыруы, "Беренче" телеканалдагы "Время", "Эфир"дагы "Компьютерньюс", ТНТдагы "Битва экстрасенсов" – барысы да радио-, теле-, кинохроникаль программалар рәтенә керә.

Журналистлар һәм техник хезмәткәрләрнең уртак хезмәте белән периодик басма аерым бер тираж белән дөньяга таралгач, радио-, телетапшыру эфирга чыккач, алар инде *массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясе* рәвешен ала. Шул продукцияне сату, абүнәчеләргә яздыртып, почта яки башка хезмәтләр аркылы китертү, заказ буенча китереп бирү, өләшү исә массакүләм мәгълүмат чараларын *тарату* дип атала. Мәсәлән, "Казан утлары" журналын абүнәчеләргә яздырту, "Телесемь" атналык программалар газетасын киоскта сату, телевизордан ТНВ каналыннан "Кара-каршы" ток-шоу программасын күрсәтү, митингта теләгән һәркемгә "Правда" газетасын өләшү – болар барысы да массакүләм мәгълүмат чараларын тарату дип аталачак.

Инде хәзер массакүләм мәгълүмат чараларын әзерләүчеләргә кагылышлы төшенчәләргә күчик. Законда күрсәтелгәнчә, *редакция* ул – массакүләм мәгълүмат чараларын җитештерә һәм чыгара торган оешма, учреждение, предприятие, бер кеше яки берничә кеше төркеме. Сез үзегез практикага йөри торган газеталарның яки радио-, телеканалларның редакцияләрен беләсез. Мисалга, күпсанлы ТНВ

телерадиокомпаниясе редакциясе, “Шәһри Казан” газетасы редакциясе, шулай бер дистәдән дә ким кешедән торучы “Ирек мәйданы”, “Безнең гәҗит” газеталары редакцияләре дә бар.

Редакция белән гадәттә *баш мөхәррир* җитәкчелек итә. Гамәлдә аның вазыйфасы башкача - мәсәлән, генераль директор яки рәис дип аталырга да мөмкин. Әмма шуны истә тотарга кирәк: редакциядәге массакүләм мәгълүмат чараларын җитештерү һәм чыгаруга бәйле иң ахыргы сүзне кем әйтсә, баш мөхәррир шул була. Республикадагы радио-, телеканалларның һәм газета-журнал редакцияләренең баш мөхәррирләренең кайберләрен сез яхшы беләсез. Әйтик, “Идел” журналының баш мөхәррире – Рифат Фәттахов; ТНВ каналының баш мөхәррире – аның генераль директоры Илшат Әминев һ.б.

Исәпкә алынган массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе өчен хәбәрләр һәм материалларны редакцияләү, язу, җыю яки әзерләү белән шөгыльләнүче, әлеге редакция белән хезмәт килешүе яки башка төр килешүләр белән бәйләнгән яки ул хезмәтләрне редакция кушуы буенча башкаручы кеше *журналист* дип атала. Оешма, предприятиеләрнең күптиражлы басмаларында эшләүче, редакция белән килешүләр нигезендә бәйләнмәгән штаттан тыш хәбәрчеләр һәм авторлар, шулай ук Россия Тышкы эшләр министрлыгы тарафыннан аккредитация узган чит ил хәбәрчеләре дә журналист дип атала, димәк, әлеге законга буйсына. Ә менә төрле оешмалар яки предприятиеләр тарафыннан эчке рәсми документларын, норматив актларын чыгару өчен генә басыла торган, теркәлмәгән, шулай ук гомуми тиражы бер мең данәдән кимрәк булган массакүләм мәгълүмат чараларында эшләүчеләр закон алдында журналист булып санала алмый.

Күргәнебезчә, кешенең махсус белеме булмау, стажы озынлыгы, һөнәри берлеккә керү-кермәве, гражданлыгы, башка социаль яки шәхси сыйфатлары аны журналист итеп санар өчен киртә булып тора алмый, димәк, журналист хокукларына ия булудан да мәхрүм итми.

Һәрбер редакциядә дә журналистка махсус *редакция таныклыгы* (удостоверение) тапшырыла. Һөнәри вазыйфаларын башкарган вакытта журналист, таләп итсәләр, шунда ук үзе белән таныштыручы әлеге таныклыгын күрсәтергә тиешле. Бу шарт “ММЧ турындагы” законның 49 нчы маддәсендә чагылыш тапкан.

## Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. Россия тарихындагы массакүләм мәгълүмат чараларының хокукый эшчәнлегенә бәйле нинди законнарны беләсез?
2. Совет чорында журналистлар нинди законнарга буйсынып эшләгән?
3. Россия Федерациясенең "Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" Законының барлыкка килү тарихын сөйләгез.
4. РСФСРның Гражданлык кодексындагы 7 нче, Җинаять кодексындагы 131, 75, 141 нче маддәләрне карап чыгыгыз. Аларның эчтәлеге турында чыгыш әзерләгез.
5. Массакүләм мәгълүмат чараларына кагылышлы яңа закон проектларын нәрсә берләштерә?
6. Россия Федерациясендә ММЧ эшчәнлегенә бәйле күрсәтмәләр нинди законнарда билгеләнгән?
7. Россия Федерациясенең "Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" Законы нинди бүлекләрдән тора?
8. "ММЧ турындагы" Законның беренче бүлегендә бирелгән төп төшенчәләргә туры килерлек мисаллар сайлагыз.

### *Әдәбият*

Батурин Ю.М., Федотов М.А., Энтин В.Л. Закон о СМИ: на перекрестке веков и мнение – М.: Издание Союза журналистов России, 2004.

Бережной А.Ф. Царская цензура и борьба большевиков за свободу печати (1895-1914) / А.Ф.Бережной. - Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1967.

Временные правила о повременных изданиях. – Казань: Лито-типография И.Н.Харитонова, 1906

Законодательство Российской Федерации о средствах массовой информации / Научный комментарий доктора юридических наук М.А. Федотова. Серия “Журналистика и право”, выпуск 2. — М: Фирма Гардарика, 1996.

Нормативные правовые акты Российской Федерации о СМИ // http://www.medialaw.ru/laws/russian_laws/index.html

Обсуждение проектов закона о СМИ. - М.: Институт проблем информационного права, 2003..

Правовой сайт “КонсультантПлюс” // http://www.consultant.ru

Пять лет Закону РФ о средствах массовой информации/ — М.: Факультет журналистики МГУ им. М.В. Ломоносова, 1997.

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Русская печать и цензура в прошлом и настоящем. Статьи В.Розенберга и В.Якушкина. – М.: Изд-во М. И С. Собашниковых, 1905.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М. А. Правовое поле СМИ — Pro et contra // Библиотека Центра экстремальной журналистики. — http://www.library.cjes.ru/online/?a=con&b_id=602

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.

Эчтәлеккә кире кайтырга!

## *2 нче тема. Массакүләм мәгълүмат чараларын оештыруга таләпләр*

***Гамәлгә куючылар.*** Исеме булган, даими басма, радио-, телепрограмма рәвешендәге яки массакүләм мәгълүмат таратучы башка формага ия интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсен *массакүләм мәгълүмат чаралары* дип атыйлар.

Кем массакүләм мәгълүмат чараларын *гамәлгә куючы* була ала, ягъни кемнең газета чыгара башларга, теле- яки радиоканал ачарга хокукы бар, шуны ачыклыйк. Беренчедән, Россия җирлегендәге 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе гражданлыгына ия булган, хәзерге вакытта суд тарафыннан иректән мәхрүм итү урыннарында тоткарланмаган, медицина күзлегеннән караганда, үз акылында дип табылган теләсә кемнең массакүләм мәгълүмат чарасын гамәлгә кую хокукы бар. Күптәннән Россиядә яшәсәләр дә, гражданлыклары булмаган кешеләр – апатридлар да Россия гражданнары белән бертигез

хокукларга ия, дип табыла. Чит ил гражданнары бу хокуктан мәхрүм. Әмма искәрмә ясап, чынлыкта аларның да безнең илдә массакүләм мәгълүмат чарасын гамәлгә куя алуларын билгеләп узмый булмый: Россиядәге берәр предприятиене сатып алып яки яңаны үзләре оештырып, аннан шул предприятиене яңа массакүләм мәгълүмат чарасының гамәлгә куючысы итеп билгели алу мөмкинкинлеге бар бит.

Икенчедән, массакүләм мәгълүмат чараларын оештыру хокукы гражданнар җәмгыятьләренә - иҗтимагый, дини, хезмәт һәм журналист коллективларына да бирелгән.

Өченчедән, массакүләм мәгълүмат чараларын дәүләт органнары да гамәлгә куя ала. Аңлашыладыр, моны дәүләт хакимияте дә, җирле үзидарә органнары да эшли ала.

Гамәлгә куючылар бер дә, берничә дә булырга мөмкин. Берничә булганда, аларның һәркайсы *гамәлдәш (соучредитель*) дип атала. “ММЧ турындагы” Законның 22 нче маддәсенең 1 нче өлешенә нигезләнеп, алар арасында килешү төзелә. Бу килешүдә аларның икесе дә ия булган хокуклар, бурычлар, җаваплылык, гомуми кагыйдәләр, гамәлгә куючылар составының үзгәрү шартлары һәм аның юридик нәтиҗәләре, үзара бәхәсләрне чишү тәртибе күрсәтелә. Дөрес, бу килешүне төзү закон тарафыннан мәҗбүр итеп куелмый, әмма алда килеп чыгачак проблемаларны күздә тотсак, килешүнең зарурлыгы аңлашыладыр.

Билгеле ки, яңа ММЧ һәм аның эшчәнлеген тормышка ашыручы редакция оештырганда, аның икътисадый нигезләмәсе зур әһәмияткә ия. Икътисади нигезләмә ул – финанс, матди, мәгълүмати, эш көче ресурслары. Алар булмаса, газета да басылмый, радио- яки телетапшыру эфирга чыкмый, интернет-басма таратылмый кала. ММЧ ачарга теләгән кеше ресурслар мәсьәләсен чишүне, теркәү турындагы белешмә алганчыга кадәр дип, ахырга чиратка калдыра алмый.

Иң элек басманың финанс нигезе тәэмин ителә. Аның күләме, билгеле, булачак ММЧның чыгу даимилегенә, күләменә, якынча тиражына, ММЧ базарындагы гомуми халәткә һәм башкаларга бәйле. Икенче адым – матди-техник базаны барлыкка китерү. Моңа кирәкле кәгазь запасы булдыру, нәшрият яки типография белән килешү төзү (радио яки телевидение булганда, сигнал тарату өчен дәүләт техник үзәге белән килешенелә), редакция өчен бинага бәйле мәсьәләне чишү,

эш өчен кирәкле җиһазлар, техник чаралар алу кирәк. Басма ММЧны базарга чыгару өчен тарату базасын булдыру да таләп ителә – ул ирекле сатуда булса, таратучы хезмәтләр белән бәйләнеш урнаштыру, басмага яздыру кампаниясен башлап җибәрү кирәк.

Кирәкле мәгълүмат белән даими тәэмин ителеп тору өчен үзәк яки төбәк мәгълүмат агентлыклары белән килешү төзү, интернетка тоташу да шулай ук мөһим чаралар.

Гамәлгә куючы әле булачак проектын тормышка ашыру турында хыяллана гына башлаган чорында ук ММЧның эшче көчләре – журналистлар, техник хезмәткәрләр турында уйлый башлый. Чөнки дәрәҗәле редактор тарафыннан җитәкчелек ителгән бердәм команда, бергә тупланган көчле коллектив яңа ММЧны уңышка ирештерүдә үз ролен уйнаячак. Ә шундый кешеләрне редакциягә тарту бары тик уңайлы эш шартлары, яхшы хезмәт хакын тәэмин иткәндә генә мөмкин.

***Массакүләм мәгълүмат чараларсын теркәү механизмы.*** Теркәү *(регистрация)* Массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендә законлылыкны тәэмин итү Федераль хезмәте (Федеральной службой по надзору за соблюдением законодательства в сфере массовых коммуникаций и охране культурного наследия) яки аның төбәк органнары тарафыннан башкарыла. Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү гамәлгә куючы яки аның ышанычлысының массакүләм мәгълүмат чарасы таралачак төбәктәге регистрация органына гариза бирүеннән башлана.

Бу очракта өч моментка игътибар итәргә кирәк. Беренчедән, массакүләм мәгълүмат чарасын кайсы территориядә таратачагын бары тик гамәлгә куючы гына билгеләргә хаклы. Икенчедән, массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлекләрен теркәлгәннән соң гына башлап җибәрә алганга күрә, кайсы төбәктә таратылачагы алдан фаразлап кына билгеләнә. Мисал өчен, Татарстанда гына таратыла торган газета чыга башлады, ди. Бераздан аны күрше төбәкләрдә дә алдыра башлаган очракта, гамәлгә куючы, Законның 11 нче маддәсендә күрсәтелгәнчә, газетасын тагын бер тапкыр теркәргә тиешле. Өченчедән, таратылу төбәге диелгәндә, төп таратылу урыны күздә тотыла. Аерым саннар читтә сатылырга, чит төбәктән берничә кеше яздырып алырга да мөмкин. Кыскасы, матбугат турында сүз алып барганда, аның ярты тиражы шул төбәктә таралырга тиеш, ә радио һәм

телетапшырулар ныклы һәм ышанычлы кабул итү булган җирдә таратыла, дип санала.

***Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү.*** Теркәү өчен махсус документлар әзерләнә. Болар – гамәлгә куючы оешманың Уставы һәм Гамәлгә кую килешүе, дәүләт теркәлүен үтүе, салым органында исәпкә басуы, оешмада узган үзгәрешләр турындагы таныклыклар, статистика кодлары, оешманың генераль директорын билгеләү турындагы протокол яки карар, гамәлгә куючының банк реквизитлары турындагы белешмә, дәүләт салымын түләү квитанциясе, Бердәм реестрдан чыгарылма, гамәлгә куючы буларак физик затның паспорт күчермәсе, гамәлгә куючының адресы турындагы ирекле документ. Шулай ук планлаштырылган басма эротик характерда икән, аның оригинал-макеты да булырга тиеш. Барлык күчермәләрнең нотариус тарафыннан расланган булуы мәҗбүри.

Теркәлү өчен бирелә торган гаризага язма рәвештә бирелә. Гамәлгә куючы физик зат булса, анда бу кеше турында закон таләп иткән мәгълүматлар – Россия гражданы булуы, 18 яше тулганлыгы, акыл мөмкинлекләре белән бәйле чикләүләре юклыгы күрсәтелә. Моннан кала, гамәлгә куючының даими рәвештә Россиядә яшәгәнлеген күрсәтү зарур, юк икән, массакүләм мәгълүмат чарасы ул чакта чит илдә таратыла, дип саналачак.

Гаризада теркәлә торган массакүләм мәгълүмат чарасының исеме, теле, редакция адресы, таралу формасы, якынча тематикасы яки махсуслашу темасы күрсәтелә.

Теркәлер алдыннан ММЧлар *дәүләт пошлинасын* түләргә тиеш. Әгәр массакүләм мәгълүмат чарасы балалар һәм яшүсмерләр, инвалидлар өчен, шулай ук белем бирүче һәм мәдәни-агарту юнәлешендә чыгачак икән, "ММЧ турындагы" Законның 14 нче маддәсенең 1 нче өлеше нигезендә, аларның гамәлгә куючылары теркәү салымын биш тапкырга кимрәк түли. Әмма массакүләм мәгълүмат чарасы реклама һәм эротик характердагы материаллар таратырга ниятли икән, бу очракта салым артып кына калмый, югарыда аталган законның 37 нче маддәсендәге аерым шартларны үтәү дә кирәк була.

Инде суммаларга килсәк, алар бик зур түгел, мисал өчен, Россия буенча яки берничә субъектта таратылырга тиешле басма 2000 сум, мәгълүмат агентлыгы – 2400 сум, калганнары 3000 сум салым түли.

Әгәр бер субъектта, шәһәрдә, районда, микрорайонда гына чыгарылачак басма икән, салым нибары 1000 сум, агентлык өчен – 1200, ә калганнарга 1500 сумга гына кала. Реклама ММЧлары өчен салым күләме – биш, ә эротик характердагыларына ун тапкырга артыграк испәләнелә.

Гамәлгә куючы гаризасында финанслау чыганакларын, массакүләм мәгълүмат чарасының таралу даимилеген, якынча күләмен күрсәтә, әмма аларны расларлык банк документларын һ.б. теркәү кирәк түгел. Шик туган очракларда теркәүче органның бу мәгълүматларны бер ай эчендә тикшерергә хакы булса да, ул документларны гамәлгә куючыдан таләп итү хокукы юк. Инде гамәлгә куючының шикләрне үзенең тизрәк юкка чыгарасы килә икән, әлбәттә, тиешле документларны үзе җыеп китерә ала.

Кайбер массакүләм мәгълүмат чаралары теркәүдән азат ителә. Ул исемлеккә дәүләт органнары тарафыннан бары тик эчке рәсми материаллар, норматив актлар тарату өчен генә чыгарыла торган чаралар, даими тиражы 1 мең данәдән дә кимрәк булган басмалар, шулай ук кабель челтәре буенча аерым бер оешма, уку йорты, җитештерү предприятисе территориясендә генә таратыла торган яки уннан да артык абоненты булмаган радио- һәм телетапшырулар, ун данә язмадан артык таратылмаган аудио-, видеопрограммалар керә.

Хакимият органнары тарафыннан рәсми документлар, норматив һәм башка актларны бастыру өчен чыгарыла торган яки гомуми тиражы 1 меңнән артмый торган массакүләм мәгълүмат чаралары өчен теркәлү кирәк түгел. Әмма бу әле теркәү тыела дигәнне аңлатмый.

Документлар тапшырганнан соң бер ай эчендә ММЧ теркәлергә тиеш.

Мәгълүмат агентлыгы да теркәлгән очракта ММЧларга хас хокукый режим кысаларында эшләячәк. Әлеге агентлык чыгара торган бюллетень, башка төрдәге басма яки программа да барлык ММЧлар өчен бердәм булган уртак тәртиптә теркәлергә тиеш.

Аудио- һәм аудиовизуаль массакүләм мәгълүмат чаралары өчен исә өстәмә таләпләр бар. Теркәү турындагы таныклыктан кала, ул тапшыру өчен Россия Элемтә министрлыгыннан лицензия дә алырга тиеш.

***Теркәүгә каршы килү очраклары.*** "ММЧ турындагы" Законның 13 нче маддәсе теркәү вакытында каршы килерлек очракларны үз

эченә ала. Мисал өчен, Россия территориясендә яшәмәүче кешегә, шулай ук гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар ялган булып чыкса, күзалланган тематика сугышка чакыру, җинаять җаваплыгына тартылырлык эшләргә үгетләү, дәүләт яки башка төр серләрне тарату өчен (әлеге законның 4 нче маддәсендә күрсәтелгән очраклар) билгеләнсә, теркәлергә рөхсәт бирелми.

Тагын бер очрак - әгәр моннан алданрак нәкь шундый ук исемдә, даимилектә, формада бер массакүләм мәгълүмат чарасы теркәлгән булган икән, шундый ук икенче бер массакүләм мәгълүмат чарасына рөхсәт бирелми. Бу кагыйдә массакүләм мәгълүмат базарында буталчыклар килеп чыкмасын өчен кертелгән. Әмма шунысы бар, инде, мисалга, “Кояш” исемле газета чыгып килгән җирдән тагын бер “Кояш” исемле басма – журнал бастырыла башлый икән, бу законны бозмый. Икенче мисал, Удмуртиядә татарлар өчен “Дуслык” исемле газета чыга, ди. Шул ук вакытта андый исемдәге басма Башкортстанда да теркәлергә мөмкин. Бер “Дуслык” газетасы бөтен Россия буенча тарату максаты белән федераль органда теркәлгән очракта шул исемдәге тагын бер басма теркәлү мөмкинлеге булмый инде.

Югыйсә, шундый хәлләр дә булып куя икән. Мәсәлән, Хәбәрдарлыкны яклау фондына Калугада чыгып килүче "Приокская газета" басмасының баш мөхәррире Виктор Тен мөрәҗәгать иткән. Баксаң, шул ук шәһәрдә форматы, күләме, бизәлеше белән шул массакүләм мәгълүмат чарасына ике тамчы су кебек охшаш "Приокская новая" газетасы чыга башлаган. Баш мөхәррир әлеге уңайдан судка да мөрәҗәгать итәргә була.

Андый очрак Иркутск каласында да күзәтелә. Анда яңа барлыкка килгән "Новое Честное слово" газетасы шул ук шәһәрдә инде ике ел чыгып килгән "Честное слово" басмасының шрифт, логотип, бизәлешен, рубрикаларын кабатлый икән. Иң кызыгы шунда: яңа игезәк-газета искесендә җирле хакимият яратып бетерми торган депутатлар белән интервью басылып чыкканнан соң барлыкка килгән бит! Бу очракта да иске газетаның редакциясе судка мөрәҗәгать итүне дөрес дип тапкан[1].

***Редакция уставы.*** Теркәлү өчен *редакция уставы* булу мәҗбүри. Ул редакция белән гамәлгә куючы арасында үзенчәлекле килешү документы булып тора. Аның эчтәлеге һәм төзелеше редакция һәм

[1] http://www.gdf.ru/old/monitoring/index.html

басманың эчке үзенчәлекләре, коллективның зурлыгы, хезмәткәрләрнең вазыйфаларына бәйле рәвештә формалаша.

“ММЧ турындагы” Законның 20 нче маддәсе нигезендә, редакция әле яңа гына оештырылган булса һәм уннан да азрак кешедән торса, устав *килешү* белән дә алыштырыла ала. Устав редакция коллективы җыелышында тикшерелеп, күпчелек тавыш белән кабул ителә (җыелышта барлык хезмәткәрләрнең кимендә өчтән икесе катнашырга тиеш) һәм гамәлгә куючы тарафыннан раслана. Ул редакциянең дә, гамәлгә куючыларның да интересларын исәптә тотарга, аларның икесенең хокуклары һәм бурычларын төгәл күрсәтергә тиеш.

Бәхәсләр килеп чыгуны исәптә тотып, "ММЧ турындагы" Закон буенча, массакүләм мәгълүмат чарасының беренче саны басылу һәм эфирга чыгу көненнән башлап, уставны үзара килештерү һәм раслар өчен өч ай вакыт бирелә. Әгәр шул вакыт эчендә устав теркәүче органга тапшырылмаса, әлеге орган, теркәүне гамәлдән чыгаруны сорап, судка мөрәҗәгать итә ала.

Редакцияләрнең уставларында ике якның да, ягъни гамәлгә куючы һәм редакция, баш мөхәррир, журналистлар коллективының хокуклары, бурычлары күрсәтелә. Шунда ук баш мөхәррир, редакцион коллегия яки редакция белән идарә итүнең башка органнарын сайлап яки белгеләп кую тәртибе, массакүләм мәгълүмат чарасын оештыру, эшчәнлеген туктатып тору яки ябу тәртибе билгеләнә. Уставта гамәлгә куючы үзгәргәндә, массакүләм мәгълүмат чарасы ябылганда, редакция юкка чыгарылган очракларның нинди юридик нәтиҗәләргә китерәчәге дә карала. Әлеге уставны кабул итү һәм үзгәртү шартлары турында да сүз була.

Аңлашыладыр ки, редакциянең оештыру формасына карап, уставның эчтәлеге дә төп үрнәктән үзгәрәк булырга мөмкин. Мәсәлән, чикләтелгән җаваплылыктагы җәмгыять рәвешендә оештырылган редакциянең уставында башлангыч капитал күләме, һәрбер катнашучының өлеше, вкладларны кертү күләме, составы, вакыты һәм тәртибе һ.б. күрсәтелергә тиеш. Законга каршы килерлек булмаса, уставны тагын башка положениеләр белән тулыландырырга да рөхсәт ителә.

***Гамәлгә куючы, нәшир, редакция, милек хуҗасы арасындагы хокукый мөнәсәбәтләр.*** ММЧны гамәлгә куйганнан соң гамәлгә куючы, нәшир, редакция, милек хуҗасы арасында аерым хокуклары

һәм бурычлары булган хокукый мөнәсәбәтләр башланып китә. Бу мөнәсәбәтләр “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” закон белән көйләнелә. Ул мөнәсәбәтләрнең эчтәлеген редакция уставы һәм үзара килешү документлары билгели. Әмма һәр очракта да үзенчәлекләре дә булырга мөмкин. Мәсәлән, гамәлгә куючы бер үк вакытта редакция ролен үтәргә дә, шул редакциядә баш редактор вазыйфаларын башкарырга да мөмкин. Яки бер үк вакытта нәшир дә булырга, димәк, басманың матди-техник базасын һәм таратылуын тәэмин итәргә тиеш.

Журналистларны хуҗаларыннан мөмкин кадәр саклау, яклау максатында “ММЧ турындагы” Закон гамәлгә куючының юридик мөмкинлекләрен шактый кысып билгеләгән. Сүз дә юк, ул редакциягә аерым бурычлар йөкли ала, мисал өчен, тиз арада үз исеменнән язылган, законда *“гамәлгә куючы белдерүе*” дип аталган материалны бастыруны таләп итеп куя ала. Уставта бу белдерүнең аерым шартлары да күрсәтелергә мөмкин, мәсәлән, аның даимилеге, күләме, тематикасы, кульязманы тапшыру вакыты, гамәлгә куючылар берничә булган очракларда, аны алар белән дә килештереп эшләү шарты. Редакциягә ул белдерүне үзгәртү хокукы бирелми, чөнки шул материал буенча ахырдан бәхәсләр чыгып, эш судка барып җитсә, җавапны гамәлгә куючы бирергә тиеш. Әмма басылып чыккан белдерүдә аның гамәлгә куючыныкы икәнлеге ачык күрсәтелмәгән икән, җаваплылык редакция өстенә кайтып кала.

Шушы “белдерү”дән кала, гамәлгә куючының редакция эшенә катнашу хокукы юк диярлек. Дөрес, редакция коллективы белән килешү нигезендә, уставта аның катнашу мөмкинлеге киңрәк итеп тә карала ала. Әмма аның гамәлләре закон белән каршылыкка кермәскә тиеш. Әйтик, гамәлгә куючы материалларны бастырыр алдыннан үзе белән килештерүне таләп итә икән, бу эше закон бозу, дип бәяләнәчәк.

Гамәлгә куючының редакциягә бирелгән матди милекне нәтиҗәле, максатка ярашлы итеп кулланылуны контрольдә тотарга, уставта күрсәтелгән тәртиптә баш мөхәррир билгеләргә һәм аны эшеннән азат итәргә, юридик зат буларак, редакцияне юкка чыгару турында карарлар кабул итәргә хокукы бар.

Чынбарлыкта, кызганычка каршы, менә шул хокук аның законга ярашмаган таләпләренә каршы чыккан редакция яки баш мөхәррирдән котылырга мөмкинлек бирә дә. Андый башбаштаклыклардан котылу

өчен, 1999 елның 28 апрелендә Россиянең Матбугат дәүләт комитеты, РФ Президенты каршындагы Мәгълүмати бәхәсләр буенча суд палатасы һәм Журналистлар берлеге уртак рекомендация кабул итте. Анда ассызыкланганча, гамәлгә куючының, уставта күрсәтелгән очраклардан кала, массакүләм мәгълүмат чарасын башка сәбәпләр белән ябарга яки аны финанслауны туктатырга хакы юк.

Шул ук рәвештә аның гамәлгә куючылар исемлегеннән чыгарга да хакы юк. Чыгу теләге булса, ул барлык бурычлар һәм вазыйфаларын үтәүне редакция һәм калган гамәлгә куючыларның ризалыгы белән генә өченче затка тапшырырга тиеш. Өченче зат булып бу очракта редакция коллективы үзе дә торырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, ул вакытта массакүләм мәгълүмат чарасы яңадан теркәү үтә.

Кагыйдә булганча, гамәлгә куючының үзгәрүе редакция уставына һәм редакция белән икеарадагы килешүгә дә үзгәрешләр кертүне таләп итә. Әмма шунысы мөһим: устав, килешү документлары кабат каралуга карамастан, алдагы гамәлгә куючыга йөкләнгән бурычлар юкка чыкмый, аларны аның урынына килгән яңасы үтәргә тиеш.

Гамәлгә куючылар берничә булып, аларның берсе бу составтан чыгарга теләгән очракта да шушы ук кагыйдәләр эшли.

Гамәлгә куючы юридик зат булган очракта, ул орган массакүләм мәгълүмат чарасын башкага кушу, бүлү, аерып чыгару яки башка төргә үзгәртү юлы белән аны ябу яки үзгәртеп кору турында карар кабул итә ала.

Гамәлгә куючының уставта яки редакция белән үзара төзелгән килешүдә күрсәтелгән очракларда һәм алдан килешенгән тәртип белән массакүләм мәгълүмат чарасының эшчәнлеген туктатып торырга яки бөтенләй ябарга мөмкинлеге бар. Әмма шунысы бар: туктатып тору вакыты бер елдан да артмаска тиеш. Артыкка китсә, аны теркәгән орган теркәүне юкка чыгаруны сорап, судка мөрәҗәгать итә ала. Суд бу таләпне дөрес дип тапса, аның артыннан ук теркәү документы һәм редакция уставы да гамәлдән чыга.

## Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. Массакүләм мәгълүмат чарасын гамәлгә куючы төшенчәсенә аңлатма бирегез.

2. Массакүләм мәгълүмат чарасын гамәлгә куяр алдыннан гамәлгә куючы чишәргә тиешле нинди мәсьәләләрне беләсез?

3. Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү механизмы нәрсәдән гыйбарәт?

4. Кайсы очракларда теркәүгә каршы килергә мөмкиннәр?

5. Редакция уставының төп эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт?

6. Гамәлгә куючының хокуклары "ММЧ турындагы" Законда ничек билгеләнә?

7. Үзегез практикага йөри торган редакциянең уставын алып өйрәнегез һәм андагы редакция белән гамәлгә куючы арасындагы мөнәсәбәтләрне күрсәтүче моментларны аерып күрсәтегез.

## ***Әдәбият***


Давтян С.Л. Редакционные уставы. Правовые особенности организации и функционария редакции СМИ / Под ред. А.Г.Рихтера. – М.: Инст.проблем информ.права, 2004. – 192 с. – (Журналистика и право; Вып.36)

Оформление трудовых отношений в редакциях СМИ / Авт.-сост. А.А.Кашин, Д.С.Корсаков, М.А.Ледовских, С.В.Педько. – М.: Престиж, 2007. – 120 с. – (Справочная серия. Юристу и руководителю СМИ)

Регистрация средств массовой информации в регионе ОБСЕ / Специальный докладПредставителя ОБСЕ по вопросам свободы СМИ. - Вена, 2006. - http://osce-fom.cjes.ru/docs/?did=7

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Рихтер А. Г. Правовые основы журналистики : Хрестоматия. - М.: Институт проблем информационного права, 2004.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.


Эчтәлеккә кире кайтырга!

### *3 нче тема. Журналист һәм мәгълүмат*

Журналистның төп коралы нәрсә? Берәүләр кулы-аягы дияр (янәсе, аны аяклары туйдыра), икенчеләр үткен һәм акыллы сүзе, дигән фикерне хуплар, өченчеләр исә кәгазь-каләме дип шаяртырга да мөмкин. Болар барысы да дөрес кебек. Чынлап та, ул кулы-аягы белән табылганнарны журналист сүзенә, авазына әйләндереп, кәгазе-каләме ярдәмендә халыкка җиткерә бит. Әмма нәрсәне таба, эзли, эшкәртә һәм җиткерә соң ул? Әлбәттә, мәгълүматны. Димәк, журналистның төп коралы да мәгълүмат булып чыга.

Россия Конституиясенең 29 нчы маддәсе буенча, массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүмат табу һәм тарату өлкәсендә киң хокукка ия. Анда күрсәтелгәнчә, "һәркемнең дә мәгълүматны теләсә нинди законлы юл белән эзләү, алу, тапшыру, җитештерү һәм тарату хокукы бар. Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларның исемлеге федераль закон белән билгеләнә". Шунда ук "массакүләм мәгълүмат чараларының иреге гарантияләнә" дигән момент та бар.

***Мәгълүмат төрләре.*** Гамәлдәге законнарга нигезләнеп, ирешү юлларын исәпкә алып караганда, мәгълүматның берничә төрен аерып чыгарырга мөмкин. Беренчесе – аерым кешеләр турындагы һәм шул кешеләргә генә билгеле булган, ягъни *гражданлык әйләнешендәге мәгълүмат*. Әлеге мәгълүматны шул кешеләр, үзләре теләсәләр, башка берәүләргә бушка яки сатып бирә ала; башкалар белән бүлешмичә, үзләрендә генә дә сакларга мөмкин. Ул очракта беркемнең дә алардан ул мәгълүматны бирүләрен таләп итә алмый. Мисал өчен, танылган җырчының ничә машинасы булуы, ял итәргә кайсы илгә барып кайтуы, кемгә өйләнергә исәпләп йөрүе шундый мәгълүматка керә.

Икенче төр мәгълүмат – *ачык һәм һәркем дә ирешерлек мәгълүмат*. Бу – теләсә кайсы кешегә бернинди тыюларсыз барып ирешергә тиешле мәгълүмат. Беренче чиратта, аның белән дәүләтнең мәгълүмати ресурсларын формалаштыручы һәм саклаучы органнарда эшләүче кешеләр тәэмин итә. Ул һәркемгә ачык мәгълүматны санитар-эпидемиологик күрсәткечләр, әйләнә-тирәдәге экологик торыш, ризыкның һәм көнкүреш кулланылыштагы товарларның сыйфаты, куркынычсызлыгы, кеше башкарган эшләрнең аның тормышына һәм сәламәтлегенә тәэсире турында даими таныштырып торырга тиешле оешмаларның шуның өчен куелган махсус хезмәткәрләре дә бирә.

Тагын һәркемгә дә ачык булмаган – *ябык, ягъни чикләнгән мәгълүмат* төшенчәсе бар. Чынлап та, кайбер очракларда дәүләткә яки аерым кешеләргә зыян килмәсен өчен, мәгълүмат бар кешегә дә ачык булмаска мөмкин. Әйтик, дәүләт сере, коммерция сере, суд сере һ.б. шундый мәгълүмат төренә карый.

Тик журналистка шуны истә тотарга кирәк: төрле органнар, оешмалар һәм аерым гражданнарның хокукый статусын ачыклаучы норматив актлар, шулай ук дәүләт органнарының эшчәнлеге, бюджет яки фонд акчаларын ничек тотулары турында сөйләүче документлар беркайчан да ябык мәгълүматка керми. Әгәр шул мәгълүматларны сорап мөрәҗәгать иткән очракта, аларны “сер” дип атап, бирүдән баш тарталар икән, бу очракта мәгълүмат бирергә теләмәгән кешенең законны бозганлыгы турында белеп торыгыз.

Мисал өчен, 2000 нче елда “Эфир” телеканалының “Город” программасы 28 тапкыр конфликтлы очракларда калган. Аларның күпчелеге журналистларны дәүләт органнарына кертмәү, сәбәбен аңлатып тормыйча гына мәгълүмат бирүдән баш тарту, материал һәм документлар белән танышу мөмкинлеген чикләү белән бәйле булган.

***Ачык мәгълүмат төрләре.*** Әлеге төргә керә торган мәгълүмат турында тирәнрәк карап китик әле. “Дәүләт сере турындагы” Законның 7 нче маддәсенең 1 нче бүлегендәге 1 нче пункты күрсәткәнчә, ул төргә гражданнарның сәламәтлегенә һәм куркынычсызлыгына янаучы гадәттән тыш хәлләр һәм фаҗигаләр, алар китергән бәлаләр, табигать бәла-казалары, рәсми һава торышы фаразлары керә. Әлеге Законның шул ук маддәсенең 3 нче пункты бу исемлеккә дәүләт тарафыннан гражданнарга, урындагы кешеләргә, оешмалар, предприятиеләргә күрсәтелә торган ярдәм, өстенлекләр турындагы мәгълүматларны да кертә. Ә алдагы 4 нче пунктта кеше хокуклары бозылу турындагы фактлар турында сүз бара. 6 нчы пункт бу исемлеккә дәүләт җитәкчеләренең сәламәтлеге турындагы мәгълүматларны да өсти.

Предприятие һәм оешмалар гражданнарга санитария-эпидемиология торышы, әйләнә-тирә, ашамлыклар, җитештерү продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турындагы мәгълүмат белән ачыктан-ачык тәэмин итеп торырга тиеш.

Кредит оешмалары, ягъни банкларга теләсә кем, хәтта аларның клиенты булмаган кеше мөрәҗәгать иткәндә дә, банк эшчәнлегенә

бәйле кайбер документларны – банк операцияләрен алып бару хокукы бирә торган лицензия, бухгалтер балансы, керемнәр һәм чыгымнар турында хисап, узган ел буенча аудитор нәтиҗәсе, шулай ук айлык бухгалтер балансларын күрсәтү бурычы йөкләнгән (“Банклар һәм банк эшчәнлеге турындагы” федераль законнын 8 нче маддәсе буенча).

***Ябык мәгълүмат төрләре.*** Ябык мәгълүматларны ике төркемгә бүлеп булыр иде. Беренчеләре – дәүләт сере, икенчеләре – конфиденциаль сер.

Россия Федерациясенең “Дәүләт сере турындагы” Законының 2 нче маддәсенә нигезләнеп, *дәүләт сере* төшенчәсенә аңлатма бирик. Аларны куллану Россия Федерациясенең куркынычсызлыгына зыян салырга мөмкин булган, хәрби, тышкы сәясәт, икътисад, разведка, контрразведка, тикшерү өлкәләренә кагылышлы, дәүләт тарафыннан саклана торган мәгълүмат ул. Дәүләт серенә караган мәгълүмат “үтә әһәмиятле”, “үтә яшерен”, “яшерен” грифлары белән билгеләнә. Андый серләрнең яшерен булып яшәү вакыты – күп дигәндә, 30 ел. Саклау вакытын тагын да озайтуны Дәүләт серен яклау буенча махсус ведомствоара комиссия карый.

Серләрнең икенче төркеме – *конфиденциаль сер*. Болар – аерым шәхеснең хокукларын саклау максатыннан, бар кеше өчен дә ачык булмаган мәгълүматлар. Аларның төрләре Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 1997 елның 6 мартында расланган исемлектә ачык билгеләнгән:

1) *шәхси мәгълүматлар* – аерым бер кешенең шәхси тормышында урын алган фактлар, вакыйгалар, очраклар турындагы мәгълүматлар. РФ Конституциясенең 23-24 нче маддәләре һәркемгә шәхси тормышның кагылгысызлыгын тәэмин итә: кешенең ризалыгыннан башка, аның шәхси тормышы турындагы мәгълүматларны җыю, саклау, куллану, тарату тыела.

Ә менә "ММЧ турындагы" законның 49 нчы маддәсе журналист өчен бу очраклардан искәрмә ясый: иҗтимагый әһәмияте булганда, шул кешенең рөхсәтеннән башка да аның шәхси тормышы турындагы мәгълүматларны тарату хокукын бирә. Әмма бу вакытта берничә сорау туа. Беренчедән, ул “иҗтимагый әһәмияте булу”ны ничек аңларга? Икенчедән, законда андый мәгълүматны тарату рөхсәт ителсә дә, аны җыю һәм саклау турында бер сүз дә юк. Ә аны җыймыйча яки сакламыйча гына ничек итеп таратып була икән соң?

Шулай да бу очракларда, аерым бер кеше турында сүз алып барганда, аның *шәхси һәм халыкка билгеле тормышы* төшенчәләрен аерып күрсәтүнең файдасы булырга мөмкин. Мәгълүмат субъектының, ягъни шул кешенең бар халык өчен дә ачык җәмәгать урынында булуы аның шәхси тормышы өлкәсенә карамый. Аның игътибарны үзенә тарту максатыннан халыкка файда китерә торган яки зыян сала торган эшләр башкаруы да шәхси тормышка кертелми.

Аерым кешенең шәхси тормышы турында мәгълүмат җыяр өчен журналист шул кешедән рөхсәт алырга тиеш. Ул рөхсәт язма рәвештә генә булырга тиеш димәгән, телдән әйтелгән очракта да дөрес санала. Ахырдан мәгълүмат субъекты тавыш-гауга чыгарган очракта, аның телдән ризалык бирүен исбатлый алса, журналист гаепле дип табылмаска тиеш. Хәтта кайбер вакытта субъектның үзе турында мәгълүмат җыйганны күреп торып бер сүз дә әйтмәве, ягъни дәшми калуы да аның ризалык белдерүе дип табылырга мөмкин. Мәсәлән, шундый очракны карап узыйк. Фотохәбәрче танылган җырчыны паркта тәмәке тартып торган килеш сурәткә төшереп ала. Фотосурәте газетада басылып чыккач, шул җырчы, үзенең шәхси тормышына тыкшынуда гаепләп, басманы судка бирә. Әмма аның фотода җәмәгать урынында булуын һәм фотода объективка карап елмаеп утыруын исәпкә алгач, фотохәбәрче гаепсез дип табыла: елмаеп утыра, димәк, үзен төшергәнннәренә каршы түгел.

Телефоннан сөйләшүләр, почта, телеграф, интернет аша килгән хат-хәбәрләр һәркемнең үз шәхси эше дип карала, шуңа күрә дә чит кешенең андый серләре белән танышырга омтылган яки танышкан өчен журналистны Җинаять кодексының 138 нче маддәсе нигезендә җавапка тартырга мөмкиннәр. Әле шунысы да бар: ике кеше арасында булган телефон сөйләшүендә яңгыраган яки хатларда язылган мәгълүматларны, аларга катнашы булмаган өченче берәүдән белеп, халыкка чыгарган өчен дә журналистны шундый ук җәза көтә.

“Вөждан ирege һәм дини оешмалар турындагы” федераль Законның 3 нче маддәсе нигезендә, нинди дин тотуы һәркемнең үз эше, һәм ул сер булып кала ала. Махсус шуның өчен җиһазландырылган урыннарда дини йолалар башкару кешенең шәхси тормышына карый, димәк, андагы кешеләрне үзләренең рөхсәтеннән башка фото- яки видеокамерага төшерергә ярамый булып чыга;

2) *тикшерү эше яки судка бәйле серләр турындагы мәгълүматлар.* Җинаять эше буенча тикшерү алып баручылар һәм шул тикшерүне күзәтеп торган кешеләр андагы серләрне ачмау турындагы документка кул куя. Суд үз карарын чыгармый торып, аларның бу мәгълүматларны прокурор яки тикшерүче рөхсәтеннән башка кемгә дә булса ачарга хаклары юк. Шуңа да суд карары чыгарылганчы ук тикшерү материаллары белән танышырга теләге булган журналистны алар белән бары тик прокурор яки тикшерүче рөхсәте белән генә таныштыра алалар. Әгәр дә материаллар тупланып та, ул очрак буенча җинаять эше кузгатылмаган икән, журналистның алар белән танышу хокукы барлыкка килә;

3) *хезмәт сере* – федераль законнар һәм Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы нигезендә дәүләт органнары тарафыннан тыю салынган серләр ул. *Коммерция сере* исә коммерция эшчәнлеге белән бәйле мәгълүматлар. Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы билгеләгәнчә, әгәр мәгълүмат, башка кешеләргә билгеле булмавы аркасында потенциаль коммерция кыйммәтенә ия икән, ул хезмәт яки коммерция серенә карый. Мисал өчен, банкның акча операцияләре, исәп-хисап счетлары, клиентлары турындагы мәгълүматлары коммерция серенә керә. Аларны законсыз рәвештә, мәсәлән, документларны урлау юлы белән яки зыян китерү максаты белән табып тараткан өчен җаваплылыкка тартырга мөмкиннәр.

Ә менә оешманы гамәлгә кую турындагы документлар, аерым бер эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокук бирүче лицензия, сертификатлары, оешмада эшләүчеләр саны, аларның эш шартлары турындагы мәгълүматлар коммерция сере була алмый;

4) *һөнәри сер* – аерым бер һөнәргә караган кешеләрнең бар кеше өчен дә ачык була алмый торган мәгълүматлары. Һөнәри серләрнең берничә төре бар. *Медицина яки табиб сере* кешенең медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итүе, аның сәламәтлегенең торышы, психик тайпылышларга ия булу-булмавы кебек мәгълүматларны үз эченә ала. Медицина сере булып саналган мәгълүматларны җыйган һәм тараткан өчен журналистны, кешенең шәхси тормышына тыкшынуда гаепләп, Россия Федерациясе Җинаять кодексы нигезендә җавапка тартырга һәм әхлакый зыян китергән өчен шул кешегә компенсация түләтергә мөмкиннәр.

Безгә исә *журналист сере* турында белеп торырга кирәк булыр. "ММЧ турындагы" законның 41 нче маддәсе белдергәнчә, әгәр кем дә булса ниндидер мәгълүматны сер итеп саклауны шарт итеп куйган икән яки чыганакның исемен ачмау шарты белән мәгълүмат биргән икән, редакция ул серне беркемгә дә ачмаска тиеш. Бердәнбер искәрмә - тикшерү барышында суд органнары таләп иткән очрак. Анда да редакция, чыганакның исемен ачмау максатыннан әйтми калып, бар җаваплылыкны үз өстенә алырга мөмкин.

Журналист та әлеге Законның 49 нчы маддәсе нигезендә, мәгълүматның һәм аның чыганагының яшеренлеген сакларга тиеш. Беркем дә аннан сер итеп кенә, исемен башкаларга ачмаслыгына ышанып әйткән чыганакның кем икәнен мәҗбүр итеп ачтыра алмый. Чөнки Россия Федерациясе Конституциянең 51 нче маддәсе һәм "ММЧ турындагы" законның 49 нчы маддәсе нигезендә, журналист сер итеп җиткергән мәгълүматнең эчтәлеге һәм чыганагы турында шаһитлек күрсәтмәләре бирүдән азат ителә.

Ә менә җәмәгатьчелеккә ачмау шарты белән бирелгән мәгълүматны, псевдонимны яки яшерен чыганак исемен ачкан өчен, бу эшләр китергән зыян күләменнән чыгып, журналистны җинаять җаваплылыгына тартырга да, компенсация түләтергә дә мөмкиннәр.

Хәбәрдарлыкны саклау фонды тикшеренүләре журналистларга мәгълүмат алу өчен чыганак булып кемнәр хезмәт итүен тикшергән һәм шуны ачыклаган: аларның 60% тан артыграгы хакимият органнары һәм шуларда эшләүче чиновниклар икән[2]. Тикшерүләр күрсәткәнчә, төбәкләрдәге һәм җирле массакүләм мәгълүмат чаралары чыганак итеп башкарма хакимият органнарын сайлап алсалар, үзәк массакүләм мәгълүмат чаралары исә күпчелек очракларда хакимияткә катнашы булмаган аерым кешеләргә мөрәҗәгать итә.

Еш кына шулай килеп чыга да: журналист башкарма хакимият органында үзе өчен даими мәгълүмат чыганагын булдыра. Республика яки район хакимиятендәге ул кеше телдән килешү нигезендә журналистны кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итеп тора да инде. Бер яктан караганда, бик уңайлы кебек. Беренчедән, мәгълүмат журналистка көне-сәгате белән барып ирешә, икенчедән, шул эшкә катнашы булган кешедән килгәнгә, дөрес, дәлилле була кебек. Әмма,

[2] Корконосенко С.Г. Право и этика СМИ: Учебное пособие / С.Г.Корконосенко, В.В.Ворошилов. –СПбГУ, 1999. – С. 29-30.

икенче яктан карасак, журналист андый очракларда мөстәкыйльлеген югалта, вакыйгаларга бәя биргәндә, теләсә-теләмәсә, үз фикереннән бигрәк, мәгълүмат биргән кеше фикерен яктыртуны артыграк күрә. Чөнки башкача эшләү чыганакны югалтуга китерергә дә мөмкин бит. Болар нәтиҗәсендә журналистны хаклы рәвештә бер яклы гына фикерләүдә, мәгълүматының еш кына тикшерелмәгән булуында гаепли башлаячаклар. Андый күңелсез хәлләргә тарымас өчен иң кулае – бер үк темага мәгълүмат бирерлек берничә чыганак булдыруга ирешүдер, мөгаен.

Мәгълүмат чыганагы сайлау һәм мәгълүмат җыю алымнары, традиция буларак, һәрбер җәмгыятьтә үзенчә урнаша. Мәсәлән, журналистның мәгълүмат җыйганда, үзен башка бер кеше итеп таныштыру ысулы, АКШ белән Россия журналистларын чагыштырсак, бездә 1,5 тапкырга күбрәк кулланыла икән. Яшерен камера һәм диктофон куллану аларда да, бездә дә чама белән бер күләмдә гадәткә кергән. Ә менә үзләренең рөхсәтеннән башка кешеләрнең шәхси документларын куллану - АКШта бездәгедән 10 тапкырга, этика һәм законнар белән тыелган очракларда да чыганакларның һәм геройларның чын исемен ачып бирү 43 тапкырга артыграк очрый.

*Гражданлык хәлләрен язып бару актлары сере* белән бәйле тыюлар да бар. Гражданлык хәлләрен язып бару актлары – алар кешеләрнең хокуклары барлыкка килү һәм юкка чыгуга китергән, шулай ук гражданлык халәтен сурәтләүче вакыйгалар. Мәсәлән, өйләнешү, гражданлык, милләт турындагы мәгълүматлар шул вакыйгаларга керә.

Баланың тууы, никахы, аерылышулары, уллыкка (кызлыкка) алу, аталык хокукларына ия булу, исем алыштыру һәм үлем очраклары мәҗбүри рәвештә дәүләт тарафыннан исәпкә алына, ягъни регистрацияләнә. Исәпкә алу вакытында ЗАГС хезмәткәренә билгеле булган бу мәгълүматлар да шәхси мәгълүматлар булып санала. Шуңа да алар барлык кешегә дә ачык булмаган серләр рәтенә керә. Димәк, журналист ЗАГС кенәгәләреннән берәр кеше турында яшерен мәгълүмат җыйса, таратса, ЗАГС хезмәткәре белән беррәттән җавапка тартылачак. *Нотариаль сер* турында да шушы ук тыюларны әйтергә була.

Әмма әгәр ул дәүләт, хезмәт, тикшерү, һөнәр серләрен ЗАГС хезмәткәрләре, табиблар, дәүләт эшлекләләре, судьялар авызыннан

түгел, ә, мисал өчен, авыру белән бер палатада яткан кешеләр, күршеләре, танышлары аркылы белеп, материалларында файдаланса, журналист җавапка тартылмый. Чөнки бу очракта журналист турыдан-туры мәгълүмат бирелгән кеше түгел, ә өченче кеше дип саналачак.

## Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. Гражданлык әйләнешендәге, ачык һәм ябык мәгълүматларның аермалы яклары нәрсәдә?
2. Ябык мәгълүматның нинди төрләре була? Алар кайсы законда тәгаенләп күрсәтелә?
3. Журналист өчен кемнәр мәгълүмат чыганагы булып хезмәт итә ала?
4. Чит илләрдәге журналистларының мәгълүмат чыганаклары турында чыгыш әзерләгез.

## *Әдәбият*


Доступ к информации / Авт.-сост.Г.Ю.Арапова, С.И.Кузеванова, М.А.Ледовских. – М.: Престиж, 2006.

Законодательство Российской Федерации о средствах массовой информации / Научный комментарий доктора юридических наук М.А. Федотова. Серия “Журналистика и право”, выпуск 2. — М: Фирма Гардарика, 1996.

Осташевский А. Комментарий к Закону «О СМИ» // Новороссийское агентство журналистских расследований - http://www.novajur.ru/index.php?pid=2\

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.


Эчтәлеккә кире кайтырга!

## *4 нче тема. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм реклама*

***“Реклама турындагы” федераль закон.*** 1995 елгы “Реклама турындагы” федераль закон кабул ителгәнгә ун елдан артык вакыт үтеп киткәннән соң, бу законда ачылган “ак таплар”, үз вакытында ачыкланып бетелмәгән проблемалар, шулай ук законны әйләнеп узу мөмкинлекләре тагын да калкурак булып күренә башлады. Реклама күләме дә артты, ул торган саен остарак, хәйләкәррәк булырга өйрәнде, еш кына аудиториядә ризасызлык уянуга да сәбәпче булды.

Шуңа күрә әле 2004 елда ук бер төркем Дәүләт Думасы депутатлары, төгәлрәк әйткәндә, Ю.Н.Волков, В.Р.Мединский, В.Я.Комиссаров, В.Г.Драганов, Ю.Г.Медведев һәм А.А.Кармеев Дума каравына “Реклама турындагы” законның яңа проектын тәкъдим иттеләр. Әлеге проект тикшерү барышында шактый гына үзгәрешләргә дучар булды һәм 2006 елның 22 февралендә парламент тарафыннан кабул ителде.

Законнын максаты – намуслы көндәшлек һәм кулланучыларның намуслы һәм дөреслеккә туры килгән рекламага булган хокукларын тормышка ашыру шартларында товар, эш һәм хезмәт күрсәтү базарын үстерү.

Әлеге законны кабул иткәндә үк ул реклама эшчәнлеген көйләүнең нәтиҗәлелеген арттыру юнәлешендә барлыкка килде, чөнки ул реклама базарының бүгенге көн үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән, шул сәбәпле рекламаны кулланучылар, реклама эшчәнлеге субъектлары һәм дәүләт арасында балансны тәэмин итә ала, дип белдерелде.

Законның эчтәлегенә килсәк, ул рекламага куела торган төп таләпләрне ачыклый, аны тарату алымнарын билгели, аерым төр товар рекламасына булган таләпләрне аерып күрсәтә.

Ул алты бүлектән, 40 маддәдән тора. Беренче бүлектә гомуми положениеләр урын алган, төп төшенчәләргә аңлатма бирелә, төп таләпләр күрсәтелә.

Әлеге закон, искесе кебек үк, үз кысасына сәяси рекламаны кертми.

***Рекламага бәйле хокук өлкәсендәге төп төшенчәләр.*** Массакүләм мәгълүмат чараларында реклама урнаштыру мәсьәләләренә кереп киткәнче, шул өлкәдә кулланыла торган төп төшенчәләрне ачыклап китү урынлы булыр.

***Реклама*** – ул рекламаланган объектка игътибарны юнәлтү, аңа карата кызыксыну формалаштыру һәм саклау, базарда аның алга этәрелүенә тәэсир ясау максатыннан һәм төрле алымнар ярдәмендә, төрле формада һәм төрле чаралар кулланып таратылган, алдан билгеле булмаган һәм чиксез сандагы кешеләргә адресланган мәгълүмат (законның 3 нче маддәсе).

***Реклама бирүче*** дип аны җитештерү, урнаштыру, тарату өчен кирәкле мәгълүматка ия юридик яки физик зат, аның чыганагы атала. ***Реклама җитештерүче*** – радио, телевизион, элемтә каналлары, эфир вакытына бәйле техник чаралар кулланып, рекламаны урнаштыру һәм тарату белән шөгыльләнүче юридик яки физик зат. Ә ***рекламаны кулланучылар*** исә реклама җиткерелеп, шуның нәтиҗәсендә тәэсир ителә торган юридик һәм физик затлар була.

Рекламага бәйле очракларны тикшергәндә “товар”, “хезмәт”, “идея” төшенчәләренә дә билгеләмә бирү таләп ителә. “Товар” үзе “эш” һәм “хезмәт” дигәннәрне колачлый. ***Эш*** – нинди дә булса әйбер тудыру өчен башкарылган эшчәнлек төре, шөгыль. Ә ***хезмәт*** – бер затның икенчесенә файда китерү максатында башкарганнары була. ***Товар*** – кыйммәте булган, алмашу, сату-алу юлы белән җәмгыятьтә бүленә торган, хезмәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйбер. Ә ***идея, башлангычлар*** дигәндә, “концепция”, “уйлап чыгару” күздә тотыла.

Бу төшенчәләрне шулай аерып билгеләүнең әһәмияте зур. Ул, әйтик, теге яки бу белдерүне реклама дип бәяләргәме-юкмы икәнлеген ачыклаганда ярдәмгә килергә мөмкин. Мисал өчен, бер кешенең документларын югалтуы турындагы белдерүе реклама була алмый.

Элеккегесе белән чагыштырганда, законның яңа варианты нәфис фильм яки телетапшырулар вакытында артык игътибарны җәлеп итми генә берәр товарны рекламалауны үзенең контрольдә тотарга тиешле булган чикләреннән читкә чыгара.

Россия законнары белән тыелган товарларны (мәсәлән, махсус хезмәтләр куллана торган радиостанцияләр) һәм эшчәнлекне (дәүләт бүләкләрен, порнографик басмаларны сату һәм алу) рекламаларга да ярамый. Реклама көчләү теләге, агрессия, паника уятмаска,

кешеләрнең физик сәламәтлегенә зыян китерерлек куркыныч эшләргә сәбәпче булмаска, табигатьне саклау турындагы законнарны бозмаска тиеш.

***Массакүләм мәгълүмат чараларында реклама тарату.*** Законның икенче бүлеге рекламаны телевидение, радио яки газета-журналларда тарату ысулларын билгели.

14 нче маддә телевидениедә реклама паузасының вакытын 4 минутка кадәр чикли. Дөрес, дүрт минутлык рекламаның нәтиҗәлелеге югалганын аңлап, реклама блогын, гадәттә, кыскарак вакытлы итеп ясыйлар.

Законның 14, 15, 39 нчы маддәләре телевидениедә реклама вакытын тәүлекнең 15 проценты күләмендә генә була алуын билгели, радио рекламасы өчен бу элеккечә 20 процент булып кала

2008 елның 1 гыйнварыннан законның тагын бер моменты гамәлгә керде: телерекламаның күләме бер сәгать эчендә дә 15 проценттан да артыграк вакытны, димәк, 9 минуттан да артыкны алып торырга тиеш түгел. Бу чикләүләргә шул каналның телетапшырулар турындагы мәгълүматлары керми. Ягъни гадәти реклама блогының башында яки ахырында күрсәтелгән шундый телеанонслар кайчакта блокның вакытын күпкә арттырып җибәрә.

Хәзер 15 минуттан да озынрак булган һәм балалар өчен, мәгариф юнәлешендәге программаларны реклама белән бүләргә мөмкин. Закон проектын әзерләүчеләр әлеге адымны балалар өчен кыйммәтле тапшыруларны сатып алу яки эшләтү өчен мөмкинлекләр күбрәк барлыкка килү белән аңлата.

Спорт ярышларын, әгәр алар туры эфирда барса, реклама белән бары тик уеннарның тәнәфесләрендә генә бүләргә ярый. Дөрес, шул ук вакытта, андый тәнәфесләр булмаса, мәгълүмат югалуга китермәгән очракта, ярышны реклама белән бүләргә мөмкинлек турында да әйтелә (14-15 нче маддәләр).

Россия Федерациясендә матәм көне дип игълан ителгән көннәрдә теле- һәм радиопрограммаларда реклама тарату тыелган.

Газета-журналда бастырылган реклама барлык мәйданның 40 процenttан артыгын алып торса, ул реклама басмасы дип атала, бу юнәлеше аның чыгарылыш турындагы мәгълүматларында да күрсәтелергә тиеш.

***Аерым төр товарларны рекламалау үзенчәлекләре.*** Законның өченче бүлеге аерым төр товарларны рекламалау очракларына ачыклык кертә. Аның нигезендә, исерткеч эчемлекләр, тәмәке, сыра кебек товарларны газеталарның беренче һәм ахыргы полосаларында, журналларның беренче һәм ахыргы битләрендә, тышлыкларында рекламалау тыелган.

Алкоголь һәм тәмәке продукциясе рекламасында хәзер һәр очракта да аны күп итеп куллануның зыяны турында кисәтү булырга тиешлеге искәртелә. Ул кисәтү реклама мәйданының кимендә 10 процентын алып торырга тиеш.

Шунысын да әйтеп китик, законның 22 маддәсе телевидениедә һәм радиода исерткеч эчемлекләр һәм тәмәкене рекламалау гомумән тыелганлыгы, ә сыраны бары тик кичке 22.00 нан иртәнге 7.00 гә кадәр генә (радиода төнге 24.00 сәгатьтән иртәнге 9.00 га кадәр) рекламаларга рөхсәт бирелгәнлеге турында сөйли.

Дарулар, медицина техникасы кебек товарларны рекламалауга таләпләрнең хәзер кырыслануын билгеләп үтү кирәк. Аерым алганда, андый реклама, әгәр гадәти кулланучыларга адресланган булса, киңәшләр бирүче медицина хезмәткәрләре образын файдаланмаска, табибка мөрәҗәгать итмичә генә дәваланып була дигән ялгыш фикер тудырмаска, сәламәт кешедә дә дару куллану теләген барлыкка китермәскә тиеш.

Шунысы да бар, андый рекламаларда әлеге даруны куллануга каршы килерлек сәбәпләр барлыгы, шулай ук инструкциясе белән танышу яки белгеч консультациясе алуның кирәклеге турында мәгълүмат та булырга тиеш.

Биологик актив матдәләр өчен дә үз чикләүләре бар. Хәзер рекламада аларны дару буларак тәкъдим итү, шулай ук дәвалау сыйфатлары бар дип күрсәтү һәм дәваланган очракларны мисал итеп китерү тыелган (25 нче маддә).

Кызганычка каршы, әлеге законда аңлашылып бетмәгән моментларның барлыгы турында белдерә галимнәр. Мәсәлән, элеккеге вариантта “телепрограмма” дигән төшенчә юлдаш һәм кабель каналлары аша килүче теләсә кайсы тапшыруга да карый иде. Ә хәзер “телепрограмма” дигәндә, кабель каналларны аша таратыла торган тапшырулар истә тотылмый. Димәк, телетапшыруларда тәмәке һәм исерткеч эчемлекләр рекламасы тыела дигәндә, без кабель каналлары

тапшыруларын күз алдында тотмыйбыз, булып чыга? Шулай булгач, аларда шундый тыелган реклама төрләре барлыкка килгән очракта да закон бозылмаячакмы, дигән сорау куя галимнәр.

***Реклама өлкәсенең дәүләт тарафыннан контрольдә тотылуы.*** Законның 5 нче бүлеге шул мәсьәләгә багышланган. Реклама турындагы законның үтәлешен күзәтүдә тоту бурычы башкарма хакимиятнең федераль органы – Монополиягә каршы көрәш федераль хезмәтенә тапшырылган. Законның 36 нчы маддәсе буенча, әлеге орган тарафыннан ачылган тикшерү эшләрен карау тәртибе РФ Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Реклама турындагы законнарның бозылганлыгы билгеле булгач, бозган зат контрреклама бирергә тиеш. ***Контрреклама*** ул – дөрес түгел рекламаны таратудан килгән зыянны юкка чыгару максатыннан аны кире кагу. Шунысын истә тотарга кирәк: законны бозуның барлык очраклары да контрреклама бирүне таләп итми. Мәсәлән, бер товарны шундый башкалардан аерып куеп, "иң яхшысы", "бары тик ул гына" кебек дөреслеккә туры килмәгән сыйфатлар билгеләнгән булса, мондый реклама кире кагуны таләп итә. Ә менә лицензияләнергә тиешле эшчәнлекне рекламалаганда лицензия номеры һәм лицензияләгән органның исеме күрсәтелмәү контрреклама таләп итми. Контррекламаны законны бозган зат үз исеменнән бирергә тиеш.

Контрреклама бирү турындагы карарны хәзер элеккечә монополиягә каршы көрәш органы түгел, ә шул органның мөрәҗәгате нигезендә, арбитраж суды чыгарырга тиеш. Суд контрреклама урнаштыруның формасын, урынын һәм вакытын да билгели.

## Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. “Реклама турындагы” федераль законның бүлекләре, төп эчтәлеге, максаты нидән гыйбарәт?
2. Рекламага бәйле хокук өлкәсендәге төп төшенчәләргә аңлатма бирегез.
3. Массакүләм мәгълүмат чараларында реклама таратуга төп таләпләр нинди?
4. Аерым төр товарларны (исерткеч эчемлекләр, сыра, тәмәке, дарулар һ.б.) рекламалауның үзенчәлекләре турында сөйләгез.

5. Реклама өлкәсенең дәүләт тарафыннан контрольдә тотылуы нинди орган ярдәмендә тормышка ашырыла?

6. Контрреклама нәрсә ул, нинди максатларда кулланыла?

### *Әдәбият*


Панкратов Ф.Г. Рекламная деятельность: Учебник для студ. высш. и ср. спец. уч. зав-ий / Ф.Г.Панкратов, Т.К.Серегина, В.Г.Шахурин. – М.: Информационно-внедренческий центр «Маркетин», 1998.

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Рихтер А. Что нового в новом законе? (первый комментарий к Федеральному закону «О рекламе») // http://reklama-reg.ru/information/federallaw/comments/

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.


Эчтәлеккә кире кайтырга!

## *5 нче тема. Матбугат ирege һәм кеше хокукларын яклау*

Ирекле булу ни дигән сүз? Массакүләм мәгълүмат чаралары еш кына, үзләре дә сизмәстән, халык арасында тавыш чыгуга, бәхәс кузгалуга, фикер уянуга сәбәпче булып тора, шул рәвешчә, җәмгыять тормышына тәэсир ясый. Мисалга икътисадый яшәешне яктырткан яки әйләнә-тирәнең пычрануы турында сөйләгән язмаларны алыйк. Халык газета битләрендә басылган яки эфирдан яңгыраган теләсә кайсы хәбәр турында озаклап гәп сатарга ярата. Бер нәрсә эшләр хәл дә юк: кешене үз фикерен әйтүдән тыю мөмкин түгел бит.

Шулай булгач, журналист булып эшләүче кешенең һәрбер адымы, авызыннан чыккан һәр сүзе җәмгыять тарафыннан игътибарга алына, тикшерелә, дигән сүз. Гомумән, дөрес эшләсә дә, эшләмәсә дә, журналистның хезмәте һәркөн диярлек тәнкыйть утына тотыла. Моның ни өчен шулай икәнен “Журналист” журналының баш мөхәррире Д.С.Авраамов әйткән сүзләрдән аңлап алырга була: “Үз

һөнәре журналистка җәмгыятьтәге күренешләргә халык исеменнән әхлакый хөкем чыгарырлык хокук бирә”, - дип яза ул.

Менә шул моментта матбугат иреге, журналист иреге дигән проблема килеп туа да инде. Заманында Гегель бу турыда болай дигән: “Ирекне бер нәрсә белән дә чикләнмәгән күләмдә теләсә нәрсә сөйли яки яза алу мөмкинлеге итеп карау белемсез, надан һәм тирәннән фикер йөртә белмәүче карашлар өчен генә яраклы”.

Бүгенге көндә матбугат битләреннән укучы өстенә яңгыр булып яуган тәнкыйть язмалары еш кына шул ялгыш карашларга мисал булып тора. Файда китерүче, җәмгыятьтәге начар күренешләрдән котылырга ярдәм итүче тәнкыйть белән бергә расланмаган, дәлилсез фактлар, түбәнсетүче бәяләмәләр, гражданнарның намусына һәм дәрәҗәсенә зыян салучы  фикерләр дә урын алуы шул турыда сөйли. Сүз дә юк, тәнкыйть дәваларга да, тирән яра салырга да мөмкин. Шуңа да тәнкыйть язмалары укучылар тарафыннан да, журналистлар арасында да объективлык, кыюлык, дөреслек дәрәҗәсе ягыннан, ягъни әхлакый аспекттан тикшерелеп, игътибар үзәгенә алына.

***Журналист иреге турындагы ялгыш фикерләр.*** Матбугат эшчәнлеген буып торучы киртәләр алып ташлау сәбәпле, журналистка күбрәк ирек бирелде. Әмма әгәр журналист үзенең хокуклары турында начар хәбәрдар икән, ул ирек, ирек булудан туктап, башкалар өстеннән үзбелдекле хөкем чыгару коралына гына әверелеп калачак, ирек һавасы, башын әйләндереп, журналистны ялгыш юлга кертеп җибәрәчәк.

Бу урында Россия матбугатында урын алган берничә мисалга тукталып китик. К. фамилияле журналист яшерен генә бер шәхси предприятие эченә үтеп керә. Максаты да изге була үзенең – яхшы гына эшләп килүче җитештерүчеләрнең хезмәт уңышларын күрсәтеп бирмәкче була ул. Материал дөнья күргәч, автор шундый “буш реклама” өчен рәхмәт ишетермен дип уйлаган булса, чынында, предприятие хуҗасы аны, коммерция серен ачуда гаепләп, судка бирергә тели. Тавыш-гауга ярты елга сузыла. Ахырдан судсыз гына килешүгә ирешәләр ирешүен,  әмма авторның гына түгел, газетаның баш мөхәррире белән юридик киңәшчесенең нервыларын җитәрлек тузгыта бу вагыйга.

Тагын бер мисалга тукталыйк. Газетаның хокук бүлеге хәбәрчесе О. суд залыннан репортаж әзерли. Судья һәм утырышчылар карар

чыгару өчен аерым бүлмәгә кереп киткән вакытта, журналист та үзен шунда кертүләрен таләп итә. Таләбен ул карар чыгару механизмы белән танышасы килүе белән аңлата. Әлбәттә, аңа рөхсәт бирмиләр. Шуңа бик нык ачуланган журналист судья турында, массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законны бозып, журналистка һөнәри вазыйфасын үтәргә комачау итте, дигән гаепләү язмасы бастыра. Бу зур гаепләүгә карата озакламый Судлар берлеге һәм Судьяларның югары квалификацион коллегиясеннән җавап алына. Чынлыкта, карар чыгару өчен киңәшү бүлмәсенә судьяның закон буенча чит беркемне дә кертергә хакы юк икән. Шулай итеп, журналистны анда кертмичә ул дөрес эшләгән. Бу җавап гамәлдәге законнардан хәбәрдар булмаган журналистны көлкегә калдырган һәм аның өчен зур сабак та булгандыр, мөгаен.

***Матбугат ирегенең "Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" Законда чагылыш табуы.*** Законның беренче бүлегендәге 1 нче маддәдә үк Россия Федерациясендә, мәгълүмат эзләү, алу, җитештерү һәм тарату; массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую, алардан файдалану; массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен җитештерү һәм тарату өчен кирәкле техник чара һәм җиһазларны, чимал, материалларны ясау, сатып алу, саклау һәм файдалануда, әлеге Законда күрсәтелгәннән кала, башка бер генә тыюларга да дучар ителергә тиеш түгел, диелә. Икенче төрле итеп әйткәндә, Россиядәге массакүләм мәгълүмат чаралары ирекле, Законда күрсәтелгән очраклардан кала, аларны тыярга, кысрыкларга беркемнең дә хакы юк.

Шушы ук бүлектәге 3 нче һәм 4 нче маддәләр дә массакүләм мәгълүмат чараларының иреге турында игълан итә. Әлеге Законга таянып, без шуны әйтә алабыз: Россиядә массакүләм мәгълүмат чаралары өстеннән цензуралык итә торган, басылырга, эфирга чыгарылырга тиешле материалларны алдан тикшерүче махсус кешеләр билгеләп кую, шул максатны тормышка ашырырлык оешмалар оештыру, аларны акча белән тәэмин итеп тору, яшәтү тыела. Әлеге Закон гамәлдә чакта, аерым кешеләр дә, дәүләт тә цензура тикшерүе оештыра алмый.

Дөрес, соңгы вакытларда Россиядә массакүләм мәгълүмат чаралары өстеннән контрольлек итүче цензура оешмасын булдыру турында сүз бара. Анысы массакүләм мәгълүмат чараларының бер

өлешенең артык дәрәҗәдә әхлаксызлана баруы, шуның белән үсеп килүче буынга тискәре үрнәк бирүе аркасында килеп чыккан күренеш. Бер яктан караганда, әхлаксызлык белән көрәш хакына цензура тикшерүе кертелү белән килешергә дә мөмкин кебек. Әмма ул тикшерү әхлакый аспектны гына күз алдында тотачак, дип беркем дә тулы гарантия бирә алмый. Әхлакый нормаларга туры килү-килмәүне генә ачыкларга тиешле цензура органы, кем кулында булуына, кемгә хезмәт итүенә карап, шул “хуҗа”га ошамаган, аңа зыян китергән массакүләм мәгълүмат чараларының да, әхлакый яктан зарарлы дигән булып, иреген буып куярга мөмкин.  Шул сәбәпле прогрессив, алдынгы журналистлар нинди дә булса цензурага каршы чыга. Йомгаклап әйткәндә, әлеге Закон һәм аның 3 нче маддәсе гамәлдә йөргәндә, безнең илдә цензура тыелган эш булып санала.

***Цензура органына карата журналистлар мөнәсәбәте.*** 2003 елның июнендә Түбән Новгород шәһәрендә Идел буе матбугатының III Фестивале уздырылды. Аның беренче көне Идел буе федераль округында масс-медианы үзлегеннән көйли, тәртипкә салырлык махсус оешма булдыруга багышланган конференция белән башланып китте. Шул ук көнне анда катнашучылар белән үз эченә өч сорауны алган блиц-сорашу үткәрелә. Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкиллегенең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, беренче сорау белән Идел буе федераль округында андый массакүләм мәгълүмат чараларының үзлектән тәртипкә салынуын тәэмин итәрлек институтлар оештыру сәгате суктымы дигәнгә, барлык җавап бирүчеләрнең 90 проценты "әйе" дип белдергән. Бу сан бүгенге җәмгыятьтә массакүләм мәгълүмат чаралары өстеннән торырлык, контроль булдырырлык оешма кирәклеге, аннан да бигрәк, ул оешманың журналистларның үзләре тарафыннан ук таләп ителүе турында сөйли. Әмма андый оешманың дәүләт хакимияте органнары каршында оештырылу мөмкинлеге журналистлар тарафыннан кискен каршы килү уята. Шул хактагы икенче сорауга катнашучыларның 85 проценты ул оешма дәүләт канаты астында булырга тиеш түгел, дип җавап биргән. Бу факт журналистларның дәүләт контрольдә тота торган цензура органына каршы булуын ачык күрсәтә дә.

Журналистның мәгълүмат җыю иреге бар, моны кире кагу мөмкин түгел. Әмма шул ук вакытта, әгәр башкаларның хокукларын кысуга, матди һәм әхлакый зыян салуга китерә икән, ул ирек закон

тарафыннан бераз чикләнә төшә. "ММЧ турындагы" Законның 4 нче маддәсе белән журналистка материалларында җинаять җәзасына тартырлык эшләргә өндәү тыела. Мисал өчен, хакимият вәкилләренең законлы таләпләренә каршы килүгә, күп кеше катнашындагы тәртипсезлекләргә чакыру, сугышырга, кемне дә булса кыйнарга өндәү, милләтләр, диннәр арасында нәфрәт уяту журналист өчен әдәп-әхлак нисбәтеннән генә түгел, закон белән тыелган, ят нәрсә булырга тиеш.

Мәгълүмат иреге – демократик дәүләтләр тәэмин итә торган иң төп хокукларның берсе. Ул ирек Халыкара кеше хокуклары декларациясенең 19 нчы маддәсе һәм Кеше хокукларын һәм төп ирекләрне саклау турындагы Европа конвенциясенең 10 нчы маддәсе белән ныгытылган. Соңгысында әйтелгәнчә, һәркемнең үз фикерен ирекле рәвештә белдерергә хакы бар. Ә бу хакимият органнарына һәм дәүләт чикләренә карамастан, һәркемнең мәгълүмат алырга һәм таратырга иреге бар дигәнне аңлата.

Чынлыкта исә закон белән ныгытылган нормалар да үтәлми кала. Кеше хокуклары өлкәсендәге сәясәт буенча халыкара берлекнең (International Council Human Rights Policy) Кеше хокуклары буенча Европарламент комиссиясенә ясаган докладында Россиядәге иң зур сүз ирегенә ия булган төбәкләр исемлегенә Самара, Санкт-Петербург һәм Приморье кертелгән. Ә иң "ирексез" төбәкләр дип Татарстан, Башкорстан, Калмыкия һәм Чечня аталган. Ә Европа буенча караганда, Россия үзе сүз иреге җәһәтеннән Англия һәм Испаниядән соң өченче урында тора икән.

***Башка кешенең намусына тимәү шарты.*** Журналист һәм аның материалларының геройлары арасында килеп чыга торган бәхәсләрнең күпчелеге соңгыларының намусына, хөрмәтле исеменә, дәрәҗәсенә, репутациясенә тиюгә, пычратуга бәйле сәбәпләр аркасында килеп чыга. *Кешенең хөрмәтле исеме* – шәхескә карата җәмгыять биргән бәя, аның рухи һәм социаль сыйфатларының үлчәве ул. Хөрмәтле исем төшенчәсе шәхеснең хөрмәткә һәм горурлануга лаек әдәп-әхлак принциплары, хатын-кызлар өчен сафлык, хөрмәт, дан, иҗтимагый бәя дигәннәрне үз эченә ала. Шәхеснең аннан кала үз-үзен, сыйфатларын, сәләтен, дөньяга карашын, иҗтимагый әһәмиятен эчтән бәяләве, ягъни *дәрәҗәсе* дә бар әле. Менә шул ике төшенчә кешегә карата иҗтимагый кыйммәт итеп карауны тудыра да инде. Кеше җәмгыятьтән башка яши

алмый, шуңа күрә шул җәмгыять вәкилләренең аның турында нәрсә уйлавы, нинди бәя бирүе аңа бик мөһим. Әлеге сәбәп аркасында һәркем дә үзенең җәмгыятьтәге хөрмәтле исемен чиста сакларга өчен тырыша, репутациясен яклый. *Репутация* – хезмәттәшләре, клиентлары, фанатлары, сайлаучылары, кулланучылары, тамашачылары һ.б. каршында шул кешенең шәхси сыйфатлары турында туган фикер, бәя, дигәнне аңлата.

Массакүләм мәгълүмат чаралары бүгенге көндә үзеңнең хөрмәтле исемеңне якларлык та, журналист яки аңа тиңләштерелгән затлар тарафыннан кимсетелә алырлык та иң нәтиҗәле чара булып тора. Кайчакта журналист мәгълүмат иреген ялгыш аңлап, теленә артык ирек биреп җибәреп, үзенең геройларын кимсетергә дә мөмкин. Кайчакта образлы сөйләм куллану нәтиҗәсендә китерелгән чагыштыруларны да геройлар кимсетү дип кабул итәргә мөмкин. Шуңа бәйле көлкеле хәлләр дә килеп чыккалый.

Бервакыт Д. фамилияле журналист бер банкир турында образлы итеп түбәндәгечә яза: “Аны төнлә караңгы почмакта очратырга Ходай күрсәтмәсен. Кулыңда хәйран гына акчаң булса, тартып та алыр ул". Банкир юморны бик шәп аңлый торган кеше булып чыга. Шушы сүзләре өчен журналистны судка бирә һәм, хаклыгын раслар өчен, шаһит итеп суд утырышына үзен төнлә караңгы почмакта очраткан унсигез кешене алып килә. Алар бу банкирның шул караңгы почмакта аларга бернинди дә зыян салмавы турында язма рәвештә раслау бирәләр. Шул унсигезнең тугызы әйтүенчә, үзләре белән зур суммада акчалары да булган. Судка шаһит итеп чакырылган бишесе, имеш, хәтта мактанып, акча янчыгын банкирга селкеп тә күрсәткәннәр икән. Ә банкир, берни дә әйтмичә, алар яныннан тыныч кына узып киткән. Менә шушы шаһит күрсәтмәләре һәм банкирның угрылыгы турындагы сүзләрен раслый алмаганы өчен, суд журналист әхлакый зыян өчен банкирга 50 мең сум акча түләргә тиеш, дигән карар чыгара. Бу акчаны банкир шунда ук Хәбәрдарлыкны яклау фондына күчерә. Әле редакция банкирның угры түгеллеген күрсәтеп кире кагу һәм гафу үтенү дә бастырып чыгарырга тиеш була.

***Кире кагу хокукы.*** Дөрес булмаган мәгълүмат тарату мәгълүмати яссылыкны пычрату гына түгел, аерым бер шартларда хәтта кеше хокукларын бозу дип бәяләнергә дә мөмкин. "ММЧ турындагы" Законның 43-46 нчы маддәләрендә күрсәтелгәнчә, массакүләм

мәгълүмат чараларында урын алган мәгълүмат дөреслеккә туры килмәгән һәм намусына зыян салган очракта, мәгълүматтан файдаланучыларның *кире кагу* белән чыгыш ясау хокукы бар.

Россия Федерациясе Конституциясенең 23 нче маддәсенең 1 нче өлешен дәвам итеп, Гражданлык кодексы, исемен, дәрәҗәсен, репутациясен пычратырлык мәгълүматлар таратылган очракта, таратучы аларның дөреслеген исбатлый алмаса, ул мәгълүматларның кире кагылуын сорап, теләсә кайсы кешегә судка мөрәҗәгать итү хокукы бирә. Гражданлык кодексының 152 нче һәм “ММЧ турындагы” Законның 43 нче маддәләре буенча, әгәр ул мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чарасында таратылган булса, кире кагу да шул ук массакүләм мәгълүмат чарасында басылып чыгарга тиеш. Дөрес, “ММЧ турындагы” закон буенча кеше бары тик редакция кире кагудан баш тарткан очракта гына судка мөрәҗәгать итә ала.

Әлеге закон хәлне судка мөрәҗәгать итмичә генә чишүне төп чара итеп күрә һәм аңа зур әһәмият бирә. Чөнки бу очракта вакыт экономияләнә, кире кагу материалының басылып чыгу вакыты озакка сузылмый, суд чыгымнарын түлисе булмый, суд органнарына да эш азрак була. Шунысы да бар: кире кагу басылган икән, ул кеше судка мөрәҗәгать итә алмый инде, гәрчә әхлакый зыян өчен компенсация таләп итә алса да.

Судка мөрәҗәгать итү “ММЧ турындагы” Закон буенча материал басылып чыкканнан яки эфирда яңгыраганнан соң бер елдан да соңга калмый башкарылырга тиеш. Ә менә Гражданлык кодексы вакытны чикләп куймый. Югыйсә, андый очракта күп еллар үткәч, хәтта автор, шаһитләр, дәлилләр юкка чыккач та судка мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек кала бит. Ә бу һәрвакытта да дөреслекне раслау шарты булып тормаячак. Гражданлык кодексының судка мөрәҗәгать итү хокукын бу мәсьәлә белән кызыксынган кешеләргә дә бирүе андый аңлашылмаучанлыклар өчен тагын бер нигез булып тора, дип саный хокук белгечләре.

“ММЧ турындагы” Закон исә андый кешеләр һәм очраклар мөмкинлеген төгәл күрсәтә. Ул бары тик исеме пычратылган кешенең законлы вәкилләре (балигъ булмаганнарның ата-анасы, уллыкка алучылары һәм опекуннары) мөрәҗәгать итсә һәм гражданның үзенең кире кагуны таләп итү мөмкинлеге булмаса гына рөхсәт ителә. Төгәлрәк итеп әйткәндә, мөрәҗәгать итүнең бу формасыннан балигъ

булмаганнар, тулаем яки өлешчә акылга зәгыйфьләр генә файдалана ала. Кеше үлгәч исә инде аның вәкилләренең дә әлеге мәсьәләне күтәрергә хокуклары бетә, дигән сүз. Ә менә Гражданлык кодексының 1 нче маддәсенең 2 нче өлеше кешенең үлеменнән соң да аның исемен һәм абруен яклауга рөхсәт бирә һәм моны сорап теләсә кайсы кеше судка мөрәҗәгать итә ала дип саный.

Ике закон арасындагы менә шундый каршылыклар, эш судта карала калса, ике төрле итеп нәтиҗәләр чыгарырга мөмкинлек бирә дә инде. Мәсәлән, Карл Маркcның шәхесен яклауны сораган мөрәҗәгать кабул ителмәгән, чөнки мөрәҗәгать итүче аның белән бер нәселдән икәнлеген раслый алмаган. Ә икенче бер очракта суд, аның белән туганлык дәрәҗәсен дәлилләүче фактларны да сорап тормыйча, Сталинның исемен яклауны сораучының гаризасын тикшерүгә кабул иткән.

Кире кагу очракларында фактлар һәм фикерләрне аерып кую мәсьәләсенә дә игътибар ителә. Фикерләр – уй, идея, күзаллаулар алар. Алар нигездә субъектив була, шул сәбәпле фактлар төрле юллар белән дәлилләнә алса да, фикерләрне дәлилләп булмый, дип хисапланыла. Россия Федерациясе Конституциянең 29 нчы маддәсе кемне дә булса үз фикерләре һәм ышануларыннан кире кайтару максаты белән үгетләүне тыя. Димәк, суд журналистка үз фикереннән кире кайтуын да таләп итеп куя алмый.

***Кире кагу текстына таләпләр.*** Гражданны кимсетү басылып чыккан яки яңгыраган массакүләм мәгълүмат чарасында суд карары белән яки ике якның үзара килешүе нәтиҗәсендә таратыла торган кире кагу текстына килик. Аны чыгару авторның да, баш мөхәррирнең дә бурычы түгел, бу вазыйфа тулаем алганда редакция өстендә. Әгәр исеме кимсетелгән дип саналган кеше кире кагу текстын үзе тәкъдим итә икән, нәкъ шул текст басылып чыгарылырга тиеш тә.

Әлеге текстта чынбарлыкка туры килмәгән нинди мәгълүматның кайсы массакүләм мәгълүмат чарасы тарафыннан, ничек һәм кайчан таратылуы турында күрсәтү таләп булып тора. Шунысы да бар: әгәр бу текст массакүләм мәгълүмат ирегеннән үз файдаңа куллану өчен бирелсә, аноним булса һәм үз көченә кергән суд карарына каршы чыкса, аны бастырырга ярамый.

Кире кагуны таратуның үз вакыты төгәл билгеләнгән. Атнасына кимендә бер тапкыр булса да чыга торган массакүләм мәгълүмат

чараларында кире кагу аның текстын редакциягә кабул итүдән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, калган очракларда инда әзерләнеп килүче яки иң якындагы киләсе чыгарылышта таратылырга тиеш.

Кире кагу тексты өстенә “Кире кагу” дигән баш исем куела. Аның тексты кире кагыла торган мәгълүмат белән бер үк төрле шрифтта басыла; хәбәрдәге кире кагыла торган мәгълүмат фрагментыннан ике тапкырдан да зуррак күләмдә була алмый; кире кагу текстын машинка язуы белән бер биттән дә ким итәргә, дигән таләп куярга да ярамый. Әлбәттә, фрагмент дигәндә кимсетүле фикер яңгыраган һәм фамилия аталган җөмлә генә күз алдында тотылмаганын аңларга кирәк, фрагмент авторның шул кешегә кагылышлы барлык фикерләрен үз эченә ала.

Аудиовизуаль массакүләм мәгълүмат чаралары өчен үз таләпләре бар. Аларда кире кагу көннең кире кагыла торган хәбәр яңгыраган вакытында тапшырылырга тиешле. Машинка язуы белән бер биттән дә кимрәк текстны укып чыгар өчен кирәк булган вакыттан да кимрәк вакыт бирү дә дөрес түгел.

Әгәр бер-бер башка сәбәп белән массакүләм мәгълүмат чарасы ул мәгълүматны алданрак кире кагып куйган булса, тагын бер кире кагу басылып чыга алмый. Кире кагу тексты мәгълүмат басылып чыгып яки эфирда яңгырап бер елдан артык вакыт үткән булса кабул ителми. Кире кагыла торган фрагменттан ике тапкырга зуррак булган очракта да редакция аны таратудан баш тарта ала.

***Җавап бирү хокукы.*** “ММЧ турындагы” Законның 46 нчы маддәсе таратылган мәгълүмат мыскыл итү, кимсетү булмаса да, чынбарлыкка туры килмәгән һәм гражданның законлы хокукларын кыскан очракта да кешенең намусын яклау механизмын күз алдында тота. Ул *җавап бирү* дип атала. Чынбарлыкка туры килмәгән мәгълүмат тарату дигәндә, мәсәлән, эш фактик хаталарда булырга мөмкин. Ә хокукларны бозу очрагы материалда фактларны, әһәмиятле мисалларны махсус төшереп калдырудан гыйбарәт була ала. Җавап бирүгә бәйле кагыйдәләр кире кагу нормалары белән тәңгәл килә.

***Гайбәт һәм мыскыллау очраклары.*** Гражданнарның намусына кагылышлы килеп туган бәхәсләр хокукый-гражданлык чаралары белән генә түгел, хокукый-җинаять чаралары белән дә тәртипкә салына. Россия Федерациясенең Җинаять кодексы гайбәт һәм мыскыллау өчен җаваплылыкны билгели. Гайбәт белән дөреслеккә

туры килмәгән мәгълүмат арасындагы аерма нәрсәдән гыйбарәт соң? Беренчедән, *гайбәт* тарату аның баштан ук ялган икәнлеген алдан белүне күздә тота. Икенчедән, җинаять эше кузгатылган очракта, гайбәт тараткан кеше аның чынбарлыкка туры килүен раслау бурычыннан азат ителә. Киресенчә, судка ул мәгълүматның чынбарлыкка туры килмәвен һәм гаепләнүченең бу хакта алдан ук белүен дәлилләү бурычы салына.

Ә *мыскыллау* дигәндә, журналист тарафыннан икенче бер кешенең намусын һәм исемен, махсус алдан уйлап, массакүләм мәгълүмат чарасында әдәпсез рәвештә түбәнсетү аңлашыла. Әдәпсез рәвештә дигәнне дә аерым аңлатып узу мөһим. Әдәпсез сүзләр шул җәмгыять нормаларына бәйле рәвештә карала. Ул нигездә сүгенү сүзләрен үз эченә ала, тупас әйтелә. Хәтта кайчакта эпитетлар да мыскыллау сүзе буларак кабул ителергә мөмкин. Мәсәлән, Белгород өлкәсенең бер районында чыгып килүче "Наша жизнь" газетасының мөхәррире тәнкыйть мәкаләсендә җирле үзидарә җитәкчесенең эш позициясен "гайбәтче һәм тамак яргыч позициясе" дип язганы өчен алты айга төзәтү эшләренә хөкем ителә.

Журналистларның гамәлдәге законнарны белеп бетермәве аркасында килеп туган бер очрак белән танышыгыз әле.

Казахстанның «Взгляд» газетасы хәбәрчесе Ю.Кузнецова, ике кешене башка берәүне үтерүдә гаепләү эше буенча редакция биреме белән суд тикшерүен яктыртырга китә. Ул җинаять корбанының хатыны белән сөйләшә, хатын гаепләнүчеләрнең туганнары тарафыннан үзенә янаулары, кимсетүләре, күрсәтәмәләр бирүдән баш тартырга мәҗбүр итәргә тырышулары турында сөйли. Шулар тәэсирендә журналист күңелендә бер картина туа башлый. Һәм тикшерү барышында җыелган материалларны туплаганнан соң, документларда ул ике кешегә каршы җитәрлек фактлар тупланганын белеп, материалында аларны "үтерүче" дип атый. Әмма тикшерү эше шуның белән бетми, берничә ел дәвам итә, бер-бер артлы суд утырышлары була, ә ахырдан бөтенләй туктатыла... Дәүләт гаепләүчесе һәм гаепләүче кешенең үз сүзләреннән баш тартуы аркасында килеп чыга бу. Әмма журналист шулай килеп чыгасын алдан кайдан белсен?! Прокуратура һәм милиция закон кысаларында эш йөртә, бары тик гаепле кешене генә рәшәткә артына утырта, гаепле дип кулга алганнар икән, димәк, алар - гаепле, үтерүче, дип уйлаган

бит ул. Бер караганда, шулай кебек, әмма икенче яктан караганда, суд тикшерүе чыкканчы кемне дә булса гаепле дип атау тыела. Әлеге журналист шулай икәнлеген белми калган да инде. Белгән булса, газетасы редакциясен теге ике кешенең намусына зыян салган өчен дип 30 мең сум түләтүдән котылдырып калган булыр иде[3]!

***Шәхси тормышның кагылгысызлыгын бозу.*** РФнең Конституциясе 23 нче маддәсендә һәркем өчен шәхси тормышның, шәхси һәм гаилә серенең, хат язышу, телефоннан сөйләшү, почта, телеграф һәм башка хәбәрләрнең кагылгысызлыгын билгели. Журналистлар бу серләрне бөтенләй дә тарата алмыйлар дигән сүз түгел, әмма аларны халык игътибарына тәкъдим итүнең үз шартлары, кагыйдәләре бар. Иң әһәмиятле шарт – аларны таратыр өчен иясенең шәхси ризалык бирүе. Ул ризалыкны кеше үзе яки законлы вәкиле (балигъ булмаган бала булса) бирә ала. Мәгълүматны тарату җәмгыять ихтыяҗлары өчен кирәк булса, ризалык таләп ителми. Әмма җәмгыять ихтыяҗларының хокук белеме тарафыннан бирелгән махсус билгеләмәсе булмаганга күрә, мәсьәлә эшне тикшерүче кеше кулында кала. Әлбәттә, кешенең дәүләт яки иҗтимагый эшчәнлеге белән бәйле мәгълүматларны тарату өчен аның ризалыгы таләп ителми.

Бу турыда без ябык мәгълүмат төрләре, аерым алганда, конфиденциаль серләр турында сөйләшкәндә, бер сүз башлаган идек инде.

Кешенең шәхси тормышы турындагы мәгълүматларны законсыз рәвештә туплаган, аның ризалыгыннан башка массакүләм мәгълүмат чарасында тараткан очракта һәм, бу эшләр журналистның яман уе аркасында килеп чыгып, гражданнарның хокукларына һәм законлы ихтыяҗларына зыян салган булса, журналист алты айга кадәр ирегеннән мәхрүм ителергә мөмкин.

“ММЧ турындагы” Законда (49 нчы маддәнең 1 нче өлеше) журналист тарафыннан фото-, кино-, видеосурәтләрне теләсә ничек файдаланудан яклау да каралган. Андый язмалар ясар алдыннан ризалык сорау таләп ителә. Дөрес, яшерен камера куллану да мөмкин хәл, әмма моның үз шартлары бар.

Беренче шарт – Конституцияне бозмау, ягъни сурәтләр ахырдан берничек тә шәхеснең хөрмәтле исемен, дәрәҗәсен пычрата дип табылмау.

[3] http://medialaw.kz/index.php?r=22&c=382

Икенче шарт – җәмгыять ихтыяҗларын яклау өчен кирәк очракта һәм очраклы рәвештә кадрга эләккән вакыйгага катнашы булмаган кешеләрне танырга мөмкин булмау.

Өченче шарт – яшерен камерага төшерү суд карары белән башкарылу.

Гамәлдә моның тагын бер төре кулланыла. Башта яшерен рәвештә камерага төшереп, ахырдан бу хакта төшерелгән кешегә әйтелсә һәм ул каршы булмаса, язма массакүләм мәгълүмат чараларында күрсәтелә ала. Монысы кешене көлке хәлдә калдыра торган тапшырулар әзерләүче иҗатчылар өчен аеруча мөһим.

Балигъ булмаганнарны яклау максатыннан, “ММЧ турындагы” Законның 41 нче маддәсенең 3 нче өлеше кырысрак таләпләр куя. Җинаять ясаган яки эшләүдә шик булган, административ хокук бозган яки җәмгыятькә каршы  эш эшләгән балигъ булмаган үсмерләрнең исеме бары тик үзләренең яки законлы вәкиле ризалыгы белән генә күрсәтелергә мөмкин. Әлеге кагыйдә җинаять корбаны дип табылган балигъ булмаган үсмерләрнең исемен күрсәтүгә дә кагыла.

***Этник журналистика һәм этник мәгълүмат.*** Бүгенге көндә бөтен дөньяда халыкларның этник үзаңы уяну күзәтелә. Ягъни җәмгыятьтә, кешеләр арасында яшәгәндә, кайсы милләттән булуыңның әһәмияте үсә бара. Бу күренеш күпмилләтле Россиядә аеруча нык таралган. Мөгаен, моңа сәяси вакыйгалар мәгълүм күләмдә тәэсир итми калмыйдыр. Нәкъ менә журналистлар, массакүләм мәгълүмат чаралары халык аңында милләтләргә кагылышлы фикерләр, күзаллаулар формалаштыручы булып тора. Шуңа да милләтләргә кагылышлы нинди генә сүз язса да, журналист үзалдына аның аудиториягә ясаячак этник тәэсире нинди булыр, дигән сорау куярга тиеш.

Массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмгыять тормышы турында сөйләгәндә, әлбәттә, аның аерым милләтләргә кагылган өлкәләре турында язмый калмыйлар. Моннан кала да теләсә кайсы материалның герое бер милләт вәкиле була, нindидер детальләр аркылы вакыйгаларның эчке бәйләнешләрен бирү, фикерне символлар аркылы җиткерү максатыннан, журналист ул этник сыйфатны махсус кулланырга мөмкин. Милләтләргә кагылышлы темаларны яктыртучы журналистика *этник журналистика* дип атала. Ә тормышның аерым бер милләтләргә караган яклары турындагы мәгълүмат *этник*

*мәгълүмат* була. Аны конкретрак күз алдына китерик. Этник мәгълүмат текстында түбәндәге сүз, төшенчә, билгеләмәләрне очратырга була:

этнонимнар, ягъни милләт атамалары (урыс, татар, грузин, чечен, чукча, америкалы...);

милли-административ төбәк һәм ил атамалары (Татарстан, Украина, Кытай, Германия...);

“милли”, “милләт” сүзләре;

илләр һәм республика башкалалары, аерым бер милләткә караган символлар һәм кыйммәтләр.

Төрле мәгълүмат каналлары аркылы аудиториягә барып җитә торган этник мәгълүмат уңай, тискәре яки нейтраль булуы турында укучылар, тыңлаучы яки тамашачылар үзләре дә чамалый. Ул хисси яктан да төрле, әйтик, тыныч яки соклану, горурлык яки ачулануы, гаепләү яки кызгану хисләре белән җиткерелергә мөмкин. Уңай һәм нейтраль этник мәгълүмат журналистның төрле милләт вәкилләре, аларның яшәү рәвеше, матди һәм рухи мәдәнияте, милли геройлары һәм бүгенге билгеле шәхесләре турында сөйләвендә урын ала. Мондый мәгълүмат халыкта үз милләте белән горурлану тойгысы уятырга, башка милләтләргә карата уңай мөнәсәбәт тудырырга ярдәм итә, белем дәрәҗәсен үстерә. Әлеге мәгълүматларга нигезләнгән махсус басмалар да чыга. Мәсәлән, “Жизнь национальностей”, “Этносфера”, “Новый Вавилон” кебек журналлар төрле халыкларның милли тормышы, яшәү рәвеше, милли проблемалары белән таныштырып тора, уңай яки нейтраль этник мәгълүмат белән тәэмин итә. Андый мәгълүматлар журналистикага белем бирү һәм күңел ачу, ял иттерү функциясен үтәргә ярдәм итә.

***Этник түземлелек.*** Кешелек әле бер, әле икенче халыклар арасында гасырлар буе дәвам иткән сугышлардан туеп, XX гасырда күп мәдәниятле, күп милләтле бу дөньяда үзара килешеп, бер-береңә түземле булып яшәүнең өстенрәк булуына төшенде. Шул сәбәпле Берләшкән Милләтләр Оешмасы төзелде дә. Барлык күпсанлы һәм азсанлы милләтләрнең тигез хокукка ия булуы аның Уставы белән ныгытылган. Россия Конституциянең 19 нчы маддәсе дә илнең һәр кешесенә, җенесе, милләте, расасы, теленә карамыйча, бертигез хокуклар гарантияли. Ә 29 нчы маддә социаль, расаара, милләтара һәм

динара нәфрәт, дошманлык уятырлык пропаганда яки агитация алып баруны тыя.

*Этник түземлелек* башка милләт һәм раса вәкилләренә карата сабыр, түземле, килешүчән мөнәсәбәттә булу дигәнне аңлата. Ул – демократик җәмгыятьтә тыныч яшәүнең бер шарты булып тора.

Этник түземлелекне журналистларның эшчәнлеге белән бәйләнештә караганда, аларның эш принциплары кешеләрне теге яки бу милләткә яки расага караган өчен кимсетмәүгә, аларга карата хаксыз, ваемсыз, игътибарсыз булмауга нигезләнә, өстәвенә, журналистлар үзләренең укучылары, тыңлаучы-караучыларына да шул принципларны төшендерергә, шулай яшәргә өндәргә тиеш, дип санала. Тиеш булса да, журналистлар арасында алай эшләмәүчеләр дә бар. Моның сәбәпләре, беренче чиратта, законнарның ахыргача үтәлмәве, икенчедән, соңгы елларда Россия җәмгыятендә төгәл әхлакый ориентирларның югалуы белән бәйле.

***Тискәре этник мәгълүмат.*** Андый мәгълүматны кешелексез дип атау да дөрес булыр. Чөнки ул массакүләм мәгълүмат чараларында башкаларны кимсетүгә нигезләнгән. Ә мондый мәгълүмат, үз чиратында, җәмгыятьтә ызгышлар китереп чыгаруга сәбәп булырга мөмкин. Без башкалардан үзебезгә, милләтебезгә, телебезгә карата уңай мөнәсәбәт таләп итәбез икән, үзебез дә шундый ук мөнәсәбәтне сакларга тырышырга тиешбез.

“ММЧ турындагы” Законның 4 нче маддәсе массакүләм мәгълүмат чараларын явыз ният белән куллану очраклары исемлегенә аларны милләт, дин төрлелеге аркасында үзара түземсезлек, килешмәүчәнлек китереп чыгару өчен файдалануны да кертә. Ә 51 нче маддә белән исә журналистка милләте, расасы, теле аркасында аерым бер яки зур төркем кешене кимсетү максаты белән мәгълүмат таратуны тыя.

Массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы тискәре, ызгыш уятырлык этник мәгълүмат тарату очракларына тукталыйк. Мисал өчен, журналист вокзалда булган вакыйга турында хәбәр иткәндә, “аңлашылмаучанлык, тәртипсезлек килеп чыгуда милиционер, такси йөртүче һәм чегән хатыны гаепле” дип яза. Менә бу этник түземсезлеккә мисал инде. Журналист “милиционер, такси йөртүче, эшсез” дип язмаган бит, “урыс, татар, чегән” дип тә куймаган. Димәк, бу очракта чегән халкын кимсетерлек мәгълүмат бирелгән.

Рус телле матбугатта “лицо кавказской национальности” дигән сүзтезмәнең ялгышлыгын да искәртеп үтәргә кирәк. Кавказда нинди генә милләт яшәми, аларның барысын бергә җыеп, бер кушма милләт ясау кебегрәк килеп чыга бит бу!

Аудитория аңына шундый мәгълүмат белән беррәттән этник идеяләр дә ирештерелә. “Бу милләт бик тырыш” яки “теге милләт бик кунакчыл” дигән идеяләр уңай дип атала. Әмма матбугатта аларга капма-каршы мәгънәдә яңгырый торганнары да очрый. Журналист шундыйлардан качарга тиеш, монысы бәхәссез.

Өстәвенә, этник темаларга язарга алынган журналист шул өлкә белән яхшы таныш булырга, фикер йөртә белергә дә тиеш. Мәсәлән, Түбән Новгород шәһәрендә 2003 елны төнге клубларда татарча дискотекалар оештырыла башлый. Шул уңайдан, төбәктәге кайбер массакүләм мәгълүмат чаралары алар турында "мөселман дискотекалары" дип язып чыга. Хәтта андый егетләр һәм кызлар бергә була торган чараларда катнашу Шәригать кануннарына каршы килә, димәк, мөселманнарга анда булырга ярамый, дигән мәгълүмат тә таратыла. Менә бу мәгълүмат этник мәгълүмат төренә карый да инде. Әмма ул турыда хәбәр иткән журналистлар "татар" белән "мөселман" төшенчәләрнең тәңгәл килмәвен белмәгәннәр, шуның белән этник темаларга язар өчен үзләренең әзерлексез икәнлекләрен күрсәткәннәр булып чыга. Шуның аркасында укучылар арасында да аңлашылмаучанлыклар килеп туарга, Исламның төп мәгънәсенә төшенүдә ялгышлар да килеп чыгарга мөмкин иде бит.

***Мәгълүмати экология.*** Мәгълүмат иреге турында сүз башланган икән, аңа бәйле рәвештә *мәгълүмати экология* төшенчәсен дә карап китәргә кирәктер. Мәгълүмат экологиясе проблемасы хокук өлкәсендә беренче тапкыр 1993 нче елда кузгатыла башлады, анда Россия Федерациясе Президентының “Мәгълүмати тотрыклылык гарантиясе һәм телерадиотапшыруларга таләпләр турында” карары чыкты. Бу карарда телерадиотапшыруларның мәгълүмати чисталыгын арттыру, культура дәрәҗәсен күтәрү турында сүз алып барыла.

“Мәгълүмати экология”, нигездә, журналист вазыйфаларын үтәүгә салкын карау, массакүләм мәгълүмат чарасының аудиториясе, закон һәм һөнәри коллектив каршында җаваплылык сизмәве аркасында бозыла.

Икенче сәбәп – мәгълүмат биргән кешенең анык чыганагын күрсәтү таләбен, беренче тапкыр халыкка чыгарылса, цитатаның авторын күрсәтү шартларын үтәмәү.

Өченче сәбәп – журналистның үзе әзерләгән материалның киләчәктә суд белән бәйле бәхәсләр китереп чыгарачагын белә торып, бу хакта баш мөхәррирне кисәтеп куймау.

Барлык бу сәбәпләр дә законны үтәмәүдән килеп чыккан, дип хисаплана.

Дөрес, "мәгълүмати экология" бозылуның сәбәбе махсус алдан әзерләнгән, максатчан эшчәнлек нәтиҗәсе дә булырга мөмкин. Бу исемлеккә "кара пиар", "компромат түгү" кебек эшләр керә. Әмма боларның тамырларын журналистикадан түгел, ә сәясәт, икътисад өлкәсеннән, криминаль структураларга бәйләп эзләргә кирәк.

***Мәгълүмати экологияне бозган очраклар.*** Аңа социаль, раса, милләт, динара нәфрәт һәм низаглар китереп чыгарырга сәләтле мәгълүмат; сугышка чакыру; нәфрәт, дошманлык, башкалардан өстенлекне пропагандалаучы мәгълүмат; порнография; кешеләрнең намусына, исеменә, репутациясенә зыян салучы; намуссыз, тикшерелмәгән, әхлаксыз, күрә торып ялган мәгълүмат, яшерен реклама; психикага тәэсир ясаучан мәгълүмат; дәүләт һәм конфиденциаль серләрне таратучы; сайлау алды агитациясе кагыйдәләрен бозучы һ.б. мәгълүматлар керә.

Мәгълүмати пычраклык арасында зур урынны иҗтимагый әхлак нормалары белән каршылыкка керә торган материаллар һәм хәбәрләр алып тора. Россия Федерациясе Конституциясе 55 нче маддәсенең 3 нче өлешендә әхлакны анык хакына кеше хокуклары һәм иреге федераль законнар белән чикләнә алырлык кыйммәтләр исемлегенә керткәннәр. Чынбарлыкта исә массакүләм мәгълүмат чараларында әхлак өчен көрәш бүгенге көндә порнография, интим хезмәтләр турындагы реклама белән көрәшүгә генә кайтып кала. Совет чорында цензура гамәлдә булганга, газет-журнал битләрендә бер шартларда да ялангач тән сурәте басылып чыга алмый иде. Инде соңгы 15-20 елда бер чиктән икенчесенә ташландык: "тыелган җимеш" массакүләм мәгълүмат чараларын тутырды.

"ММЧ турындагы" Законның 4 нче һәм 37 нче маддәләре нигезендә, массакүләм мәгълүмат чараларында порнографияне пропагандалаучы материаллар чыгару, шулай ук порнографик

материаллар һәм предметларны законсыз ясау, рекламалау, тарату максатында файдалану тыела.

37 нче маддә үзенчә порнографик һәм эротик эчтәлектәге материалларны аерып куя кебек. *Эротик материаллар* – секска карата гомумән алганда һәм системалы рәвештә кызыксыну уята торган материаллар, диелә анда. Әмма бу җитәрлек дәрәҗәдә конкрет булмаган аңлатма үзләренең массакүләм мәгълүмат чараларында сексны төп тема итәргә планлаштырган гамәлгә куючыларга зур ирек бирә. Аның ярдәмендә алар үзләренең басмаларын тиз генә законлаштырып куйдылар. Андый продукцияне бары тик шуның өчен махсус көйләнгән, дини оешмалар, балалар учреждениеләреннән еракта урнашкан урыннарда, үтә күренмәле һәм ябыштырылган пакетларга салып кына сатарга рөхсәт ителүгә карамастан, җирле хакимиятләр моның шулай эшләнмәвенә күз йомып килсәләр.

“ММЧ турындагы” Законның 37 нче маддәсе эротик теле- һәм радиотапшыруларның эфирга чыгу вакытын да тәгәлләп күрсәтә: төнге 11 дән иртәнге 4 кә кадәр. Әмма бу категориягә кермәгән, әмма эчендә эротик эпизодлар кертелгән программалар да булла бит . Тулаем эротик эчтәлектә булмагач, алар 37 нче маддәдә күрсәтелгән таләпләрне үтәргә тиеш түгел. Тик мондый тапшырулар кич, бөтен гаилә белән җыелып телевизор карый торган вакытта эфирга чыга. Мисалга ТНТ каналыннан барган “Цена любви”, “Запретная зона” тапшыруларында андый эпизодлар шактый очрады. Әмма аз гына булса да эротик фрагментлар кертелгән тапшырулар өчен дә махсус тыюлар барлыкка килергә мөмкин.

Тагын шундый проблема бар: фахишәлек белән шөгыльләнүче притоннар тоту Россия Федерациясе Җинаятьләр кодексының 241 нче маддәсе белән тыела. “ММЧ турындагы” Законның 4 нче маддәсе исә массакүләм мәгълүмат чараларын җинаять җаваплылыгына тартыла торган эшләр өчен файдалануны тыя. Димәк, фахишәлек рекламалары бастыру да тыела. Кызганычка каршы, барлык массакүләм мәгълүмат чаралары да бу законга тугрылык сакламый.

Массакүләм мәгълүмат чараларында норматив булмаган лексика, гади итеп әйткәндә, сүгенү сүзләре куллану да әхлаксызлык дип бәяләнә.

***Массакүләм мәгълүмат иреген явыз ният белән файдалану.*** “ММЧ турындагы” Законның 4 нче маддәсе массакүләм мәгълүмат

ireген явыз ният белән файдалануның өч төрен аерып күрсәтә. Болар - массакүләм мәгълүмат чараларын җинаять җаваплылыгына тартылырлык эшләр өчен, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләрне пропагандалау максатында кулану, массакүләм мәгълүмат чараларында халык аңына тәэсир итәрлек яшерен вставкалар кертүдән гыйбарәт.

Җинаять җаваплылыгына тартылырлык эшләр турында сүз алып барылганда, закон дәүләт яки башка серләрне тарату, хакимиятне яулап алырга, дәүләтнең конституцион төзелешен һәм тулылыгын көч кулланып җимерергә чакыру, милли, классара, социаль, дини нәфрәт уяту, сугышны, шулай ук порнография, көчләү һәм явызлык культын пропагандалауны аерым күрсәтә.

***Журналистларның үз хокукларын явыз ният белән файдалану очраклары.*** Журналист үз хокукларын иҗтимагый әһәмияткә ия мәгълүматларны яшереп калдыру яки уйлап чыгару; имеш-мимешләрне расланган хәбәр итеп тарату; чит кеше яки массакүләм мәгълүмат чарасы булмаган башка оешма өчен мәгълүмат җыю максаты белән кулланган булса, ул хокукларны явыз ният белән файдаланган, дип хисаплана. Шулай ук аңа үзенең мәгълүмат тарату хокукын башка максатта - җенесе, яше, раса яки милләте, теле, дингә мөнәсәбәте, һөнәре, яшәү һәм эшләү урыны, сәяси ышанулары аркасында аерым бер граждан яки гражданнар категориясен мыскыллау өчен файдалану тыела.

Россия Федерациясе Президенты каршында оештырылган Мәгълүмати бәхәсләр буенча суд палатасы андый очракларны даими тикшереп тору нәтиҗәсендә, соңгы елларда журналистлар өчен *тыюлар* исемлеген төзеп килә. Аңа түбәндәгеләр керә:

кораллы каршы тору очрагын милләтара дошманлык яссылыгына күчереп аңлату, аерым бер милләткә карата тотрыклы тискәре мөнәсәбәт формалаштыру;

максатчан рәвештә бер милләтнең башкалардан өстенлеге хисен формалаштыру;

сайлау алды агитациясе вакытында аерым бер милләткә хас гореф-гадәтләр, ышануларга гына мөрәҗәгать итү;

шул мәсьәләдә үз кызыксынуы булган кешене “бәйсез” комментатор итеп чакыру;

җинаятьләр турындагы язмаларда игътибарны җинаятьчеләр һәм аларның корбаннарының милләтенә юнәлтмәү, чөнки артык игътибар җинаятьчелекнең чын сәбәпләре турында объектив һәм тулы булмаган күзаллау формалаштыра;

дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең милли бертөрлелеге принцибында төзелгән исемлекләр бастырмаска.

Тыюлардан кала, Палата конфликтлы ситуацияләрне тикшерүче журналистлар өчен мәҗбүри кагыйдә дә кертте. Ул мәгълүмати паритет булдыру таләбе дип атала һәм, капма-каршы ике якның беренчесенә сүз бирелгән очракта, икенчесенә дә шул ук мөмкинлекне тудырудан гыйбарәт.

***Массакүләм мәгълүмат чарасын явыз ният белән файдаланган өчен җаваплылык.*** Законның үтәлеше даими тикшерелеп, күзәтелеп барылсын өчен, периодик басмалар һәр чыгарылыш тиражының бер данәсен үзләрен теркәгән органга бушлай җибәреп барырга тиешләр. Әгәр редакция 12 ай буе ике яки аннан да күбрәк тапкыр югарыда аталган 4 нче маддә таләпләрен бозып, шул турыда аны теркәгән органнан кисәтү хатлары алган икән, теркәүче органның судка мөрәҗәгать итү мөмкинлеге бар. Анда әлеге массакүләм мәгълүмат чарасының эшчәнлеген туктату мәсьәләсе каралачак. Редакцияләрнең теркәүче орган чыгарган кисәтүләрнең дөрес түгеллеген раслап кабат тикшертү хокукы да бар.

Күп очракларда ул кисәтүләр массакүләм мәгълүмат чараларында милли, дини һәм социаль низаг китереп чыгару максатыннан язылган материаллар басылып чыкканнан соң ясала.

Еш кына теркәүче органнар материалның тулаем эчтәлегенә, мәгънәсе, юнәлеше, идеясенә, аның аерым кешеләрнең һәм коллектив аңына ясарга мөмкин булган тәэсирен анализласы урынга, төп игътибарны аның эчендәге төп эчтәлектән аерып каралган фразаларга һәм сүзләргә бирәләр. Әлбәттә, андый хаталардан азат булыр өчен, тикшерүгә квалификацияле экспертларны җәлеп итәргә кирәклеге аңлашыла.

4 нче маддә таләпләрен бозган өчен җаваплылыкка тарту очракларына мисал итеп, Мытищи районара типографиясе белән булган очракны китерергә була. Биредә экстремистларның фашизм идеяләрен таратуга чакыручы “Русская правда” һәм “Русский хозяин”

дигән таблоидлары бастырыла. Моның өчен типография ике тапкыр кисәтелә һәм ахырда лизенциясе алына.

***Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм журналистлар җаваплылыктан котылып кала торган очраклар.*** “ММЧ турындагы” Законда андый очраклар шактый теркәлгән. Аңлашыладыр, беренче һәм кире каккысыз очрак булып журналист тараткан мәгълүматның чынбарлыкка туры килүенә һәм анда законга каршы бернәрсә дә булмавына дәлилләр тәкъдим итү тора. Әмма сүз материаллардагы фактлар түгел, ә журналист биргән бәя турында бара икән, мондый дәлилләр китерү кыенлаша.

Саклану чарасы сыйфатында журналист Законның 57 нче маддәсен корал итеп алырга мөмкин. Анда күрсәтелгәнчә, әгәр журналист яки редакция бастырып чыгарган ялган һәм кемгәдер зыян сала торган мәгълүмат:

мәҗбүри хәбәрләр эчендә булса (мәсәлән, суд карары буенча бастырылган текст),

мәгълүмат агентлыгыннан килсә,

сорауга җавап итеп, хакимият органнары материалларында булса,

депутат, делегат яки башка шуның кебек затларның рәсми чыгышларыннан сүзгә-сүз күчереп алынса,

эфирга алдан яздырмыйча, турыдан-туры эфирга чыгарылган автор әсәрләрендә яңгыраса,

башка массакүләм мәгълүмат чарасында чыккан мәгълүматның сүзгә-сүз күчермәсе булса,

редакция яки журналистка акланып калырга мөмкинлек туа.

Бер сүз белән әйткәндә, әгәр редакция яки журналистның ул ялган мәгълүматны ни алдан махсус уйлап, ни ваемсызлык аркасында таратмавы расланган очракта, ул җаваплылыктан азат ителә. Шул ук вакытта дөрес булмаган мәгълүмат таралуга юл куйган журналист исә җавабын бирергә тиеш.

## Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. "ММЧ турындагы" Закон ирек төшенчәсен нинди кысаларга кертә?
2. Бүгенге көндә журналист эшчәнлеген әхлакый контрольдә тотучы орган кирәк, дип саныйсызмы?

3. Башка кешенең намусына тимәс өчен, журналист нинди таләпләргә буйсынып эшләргә тиеш?

4. Кире кагу һәм җавап бирү текстына таләпләр турында сөйләгез.

5. Шәхси тормышның кагылгысызлыгы нәрсә ул? Аны бозган очракларга массакүләм мәгълүмат чараларыннан мисаллар эзләгез.

6. Этник журналистика, этник мәгълүмат төшенчәләренә аңлатма бирегез.

7. Россия законнарының этник мәгълүматка мөнәсәбәте нинди?

8. Тискәре этник мәгълүмат төрләренә массакүләм мәгълүмат чараларыннан мисаллар китерегез.

9. Мәгълүмати пычраклык нәрсә ул, аның килеп чыгу сәбәпләре нәрсәдә?

10. Мәгълүмати экология бозылуның нинди төрләрен беләсез?

11. Россия Федерациясе Президенты каршында оештырылган Мәгълүмати бәхәсләр буенча суд палатасы мәгълүмат ирегеннән явыз ният белән файдалануның нинди төрләрен билгели?

12. Журналист нинди очракларда җаваплылыктан азат ителә?

13. Башта үз уку төркемегездә, аннары танышларыгыз, күршеләрегез арасында түбәндәге анкета сорауларына җаваплар алыгыз, аннары нәтиҗәләр ясарсыз.

*Анкета өчен сораулар*

1. Сез массакүләм мәгълүмат чаралары (газет-журнал, радио, телевидение) сөйләгән сүзләргә ышанасызмы? Ни өчен?

2. Массакүләм мәгълүмат чараларының максат һәм бурычлары нидән гыйбарәт (сезнең фикер)?

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән чынлыкта кем идарә итә, алар кем кулында, “кем җырын җырлый”, дип уйлыйсыз?

4. Сезгә ничә яшь, һөнәрегез?

## ***Әдәбият***

Гражданский Кодекс РФ (Часть 4) от 18.12.2006 N 230-ФЗ (принят ГД ФС РФ 24.11.2006) // http://www1.fips.ru/wps/wcm/connect/content_ru/ru/documents/russian_laws/codeks_rf/gkrf_ch4

Европейский Суд по правам человека и защиты свободы слова в России: прецеденты, анализ, рекомендации. - М.: Институт проблем информационного права. - Т.1, 2002; Т.2, 2004.

Конституция Российской Федерации. Научно-практический комментарий / Под. ред. Б. Н. Топорнина. 3-е изд. - М.: Юристъ, 2003.

Комментарий к Уголовному кодексу Российской Федерации / Отв. ред. В. М. Лебедев- 3-е изд., доп. и испр.. - М.: Юрайт-издат, 2004.

Кудрявцев М. А. Право СМИ в современной России: проблемы и перспективы // ЗиП. - 1999.- № 3. - С. 11-18.

Право на информацию: российское законотворчество о СМИ в 1999-2000 гг. в контексте западноевропейских стандартов свободы слова. - М.: Институт проблем информационного права, 2001. - С. 7-241.

Правовые проблемы индустрии СМИ // ЗиП. -2002.-№ 6. - С. 3-8.

Прохоров Е. П. Свобода СМИ и журналистской деятельности на демократических принципах. - М.: Пульс, 2001.

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Рихтер А . Г. Свобода массовой информации на постсоветском пространстве. - М.: Издательство «ВК», 2007.

Свобода выражения мнений в Европе: Судебная практика применения статьи 10 Европейской конвенции по правам человека. - Страсбург: Совет Европы, 2007.

Свобода самовыражения, свободный поток информации, свобода средств массовой информации: Основные положения СБСЕ/ОБСЕ, 1975-2007. - Вена, 2007.

Судебная палата по информационным спорам при Президенте Российской Федерации: 1994–1996. Нормативные акты. Практика. Комментарии / Под ред. А.Б. Венгерова. М., 1997.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М. А. Право массовой информации в Российской Федерации. - М.: Междунар. отношения, 2002.

Эчтәлеккә кире кайтырга!

## *6 нчы тема. Журналист хокуклары һәм бурычлары*

***Журналист хокуклары һәм бурычларының өч төркемгә бүленүе.*** Массакүләм мәгълүмат чаралары халыкны аны кызыксындырган һәрбер күренеш, вакыйга, очрак, хәл хакында тулы һәм төгәл мәгълүмат белән даими һәм оператив рәвештә тәэмин итеп торырга тиеш. Ә журналист исә шул мәгълүматны белергә, аңларга һәм үзенең белүен һәм аңлавын халык казанышы итәргә хокуклы. Россия Федерациясе Конституциясенең 29 нчы маддәсенең 4 нче өлешендә һәркемнең мәгълүмат эзләү, алу, тапшыру, җитештерү һәм тарату хокукы бар, диелгән. Димәк, журналист бирә торган мәгълүматның хак һәм дөрес, фикерләренең беръяклы булмавы, ә эшчәнлегенең хакимият яки башка төркемнәр катнашыннан башка алып барылуын таләп итү хокукы һәркемгә бирелгән, булып чыга.

Журналистларның хокуклары һәм бурычлары “ММЧ турындагы” Законның 5 нче бүлегендә чагылыш тапкан.  Аларны шартлы рәвештә өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

Беренче төркемгә журналистның мәгълүмат табу белән бәйле эшчәнлегенә бәйле, икенче төркемгә - мәгълүматны тарату, өченчесенә исә шул мәгълүматны җитештерү һәм массакүләм мәгълүмат чарасын чыгару белән бәйле хокуклар һәм бурычлар тәшкил итә. Аларның кайберләрен без журналист һәм мәгълүмат арасындагы мәгълүмати мөнәсәбәтләрне өйрәнгәндә карый башлаган идек инде.

***Журналистның мәгълүмат табу белән бәйле эшчәнлегенә бәйле хокуклары һәм бурычлары.*** Алданрак туплаган белемнәребезне йомгаклап, беренче төркемгә караган бурычлар һәм хокукларны санап чыгыйк. Алар “ММЧ турындагы” Законның 47 нче маддәсенең 1 нче өлешендә урын алган. Журналистның дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, унитар предприятиеләр, иҗтимагый оешмалар яки аларның матбугат хезмәтләрендә булу, шуларда эшләүче кешеләр белән очрашу хокукы бар. Аңа дәүләт, коммерция һ.б. төрле саклана торган сердән кала, башка мәгълүматлар тупланган документлар белән танышу мөмкинлеге тудырылган. Журналист табигый бәла-казалар, массакүләм тәртипсезлекләр булган һ.б. урыннарга килә ала. Ул тапкан мәгълүматын тикшерергә хокуклы, шул ук вакытта мәгълүмат чыганакларын, мәгълүматның үзен ачмаска бурычлы. Аудио-,

видеоязмалар алып бара калса, бу турыда мәгълүмат бирүче кешеләргә алдан хәбәр итү, таләп ителгән очракта, редакция таныкламасын берсүзсез күрсәтү дә аның бурычына керә.

***Журналистның мәгълүмат тарату белән бәйле эшчәнлегенә бәйле хокуклары һәм бурычлары.*** Аның авторлык яки интеллектуаль милек хокукларын саклау шартларында документ һәм материалларны бастыру, хәбәр итү мөмкинлеге бар. Массакүләм мәгълүмат чарасында үз имзасы белән таралачак материалларда ул үзенең шәхси фикерләрен, фактка карата мөнәсәбәтен белдерә ала. Редакцияләү вакытында аның фикерләренә хилафлык китерелгән дип саный икән, материал астыннан үз фамилиясен алып атарга да хокуклы. Чөнки аның әзерләгән материалларын үз фамилиясе, псевдонимы астында яки имзасыз бастыру хокукы закон белән ныгытылган. Алдагы төркемдә без журналистның эзләп тапкан мәгълүматын тикшерү хокукы бар, дидек. Әмма бу аның хокукы гына булып калмыйча, "ММЧ турындагы" Законның 49 нчы маддәсенең 1 нче өлеше буенча аның бурычына әверелә. Журналист җәмгыять ихтыяҗларын саклау таләп ителгән очраклардан кала, аерым кешеләрнең шәхси тормышы турында мәгълүмат таратырга теләсә, иң элек шул кешенең үзеннән рөхсәт алырга тиеш.

***Журналистның мәгълүмат җитештерү һәм массакүләм мәгълүмат чарасын чыгару белән бәйле хокуклары һәм бурычлары.*** Өченче төркемгә журналистның ышанулары, дөньяга карашлары, уй-фикерләре белән кискен каршылыкка кергән материалны әзерләүдән баш тарта алуы (47 нче маддәнең 1 нче өлеше), хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре белән бәйләнгән редакция уставын үтәү (49 нчы маддәнең 1 нче өлеше), аерым бер материалны бастырганнан соң, аның суд белән бәйле бәхәсләр китереп чыгару мөмкинлеген редакторга алдан ук хәбәр итү һәм, редактор закон белән тыелган эш кушкан очракта, аннан баш тарту шартлары керә.

***Мәгълүматның дөреслеген тикшерү шарты.*** Боларның барысыннан журналистка кирәкле һәм аның һөнәри яктан камиллеген үстерү, һөнәри бурычын үтәү өчен мөһим тагын бер хокукы - үзе тапкан мәгълүматын тикшерү хокукы килеп чыга. Чөнки мәгълүматларның дөреслеген тикшерү өчен еш кына җитәкчеләр яки белгечләр белән очрашып сөйләшү, документлар белән танышу, гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан урыннарда булу таләп ителә дә.

Журналистның үзе тапкан мәгълүматын, бер яктан, тикшерү хокукы да бар, икенче яктан, ул шулай эшләргә бурычлы да, дидек. Бу мәсьәләгә киңрәк тукталу таләп ителә кебек. Журналист – гражданнарның мәгълүмат алуга Конституция белән беркетелгән хокукын тормышка ашыручы кеше ул. Ул – факт һәм мәгълүмат чыганагы белән аудитория арасындагы арадашчы. Журналист теге яки бу вакыйганың шаһите булган очракларда, үзе күргәннәр һәм ишеткәннәр турында түкми-чәчми, яшереп калдырмый чын дөресен хәбәр итәргә бурычлы. Әмма еш кына журналист факт турында башкалардан ишетә. Менә ул очракларда инде ул чыганактан белеп алган мәгълүматның дөреслеген тикшерергә тиеш. Мисал өчен, журналист, бюджет акчаларын ничек тотуларына ачыклык кертүләрен өмет итеп, бер дәүләт предприятиесенә сорау җибәрде, ди. Моңа каршы шул предприятиедән мәгълүмат белән җавап килгән очракта, журналистның бу мәгълүматка ышанмаска һәм аны тикшерергә тулы хокукы бар. Әмма бу аның бурычы түгел.

Бу хокук кайсы очракларда бурычка әверелә соң? Әгәр журналист, факт турында хәбәр иткәндә, кемнән белгәнлеген, ишеткәнлеген сер итеп калдыра икән, ул очракта мәгълүматны тикшерергә бурычлы. Чөнки журналист үз өстенә шаһит ролен ала, һәм, шаһит буларак, аның дөреслеге өчен бары үзе генә җавап бирә. Димәк, журналист бары тик аның үзенең яки редакция исеме астында басылып чыккан мәгълүматның гына дөреслеген тикшерергә бурычлы.

***Аккредитация кагыйдәләре.*** Журналистның дәүләт органнары һәм оешмаларына, предприятие, учреждениеләренә, шулай ук иҗтимагый оешмаларга яки аларның матбугат хезмәтләренә бару хокукы бар. Әлеге хокукны тормышка ашыру өчен, гадәттә, ул оешмалар журналистларны *аккредитацияләү* тәртибен гамәлгә кертәләр. Әгәр теге яки бу журналист аерым бер предприятие тарафыннан аккредитацияләнсә, аны шунда оештырыла торган җыелышлар, башка чаралар булачагы турында алдан ук хәбәр бирәләр, стенограмма һәм башка төрле документлар белән тәэмин итәләр, аудио яки видеоаппаратура кулланганда булышалар, бер сүз белән әйткәндә, андый очракларда журналистның мәгълүматка ирешү юлы кыскара төшә.

"ММЧ турындагы" Законның 48 нче маддәсендә күрсәтелгәнчә, аккредитация кагыйдәләре барлык оешмалар өчен дә бертөсле була

алмый, алар һәр оешма органы тарафыннан үзләренчә урнаштырыла. Редакцияләр, үз журналистларын аккредитацияләүне сорап, гаризалар бирә ала, әмма аларны канәгатьләндерү мәсьәләсе аларның аккредитация кагыйдәләренә туры килү-килмәвенә бәйле. Ә бу кагыйдәләр, үз чиратында, законга туры килергә тиеш.

Беренчедән, алар массакүләм мәгълүмат чарасының ireген яки журналистларның хокукларын кысмаска тиешләр, чөнки мәгълүмат алу, җитештерү һәм тарату, законнар белән тыелган очраклардан кала, башка бернинди кысрыклауларга да дучар ителергә тиеш түгел. Мәсәлән, журналистның махсус белеме, хезмәт стажы булмавы яки шул өлкәдә яхшы белгеч түгеллеген сәбәп итеп аккредитацияләүгә каршы килү законнарны бозу, дип хисапланыр иде. Чөнки бу хәл журналистка мәгълүматка ирешү юлларын чикләп, редакциянең мөстәкыйльлегенә аяк чалачак. Әмма да журналист үткәрелә торган чараның барышына кушылып китсә, аны үзгәртергә тырышса, аны аккредитацияләүдән баш тартсалар да бу хәл дөрес ди саналыр.

“ММЧ турындагы” Законның 61 нче маддәсе аккредитация белән бәйле бәхәсле очракларны суд ярдәмендә чишүне күздә тота. Әгәр редакция теге яки бу оешма турында ул аккредитация кагыйдәләрен боза дип санаса, аны судта каратырга хакы бар. Аккредитацияләнгән журналистның хокукларын бозу очраклары да судта каралырга мөмкин. Мисал өчен, аны утырыш яки киңәшмәгә кертмәсәләр, суд барыннан да кала ябык чара үткәрүнең законлыгын да тикшерергә дә бурычлы.

Журналистны аккредитациядән мәхрүм итү очраклары да судта тикшерелә. Мәхрүм итү нинди очракларда хаклы дип санала соң? Беренчедән, әгәр журналист яки редакция, закон кысаларында төзелгән аккредитация кагыйдәләрен бозса, икенчедән, суд тарафыннан чыгарылган карар белән журналист яки редакция аларны аккредитацияләгән оешма турында дәрәҗәсен төшерерлек расланмаган мәгълүматлар тараткан дип табылса, аккредитациядән мәхрүм итү дөрес, дип санала.

***Мәгълүмат каналлары.*** Журналист барып, мәгълүмат таләп итәрлек урыннарның исемлеген ачыкларга тырышыйк әле. Берәр сорау туа калса, журналист орган-оешмаларның җитәкчеләре яки белгечләре белән очрашып сөйләшә ала. Бу сөйләшүне сорап, редакция тарафыннан язма рәвештә мөрәҗәгать җибәрелсә дә, журналист телдән

генә белдерсә дә, журналистның аерым сорауларга җавап алу хокукы бар. Кабатлап әйтәбез, Закон шундый хокук бирә. Әмма аның бер яклы гына булуын да әйтми ярамый: шул ук җитәкчеләр яки белгечләр журналистны төрле сәбәпләр белән кабул итмәскә дә мөмкин, чөнки Закон аларга журналистны кабул итүне мәҗбүр итеп куймый.

Бу урында Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт хезмәте системасында тәртипне ныгыту чаралары турындагы" указына тукталып китү кирәктер. Әгәр массакүләм мәгълүмат чарасында башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең законнарны, гамәлгә кергән суд карарларын һәм Президент указларын тиешенчә үтәмәүләре турында материал чыкса, башкарма хакимият органнары җитәкчеләре, өч көн эчендә әлеге эшне тикшереп, нәтиҗәләр чыгарырга һәм, ике атнадан да соңга калмый, шул ук массакүләм мәгълүмат чарасына нәтиҗәләрне юлларга тиешләр.

Журналистның табигый бәла-казалар, юл фаҗигаләре, массакүләм тәртипсезлекләр булган һәм гадәттән тыш хәл игълан ителгән урыннарда булу хокукы бар. Моннан кала, ул митинг һәм демонстрацияләрдә катнаша ала. Андый урыннарга үтеп керү "чит кешеләргә" берәр төрле норматив актлар белән тыелган очракта да журналистка киртә булмаска тиеш. Чөнки журналист – чит кеше түгел, ул хезмәт вазыйфаларын башкара. Бу вакытта хокук саклау органнары вәкилләренә журналистның куркынычсызлыгын тәэмин итү бурычы йөкләнә: иҗтимагый бурычын башкарган зат буларак, "ММЧ турындагы" Закон нигезендә әлеге шарт үтәлергә тиеш. Шулай да, аны бәла-казалар булган урынга үткәрмәгән, димәк, һөнәри эшчәнлеген башкаруда каршылык күрсәткән затлар җинаять җаваплылыгына тартыла алмый.

Журналистның табигый бәла-казалар, юл һәлакәтләре һ.б. булган урыннарда эшләвенә чикләүләр була аламы? Закон бу мәсьәләгә берничек тә ачыклык кертми. Мөгаен, ул чикләүләр журналистның һәм башка кешеләрнең тормышы һәм сәламәтлеген саклау юнәлешендә генә алып барылырга мөмкиндер. Ягъни әгәр журналистның андый урыннардагы эшчәнлеге үзенең яки башка берәр затның тормышына яки сәламәтлегенә янаса, аның бу эшчәнлегенә тыю салырга мөмкиннәр.

Гадәттән тыш хәл игълан ителгән территорияләрдә дә журналист бер каршылыксыз хәрәкәт итә ала. "ММЧ турындагы" Законның 47

нче маддәсе журналистларга массакүләм тәртипсезлекләр булган, күп халык җыелган, махсус саклана торган һәм гадәттән тыш хәл игълан ителгән урыннарда булу хокукын бирә.

Бер яктан караганда, әлеге хокук теләсә кайсы вакыйганы халык өчен ачык итә, яшерен серләр калдырмый. Әмма икенче яктан, үз-үзләрен экстремаль рәвештә тоткан кешеләр, террористлар, сепаратистлар материалларның геройларына әверелә, начар үрнәк күрсәтә, бу хәл экстремальлекнең артуына, тәртипсезлек проблемасының тагын да төенләнүенә китерергә мөмкин. Шуңа күрә дә соңгы вакытта самолет куып алып китү, тотыклар алу кебек халыкара террористлык очракларын яктыртучы журналистларның эшчәнлеген көйләүче аерым кагыйдәләр булдыру турында сүз алып барыла да.

***Массакүләм мәгълүмат иреген кысу очраклары.*** Россиянең "Гадәттән тыш хәл турында" һәм "Куркынычсызлык турында"гы законнары, шулай ук президентның аерым бер җирләрдә гадәттән тыш хәл урнаштыруы хакындагы карарлары кысасында массакүләм мәгълүмат ирege кысыла. Ул шул җирдән алынган мәгълүматны алдан цензура аркылы үткәрү, басма продукцияне вакытлыча кулга алу кебек чараларда чагыла. Әле тагын шунда ук аккредитация кагыйдәләре дә хөкем сөрә.

Террорчылык акты турындагы халыкка җиткерәсе мәгълүматның формасы һәм күләмен журналист түгел, ә җәмгыять белән икеарадагы элемтәне тәэмин итәргә тиешле штаб яки оператив штаб җитәкчесе билгели. Терактка каршы үткәреләчәк операциянең тактикасы һәм махсус техник алымнарын ачучы; аның барышына киртә булырлык яки шундагы һәм аннан читтәге кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерерлек; террорчылык һәм экстремистчылыкка өндәүче һәм аны аклаучы; терактка каршы үткәреләчәк операциядә катнашачак махсус бүлекчәләр, аның белән идарә итүче штаб хезмәткәрләре, шулай ук әлеге операцияне үткәрүдә ярдәм күрсәтүче затлар турында сөйләүче мәгълүматны таратырга ярамаганлыгы да кисәтелә.

***Журналистлар һәм суд органнары.*** Белгечләр әйтүенчә, соңгы елларда журналистлар белән суд органнары арасында кискен мөнәсәбәтләр урнаша бара. Хокук сайлаучы органнар элек-электән, мәгълүматны яшереп, аны халыкка чыгарудан качып килде. Шуңа да

хәзер мәгълүмат җитешмәүдән кайчакта дөрес булмаган фактларга таянган криминаль репортажлар, материаллар газета-журналларны күмеп китте. Дөрес мәгълүматка булган ихтыяҗны канәгатьләндерү максатыннан кайчакта редакцияләр суд органнарында үзләрен яшерен рәвештә мәгълүмат белән тәэмин итеп торырлык кешеләр дә булдыргалыйлар. Әмма бу рәвешчә сатып алынган мәгълүмат еш кына берьяклы, субъектив булып чыга.

Әле эшли генә башлаган яшь журналистлар ирек һәм бәйсезлек төшенчәләрен аеруча үз итә. Коллективта җитәкчелеккә бәйле булган яшьләр үз язмаларында булса да иреклe фикерләп калырга омтыла. Нәкъ менә яңа гына журналистлык хезмәтенә тотынган кешеләр язмаларының геройларына кирәгеннән артык бәйләнәләр, тәнкыйть материалларын язуны артык күрәләр. Чөнки шул юл белән популярлык казанырга омтылалар. Чынында шулай килеп чыга да кебек: тәнкыйть сүзләре белән чыгыш ясарга яраткан журналистлар бер-ике ай эчендә бик танылып китәргә мөмкин. Әмма таякның икенче башы да бар бит: шул ике ай эчендә ул шул бер аралашкан кешеләре, геройлары белән башка аралашмас хәлгә килә, аның өчен күп кенә оешмаларның ишекләре ябыла. Мисал өчен, суд залларыннан репортажлар әзерләргә тиешле журналистны шул залларга кертми башласалар, аңа нишләргә кала? Әлбәттә, бу суд органнарында эшләүчеләргә, мәгълүмат бирүчеләргә, язмаларның геройларына ялагайланырга кирәк, дигәнне аңлатмый. Киресенчә, журналист һәрвакытта да объектив булып калырга, фикер йөртә белергә тиеш, әмма материал тыныч, нейтраль тонда әзерләнсә, моннан журналист та, укучылар да отачак кына.

Яшь журналистларга тагын шунысын да истә тоту зарур: суд-тикшерү эшләре белән бәйле хезмәткәрләр, хокук саклау органнарында эшләүчеләр законга нигезләнеп кенә эш йөртә, фикерле, журналистларның материалларын кабул итә. Шуңа да алар хокук саклау өлкәсендә белемсез журналистларның ул темаларга язарга омтылуын бик начар бәяли. Еш кына шул темаларга язучылар хокук органнары хезмәткәрләреннән алган интервьюны хокук өлкәсендә белем туплауга әйләндереп калдыра. Мисал өчен, Үзәк сайлау комиссиясе җитәкчеләреннән еш кына сайлау турындагы законнарда сүзнең нәрсә турында баруы, Конституцион суд рәисеннән “ике-өч сүз белән Конституциянең нәрсә икәнлеген аңлатып бирүен”, ә Югары суд

рәисеннән анда ничә судья эшләве һәм аларның бирегә эшкә каян килүләре белән кызыксынган сораулар бирелә икән. Югыйсә, болар турында законнарны укып карап яки башка әңгәмәдәшләр аркылы да белеп була бит.

Монысы хокук органнары һәм хезмәткәрләре турында язу өчен эшчәнлек оештыруның башлангыч моментлары булды. Гомумән алганда, журналистка хокук саклау органнары белән тыгыз бәйләнештә эш алып барырга туры килгәли.

***Суд таләп иткән материаллар белән таныштыру бурычы.*** Алдагы темаларда карап киткәнебезчә, хәтта суд таләп иткән очракларда да журналист чыганакның кем икәнен ачмыйча сер итеп калдыра ала, дидек. Чыганакның чын исемен күрсәтмәү әхлак кагыйдәләреннән чыгып һәм ул кешенең алга таба да ышанычын, хезмәттәшлек итү теләген җуймас өчен шулай эшләнә. Бер караганда, бу вакытта журналист искиткеч авыр хәлдә кала.

Бу Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә шундый ук әлегә чишелә алмаган проблемаларның берсе булып тора. АКШта, мәсәлән, барлык штатларның яртысында журналистларга чагыштырмача ирек бирерлек һәм сер итеп әйтелгән мәгълүматнең чыганагын ачу-ачмау мәсьәләсен үзе кирәк дип тапканча чишү мөмкинлеген тудырырлык законнар кабул ителгән.

Инде безнең илгә әйләнеп кайтсак, чыганакның исемен ачу ирегe төрле очракларда төрлечә аңлатыла. Әйтик, хокук саклау органнары тикшерү эшен ачар алдыннан башлангыч тикшерү үткәрә. Бу вакытта журналистка мәгълүмат чыганагын ачу бурычы куелмый. Ә инде тикшерү эше ачылган икән, ул чакта инде массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре өстенә тикшерү таләпләрен тулысынча канәгатьләндерү бурычы салына. Чөнки җинаять эшләре тикшерелгәндә, "ММЧ турындагы" Закон көчен югалтып, җинаять-процессуаль законнар гамәлгә керә. Үз чиратларында, тикшерү вәкилләренең редакциядә тентүләр үткәрү, журналист каршы килгән очракта, документларны көч кулланып тартып алу хокуклары барлыкка килә. Әмма шунысы мөһим: тентү һәм документларны алып китү бары тик махсус карар нигезендә генә алып барыла ала. Шаһит буларак судка килмәгән очракларында да журналистны анда мәҗбүр итеп китертергә мөмкиннәр.

Журналистка яшерен мәгълүмат билгеле булса? Тагын бер очракны карап китик. Әйтик, журналистка суд тикшерүенең барышы турында мәгълүматлар билгеле булды, ди. Хәбәрче бу вакытта ул мәгълүматлар белән нәрсә эшләргә хокуклы соң? Иң беренче чиратта, суд тикшерүенең дәүләт серләре белән беррәттән конфиденциаль серләр төркеменә кергәнлеген искә төшерү мөһим. Хәтта бу сер журналистка тикшерүче яки прокурорның язма рөхсәте аркасында барып ирешкән чакта да журналист аны халыкка чыгарган өчен җинаять җаваплылыгына тартылырга мөмкин. Бу турыда журналистны мәгълүматны тапшырганда ук кисәтеп куялар.

Инде шундый очрак булды дип күз алдына китерик: яшерен мәгълүмат журналистка очраклы рәвештә генә килеп эләкте. Мисал өчен, тикшерүче ялгыш әйтеп җибәрде яки журналист автобуста документлар тутырылган папка тапты һ.б. Бу мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чарасында чыгарган өчен журналист җавап тотамы? Дәүләт сере өчен шул серне белгән махсус кешеләр җавап бирә. Фикерләп карасак, аны халыкка чыгарган өчен журналист җаваплы түгел килеп чыга, чөнки бу мәгълүматның тикшерү сере икәнен аңа беркем дә кисәтеп куймаган.

Прокуратура кайбер мәгълүматларны матбугатка чыгарыр өчен журналистка махсус тапшырырга мөмкин, болар исемлегенә интервью, матбугат конференцияләре керә. Ул очракларда аларны халыкка чыгарган өчен журналист җаваплылыкка тартылмый.

***Гаепсезлек шартын саклау.*** Суд карары чыкканчы кешене гаепле дип игълан итәргә ярамый. Аңарчы журналист ул кеше турында "гаепләнүче", "шикле", "тикшерү астында тотылучы" дип кенә әйтә ала, әмма "җинаятьче" дип атарга хакы юк. Судта тикшерелә торган теләсә кайсы вакыйганы да җинаять дип атарга да ярамый. Суд карары чыгарылганчы ук гаепләнүчене җинаятьче дип атаган өчен элегрәк журналистны һәркемне дә тикшерүгә кадәр гаепсез дип тану шартын бозучы итеп таныйлар һәм шуның өчен җаваплылыкка тарталар иде. Әмма соңгы еллардагы тикшеренүләр шундый нәтиҗәгә китерде: журналист гражданнарның ирекләрен һәм хокукларын чикләүче вазыйфасын башкармый. Димәк, ул тикшерүгә кадәр гаепсез дип тану шартын бозучы була алмый. Әмма ул мондый хәл өчен башкача – гайбәт тарату, намус һәм дәрәҗәгә тигән өчен җавап тотачак.

Журналист тикшерүе вакытында кире какмаслык дәлилләр китергән очракта да журналист гаепләнүчене җинаятьче дип атый алмый. Бары шул дәлилләр нигезендә аңа карата гаепләү белдерүе белән чыга ала. Журналист тикшерүләре закон белән тыелмаган да, аерым кысалар белән чикләнмәгән дә. Андый эшчәнлек барышында массакүләм мәгълүмат чаралары белән хокук саклау органнары арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек оештырырга мөмкин.

***Суд утырышларын яктырту.*** Утырыш залында барысы да судья кулында. Законда күрсәтелгән шартларга туры килсә, ул утырышны ябык дип игълан итә ала. Ул чакта башка гадәти кешеләр кебек үк журналистлар да утырыш залына кертелмәячәк. Әмма Россиядә суд утырышлары нигездә ачык алып барыла, карар халык алдында игълан ителә. Димәк, журналист өчен башка бернинди чикләүләр дә була алмый. Журналистны утырышка кертү-кертмәү мәсьәләсен бары тик судья гына карый, залда сак вазыйфасын үтәүчеләр бу хокукка ия түгел. Судья утырыш вакытында фотога, кино яки видеога төшерүне тыярга да мөмкин. Әмма блокнотка язып баруны тыя алмый. Германия, АКШ кебек илләрдә суд утырышларында фотога төшерергә ярамый, шуңа да аларда суд репортажлары фотолар белән түгел, рәсемнәр белән генә бизәлә. Журналистның тыйганнан соң да залда яшерен рәвештә фотога яки видеога төшереп утыруын күреп алсалар, аны шунда ук чыгарып җибәрәчәкләр. Инде күрми калсалар да файдасы юк, чөнки ул язманы күрсәтергә яки бастырып чыгарырга да ярамый: шулай эшләгән очракта журналистны җавапка тартачаклар.

## Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. Журналистларның хокуклары һәм бурычлары шартлы рәвештә нинди өч төркемгә бүленә?
2. Мәгълүматны тикшерү хокукы һәм бурычы нәрсә ул?
3. Аккредитация кагыйдәләре турында сөйләгез.
4. Журналистка мәгълүмат алу өчен нинди мәгълүмат каналлар була?
5. Массакүләм мәгълүмат иреген закон белән кысу очраклары буламы?
6. Гаепсезлек шарты нәрсә ул? Ул журналистка нинди таләпләр куя?

7. Журналист белән суд органнары һәм хезмәткәрләре арасындагы мөнәсәбәттә төп принциплар турында сөйләгез.

***Әдәбият***

Европейский Суд по правам человека и защиты свободы слова в России: прецеденты, анализ, рекомендации. - М.: Институт проблем информационного права. - Т.1, 2002.; Т.2, 2004.

Конституция Российской Федерации. Научно-практический комментарий / Под. ред. Б. Н. Топорнина. 3-е изд. - М.: Юристъ, 2003.

Комментарий к Уголовному кодексу Российской Федерации / Отв. ред. В. М. Лебедев- 3-е изд., доп. и испр.. - М.: Юрайт-издат, 2004.

Комментарий к ФЗ “О средствах массовой информации” // http://prozakon.su/a50?id=33709

Лукашева Е.А. Права человека. Учебник для вузов / Е.А.Лукашева. – М.: Инфра-М, Норма, 2003.

Право на информацию: российское законотворчество о СМИ в 1999-2000 гг. в контексте западноевропейских стандартов свободы слова. - М.: Институт проблем информационного права, 2001. - С. 7-241.

Правовые проблемы индустрии СМИ // ЗиП. - 2002. - № 6. - С. 3-8.

Прохоров Е.П. Введение в теорию журналистики: Учебник для студентов вузов / Е.П. Прохоров – 7-е изд., испр. и доп. − М.: Аспект Пресс, 2009.

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Свобода выражения мнений в Европе: Судебная практика применения статьи 10 Европейской конвенции по правам человека. - Страсбург: Совет Европы, 2007.

Свобода самовыражения, свободный поток информации, свобода средств массовой информации: Основные положения СБСЕ/ОБСЕ, 1975-2007. - Вена, 2007.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.

Федотов М. А. Право массовой информации в Российской Федерации. - М.: Междунар. отношения, 2002.

Эчтәлеккә кире кайтырга!

## *7 нче тема. Журналист сайлаулар вакытында*

***Хакимият органнары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары.*** Дәүләт белән массакүләм мәгълүмат чаралары арасындагы бәйләнеш проблемасы ике аспектта карала. Беренчедән, иҗтимагый-сәяси система массакүләм мәгълүмат чараларыннан башка яши алмаячак, икенчедән, массакүләм мәгълүмат чаралары дәүләтнең демократик үсешенә кирәкле шарт булып тора. Алар икесе дә гамәлдәге иҗтимагый-сәяси системаның яшәешен тәэмин итеп торалар. Массакүләм мәгълүмат чаралары закон чыгару һәм башкарма хакимият югарылыгында дәүләт өчен әһәмиятле мәсьәләләрне чишүдә катнаша, аларның үтәлешен тикшерүгә ала, җәмгыять һәм дәүләт торышы турында төп мәгълүмат бирүче чара булып тора.

Әлеге сәбәпләр аркасында массакүләм мәгълүмат чараларын "дүртенче хакимият" дип атаганнарын күп ишеткәнегез бардыр. Әйе, анда хакимиятнең өч тармагының чалымнары да бар, әмма массакүләм мәгълүмат чаралары аларның бер өлеше була алмый.

Массакүләм мәгълүмат чаралары, сүз дә юк, ил җитәкчесен һәрвакытта игътибарда тоталар. Билгән вазыйфасыннан кала, аның матбугат, радио, телевидение өчен тагын бер кызыклы ягы бар, ул да булса, Президентның конкрет кеше, шәхес булуы. Аның җиңүләре һәм җиңелүләре, һәр адымы, әйләнә-тирәсендәгеләренең үз-үзен тотышы укучы, тыңлаучы, тамашачы өчен сериал кебек кызыклы. Гомумән, журналистика нигездә аерым кешене үзәккә куярга ярата бит, Президент шәхесе турындагы мәгълүматларның матбугат, радио, телевидениедә күренүе шул сәбәпле игътибарны үзенә юнәлттерә дә.

Бу уңайдан АКШ Президенты булган Ф.Д.Рузвельт тәҗрибәсен мисалга китерик. Аның "Камин янындагы әңгәмәләрен" телевидение аша гел тапшырып торганнар. Соңрак әлеге тапшырулар һәм гомумән алганда телевидение әлеге кешенең уңай имиджын тудырырга ярдәм итте, дип табылган.

Президент белән массакүләм мәгълүмат чаралары арасындагы элемтә еш кына аның матбугат секретарьләре аша алып барыла.

Матбугат, радио, телевидение белән үзара мөнәсәбәтләр Президент өчен генә түгел, дәүләт механизмы вәкилләренең барысы өчен дә, хәтта җирле үзидарә органы өчен дә кирәк. Россиядә бу уңайдан туган проблемаларның берсе булып чиновникларның халык белән, ягъни массакүләм мәгълүмат чаралары белән аралаша белмәве тора. Мәгълүмат белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итмәү шуннан килеп чыга.

Закон чыгару белән шөгыльләнүче органга да массакүләм мәгълүмат чараларының ярдәме кирәк. Шуңа да алар арасындагы үзара хезмәттәшлек үсә бара. Парламент утырышларының һәръяклап телевидение аша күрсәтелүе шул хакта сөйли. Парламент вәкилләре дә журналистлар белән элемтәгә торган саен күбрәк тартыла. Ул элемтә, беренче чиратта, аларның сайлаучылар белән якынайтса, икенче чиратта, танылуга ирешү дә аларны үз округларында позицияләрен ныгытуга ярдәм итәчәк.

***Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм сайлаулар.*** Массакүләм мәгълүмат чараларының сайлауларда катнашуы ике як өчен дә һәм гамәли, һәм теоретик әһәмияткә ия, дип санала. Сайлауларда катнашып, массакүләм мәгълүмат чаралары берничә төрле функция үти. Алар халыкны мәгълүмат белән генә тәэмин итеп калмый, сайлау алды агитациясе чарасы да, халык тарафыннан сайлауларны контрольдә тоту коралы булып та тора.

Сайлаулар вакытында массакүләм мәгълүмат чаралары һәм журналистлар “ММЧ турындагы” Законнан кала, түбәндәге законнарга таяналар:

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнаша алуына төп гарантияләр турындагы” Закон,

2005 елның 18 маенда кабул ителгән “Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына депутатлар сайлау турындагы” Закон,

2003 елның 10 гыйнварында чыккан “Россия Федерациясе Президентын сайлау турындагы” Закон.

Алар барысы бергәләп, Россия Федерациясе Конституциясе (32 нче маддә) белән ныгытылган сайлау хокукларын тормышка ашырырга хезмәт итә.

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнаша алуына төп гарантияләр турындагы” Законның 3 нче маддәсендә күрсәтелгәнчә, сайлауларга барлык халык өчен гомуми, тигез шартларда үтү шарты куелган. Икенчедән, сайлау комиссияләренең эшчәнлеге хәбәрдарлык рухында алып барылырга тиеш. Кандидатлар фондларына яки банкларга  кергән һәм тотылган акчалар турында әлеге комиссияләргә ачык хисаплар бирергә тиеш. Кандидат турында массакүләм мәгълүмат чарасында материал басылып чыккан очракта, аның кайсы кандидат фондыннан түләнүе күрсәтелү мәҗбүри.

Массакүләм мәгълүмат чаралары сайлаулар максатында сайлау комиссияләре, җирле үзидарә органнары һәм теркәлгән кандидатлар тарафыннан файдаланыла ала. Куллану рәвеше мәгълүмат тарату һәм акчага яки бушка басма мәйдан, эфир вакыты белән тәэмин итеп торудан гыйбарәт. Мәгълүмат тарату басылып чыгу, хәбәр итү һәм яктырту рәвешендә була ала. Мисал өчен, сайлау булачагын билгеләү шул турыда карар чыкканнан соң биш көннән дә соңга калмый бастырылып чыгарылырга тиеш. Һәм нәкъ шул басылып чыккан көннән сайлау алды компаниясе башлана, дип санала да.

Сайлау комиссияләренең үз матбугат органнары булмау сәбәпле, алар биргән мәгълүмат дәүләт катнашында оештырылган яки бюджеттан финанслана торган газета-журналларда бушка бастырылып чыгарылырга тиеш.

***Сайлау вакытында массакүләм мәгълүмат чараларын классификацияләү.*** “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнаша алуына төп гарантияләр турындагы” Законының 47 нче маддәсе беренче чирата *“вазыйфа йөкләтелгән” массакүләм мәгълүмат чаралары* төркемен аерып чыгара. Аңа түбәндәге телерадиокомпанияләр һәм басма орган редакцияләре керә:

гамәлгә куючылары дәүләт органнары, оешмалары һәм учреждениеләре булганнар,

сайлауларга хәтле бер ел эчендә барлык тоткан акчаларының 15 проценттан да ким булмаган өлешен дәүләт хакимияте яки җирле үзидарә органнары бүлеп бирелгән.

Әлеге категория массакүләм мәгълүмат чаралары арасында басма һәм аудиовизуаль, шулай ук гомумроссия, төбәк һәм җирле төрләре була.

Сайлау алды компаниясе вакытында әлеге чаралар түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

теркәлгән кандидатларга сайлау алды агитациясен бертигез шартларда үткәрүне тәэмин итү;

сайлау комиссияләренә басма мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеген бирү (атнага бер һәм аннан да күбрәк чыга торган гомумроссия һәм төбәк басмаларында – атналык басма күләменең йөздән бер өлешеннән дә аз булмаска тиеш);

сайлаучыларга мәгълүмат җиткерү өчен сайлау алды комиссияләрен эфир вакыты белән тәэмин итү (гомумроссия телерадиокомпанияләре – атна саен кимендә 15 минут, төбәк телерадиокомпанияләре – кимендә 10 минут);

теркәлгән кандидатларга бер үк шартларда бушлай эфир вакытын бирү (гомумроссия телерадиокомпанияләре – сайлауларга кадәр 30 көн дәвамында эш көннәрендә берәр сәгатьтән дә ким түгел, төбәк телерадиокомпанияләре – 30 минуттан да ким түгел);

теркәлгән кандидатларга агитация үткәрү өчен түләүле эфир вакытын, бушлаеннан кимрәк итмичә, әмма аннан ике тапкырга да артмаслык итеп бирү. Ул вакыт өчен түләү бәяләре сайлаулар билгеләнгәннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарылырга тиеш. Һәр кандидатның вакыты барлык билгеләп куелган вакытны кандидатлар санына бүлеп табыла;

теркәлгән кандидатлар биргән материалларны бастыру өчен түләүсез матбугат мәйданын бүлеп бирү;

басмада түләүле мәйдан күләмен алдан билгеләп кую. Ул бушлай бирелә торган мәйданнан азрак та, ике тапкырдан артыкка күбрәк тә була алмый;

сайлау фондларына акча керү һәм аларның тотылуы турында Үзәк сайлау комиссиясеннән килгән мәгълүматларны бастыру.

Икенче зур төркемне *“тайпылучы” массакүләм мәгълүмат чаралары* тәшкил итә. Болар – сәяси темага катнашмаучы, дәүләтнеке

яки анықы булмаган махсуслашкан массакүләм мәгълүмат чаралары. Алар сайлауларда берничек тә катнашмаска уйлыйлар икән, сайлау алды агитациясе материалларын бастырудан баш тарта алалар.

Дөрес, беренче чиратта, махсуслашкан массакүләм мәгълүмат чаралары дигәндә, нәрсә күз алдында тотылуы төрлечә аңлатылуына тукталырга кирәк. “ММЧ турындагы” Законда реклама һәм эротик материалларга юнәлдерелгән, балалар, яшүсмерләр, инвалидлар өчен, шулай ук белем бирү һәм мәдәни-агарту максатына хезмәт иткән массакүләм мәгълүмат чаралары махсус төшенчәсенә карый. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнаша алуына төп гарантияләр турындагы” Закон исә “белем бирү, балалар, техник, фәнни һәм башка басмалар” турында сүз алып бара. “Һәм башкалар” терминын куллану бу очракта ике төрле уйларга урын калдыра.

Закон исә “тайпылучы” массакүләм мәгълүмат чарасы исемлегенә керерлекләр өчен аерым шартлар куя. Ул очракларда атнасына бер тапкырдан да кимрәк таралучы дәүләтнеке, дәүләтнеке булмаган һәм җирле периодик басмаларга, дәүләтнеке булмаган һәм җирле телерадиокомпанияләргә, махсуслашкан телерадиокомпанияләр һәм басмаларга сайлау алды агитациясеннән баш тарту рөхсәт ителә.

Әгәр бу редакцияләр сайлау комиссиясенә эфир вакыты яки басма мәйдан өчен түләү күләмен һәм шартларын күрсәткән документ тапшырмасалар, алар баш тарткан булып хисаплана.

Өченче төркемне *“ангажемент алган” массакүләм мәгълүмат чаралары* тәшкил итә. Болар – кандидатларның яки партияләренең үзләре гамәлгә куйган басмалары. Бу очракта периодик басмалар турында гына сөйләргә туры килә, чөнки кандидат телерадиопрограмма яки телерадиокомпания ача икән, алар “ангажемент алган” массакүләм мәгълүмат чаралары исемлегенә керә алмый.

“Ангажемент алган” басмалардан беркем дә башка кандидатларга түләүле мәйдан тәкъдим иттертә алмый.

Дүртенче категория *“түләүле” массакүләм мәгълүмат чараларын* үз эченә ала. Алар алда санап кителгән төркемнәрнең берсенә дә карамый. Мондый массакүләм мәгълүмат чаралары теркәлгән кандидатларга килешү нигезендә түләүле эфир вакыты яки басма мәйдан бирә ала. Әлеге хокукка ия булыр өчен әлеге дәүләтнеке

булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүмати хезмәтләр һәм аларның күләме өчен бәяләрне алдан ук бастырып чыгарырга һәм әзерлекләрен Үзәк яки төбәк сайлау комиссиясенә игълан итеп куярга тиешләр.

***Сайлау алды агитациясе һәм журналистлар.*** *Сайлау алды агитациясе* ул сайлаучыларны сайлауда катнашырга һәм теркәлгән кандидатлар яклы яки аларга каршы булып тавыш бирергә чакыру, өндәү, этәрү максаты белән башкарылган эшчәнлек. Ул кандидатның теркәлгән көненнән башлана һәм сайлауга нәкъ бер тәүлек кала төнге сәгать 12 гә кадәр дәвам итә. Сайлау көнен билгеләүдән алып кандидатны теркәүгә кадәр булган арада агитация белән шөгыльләнергә ярамый. Болай эшләү кандидатны теркәүгә каршы килү өчен нигез булып торырга мөмкин.

Дәүләт һәм җирле органнарда вазыйфа биләүче кандидатлар агитацияне төп эшләреннән бушаган вакытта гына үткәрә ала. Эш буенча командировкаларга барганда сайлау алды агитациясе белән шөгыльләнү тыела. Әмма агитациягә катнашы юк икән, шунда ясаган чыгышларын массакүләм мәгълүмат чаралары аша тарату законны бозу дип бәяләнми.

Журналист яки башка иҗат кешесе, электрон яки басма матбугат хезмәткәре үзе кандидат яки ышанычлысы булып теркәлгән очракта, аңа массакүләм мәгълүмат чаралары аша сайлау кампаниясен яктырту тыела.

Массакүләм мәгълүмат чаралары алдан ук түләүле эфир вакыты яки матбугат мәйданы бирү турында игълан бастырып чыгарырга тиешле. Бу мәгълүматны бастырып чыгармаган һәм эфир вакыты яки басма мәйданны бирергә әзерлеген Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итмәгән массакүләм мәгълүмат чаралары сайлау алды агитациясендә катнаша алмый.

Сайлау алды чаралары турында мәгълүмат бирелгәндә, алар аерым бер блок булып һәм бернинди комментарийларсыз, гадәттә, теле- һәм радиотапшыруларның башында тапшырыла. Әлеге мәгълүмат сайлау фондыннан түләнми. Тик шунысы бар: редакцияләр әлеге блокларны контрольдә тотарга, аерым бер кандидатка өстенлек бирелмәвен тикшереп торырга тиешләр.

Сайлаулар турындагы законнар сайлау алды агитациясен алып бару хокукын кемгә дә булса үз файдасына куллануны тыя.

Беренчедән, агитация барышынды социаль, расаара, милли, дини нәфрәт һәм дошманлык уяту, хакимиятне яулап алырга чакыру, дәүләт төзелеше һәм чикләрен көч кулланып үзгәртүгә чакыру, сугышны пропагандалау тыелган. Монысы массакүләм мәгълүмат чаралары өчен һәрвакытта да үзгәрешсез кала торган мәҗбүри таләп.

Икенчедән, сайлау алды агитациясе чорында теләсә кайсы ММЧда, әгәр кандидатка җавап бирү яки кире кагу мөмкинлеге бирелә алмый икән, аларның намусы, дәрәҗәсе һәм эш репутациясенә зыян сала торган мәгълүматларны тарату тыела. Хәтта бу мәгълүматлар дөрес булган очракларда да.

Дөресен әйткәндә, әлеге таләпләрне үтәү җиңелләрдән түгел. Чөнки баш мөхәррир кулына килеп кергән материалларның законны бозу-бозмавын берничә сәгать эчендә аңлап, аны бастыру яки бастырмау мөмкинлеген хәл итәргә тиеш.

***Сайлау кампаниясе һәм журналист хокуклары.*** Хокуклар турында сүз башлаганда, иң элек журналистның мәгълүмат алу, җыю, тарату һ.б. булган хокукларын искә төшереп китәргә кирәк. Дөрес, сайлаулар системасы кысаларында алар бераз үзгәрә төшә, әмма юкка чыгарылмый һәм кысылмый. “Россия Федерациясе Президентын сайлау турындагы” Закон массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре турында сүз алып бара һәм алар өчен түбәндәге хокукларны беркетә:

сайлау комиссияләре утырышларында, сайлау документлары белән эшләгәндә, шулай ук сайлаучылар биргән тавышларны санаганда шунда булу хокукы;

сайлау көнендә сайлау участогының эш көне башланганнан алып, югарыда торган сайлау комиссиясе тарафыннан тавыш бирүнең нәтиҗәләре турындагы протоколның кабул ителүе турындагы хәбәр алынганчыга кадәр шунда булу хокукы;

сайлау участогындагы хәрби частьтә, ябык административ-территориаль бүленештә, хастаханә, ял йорты, тикшерү яки вакытлыча тоту изоляторында ясалган сайлау комиссиясе бинасына керү мөмкинлеген алу хокукы;

сайлау комиссиясе төзегән барлык протоколлар белән танышу хокукы;

язу хатасы, арифметик ялгышлар китү сәбәпле протокол яңадан төзелгән очракта, бу хакта мәгълүматлы булу хокукы;

танышу максаты белән сайлау комиссияләреннән һәр участок буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен сорап алу хокукы.

***Сайлауларга бәйле рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларының хокукын чикләү очраклары.*** Сайлаулар барышын контрольдә тотарга тиешле орган Үзәк сайлау комиссиясе дип атала. Аның шактый катлаулы һәм башкаларга охшамаган орган булуын билгеләп үтик. Чынлап та, ул ни закон чыгаручы, ни башкарма, ни суд хакимияте структурасына карамый, шул рәвешчә, Россиядәге хакимият тармакларына кермичә, парламент һәм Президент арасындагы мөнәсәбәтләр нигезендә формалаша.

“ММЧ турындагы” Законның берничә маддәсенә 2003 елның 4 июлендә кертелгән үзгәрешләр нәкъ менә сайлауларга кагыла. 16 нчы маддәдә массакүләм мәгълүмат чараларын чыгарудан туктату очраклары турында сүз алып барыла. Әгәр сайлау вакытында гамәлгә кергән суд карары нигезендә радио-, телепрограмма, периодик басманың баш мөхәррире Россия Федерациясенең сайлау һәм референдумнар турындагы законнарын бозган өчен административ җаваплылыкка тартылса һәм шуннан соң да тагын бер мәртәбә шул ук законны бозса, Үзәк яки төбәк сайлау комиссиясе (массакүләм мәгълүмат чаралары шул төбәктә таралу өчен генә теркәлгән булса) аның эшчәнлеген туктатуны сорап, теркәүче органга мөрәҗәгать итә ала. Бу очракта әлеге орган биш тәүлек эчендә шул мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән фактларны тикшерә һәм аның нәтиҗәләре буенча судка мөрәҗәгать итә. Суд карары белән андый очракларда массакүләм мәгълүмат чарасының эшчәнлеге сайлаулар һәм кабат сайлаулар беткәнче туктатылып торыла. Баш мөхәррир тарафыннан җибәрелгән хаталар исә сайлаучыларга мәгълүмат җиткергәндә, сайлау алды агитациясе үткәргәндә закон нормаларын бозуны үз эченә ала.

“ММЧ турындагы” Законның радио- һәм телетапшыруларны саклау турындагы 34 нче маддәсенә дә шул ук вакытта үзгәреш кертелде. Анысы шуннан гыйбарәт: сайлау алды агитациясе булган һәм эфирга чыккан материаллар шул оешмада 12 ай саклана. Сайлау комиссияләре сораган очракта, бу оешмалар аларны әлеге тапшыруларның күчермәләре белән бушлай тәэмин итәргә тиешләр.

### Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. Хакимият органнары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары арасындагы мөнәсәбәтләр турында сөйләгез.

2. Сайлаулар вакытында массакүләм мәгълүмат чаралары һәм журналистлар нинди законнарга таяналар?

3. Сайлау вакытында массакүләм мәгълүмат чараларын классификацияләү.

4. Сайлау алды агитациясен үткәрүнең журналистларга һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бәйле кагыйдәләре нинди?

5. Сайлау алды агитациясе чорында кандидатларга бирелә торган бертигез хокуклар нидән гыйбарәт?

6. Әйтик, Сез даими рәвештә бер зур предприятие һәм аның җитәкчесенең эшчәнлеген яктыртып барасыз, ди. Ул җитәкче Дәүләт Думасына сайлауларда кандидат булып катнаша башласа, Сезнен язмаларыгызның стиле, характеры ниндигә үзгәрәчәк?

### ***Әдәбият***


Законодательство Российской Федерации о средствах массовой информации: Науч. -практ. комм. проф. М.А. Федотова. М., 1999. С. 480–496.

Кравченко Ф.Д. Предвыборная агитация. Вопросы не исчерпаны // ЗиП. 2000. № 1. С. 19–21.

Как СМИ избежать ответственности за содержание распространяемой им предвыборной информации? Комментарий Центра «Право и СМИ» // ЗиП. 2000. № 12. С. 25–29.

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Судебная палата по информационным спорам при Президенте Российской Федерации: 1994–1996. Нормативные акты. Практика. Комментарии / Под ред. А.Б. Венгерова. М., 1997.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.


Эчтәлеккә кире кайтырга!

## *8 нче тема. Журналист һәм авторлык хокукы*

***Авторлык хокукларына бәйле закон.*** Соңгы берничә дистә елда интеллектуаль милеккә бәйле бәхәсләр, нигездә, 1993 елның 9 июлендә кабул ителгән "Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы" федераль Законга нигезләнеп чишелә иде. Әлеге закон 1886 елда ук кабул ителгән әдәби һәм сәнгать әсәрләрен саклау турындагы Берн конвенциясенә нигезләнеп, аңа кушылу максатыннан төзелгән һәм аның белән бәйләнештә торды. Россиядә әлеге закон кабул ителгәннән соң гына безнең ил дә әлеге конвенциянең 1971 елны кабат каралган Париж вариантына кушылып китә алды.

Хәзерге вакытта Россиядә әлеге закон инде көчен югалткан дип санала. Аның урынына гамәлгә Гражданлык кодексының 4 нче өлеше керде. Алга таба авторлык хокукы буенча мәсьәләләр аның буенча хәл ителә. 2006 елның 18 декабрендә кабул ителгән 4 нче өлешнең авторлык хокукына бәйле булган бердәнбер 7 нче бүлеге 2008 елның 1 гыйнварыннан эшли башлады. Интеллектуаль милеккә бәйле закон нормаларын кодификацияләү процессы безнең илдәге гражданлык белән бәйле законнар системасы тарихына һәм тәҗрибәсенә нигезләнгән.

Әлеге закон авторлык, патент алу, товар билгеләре һәм башта төрдәге интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм шәхсиләнү чаралары хокукларына караган милеккә бәйле яки бәйсез, катнашучыларның тигезлеге, иреге, милки мөстәкыйльлегенә нигезләнгән мөнәсәбәтләрне көйли.

1225 нче маддәнең беренче өлешендә үк интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре һәм шәхсиләнү чараларының исемлеге бирелә. Аның ябык булуы, ягъни башка чаралар белән алга таба тулыландырыла алмавы турында әйтеп китәргә кирәк. Бу чаралар, аңлашылганча, ике төркемгә бүленгән: беренчесендә - интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре, икенчесендә - шәхсиләнү чаралары. Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе өчен иң төп шарт – аның авторы булу. Мәсәлән, бу исемлеккә фәнни, әдәби һәм сәнгать әсәрләре, ЭВМ программалары, мәгълүмат базалары, уйлап табулар, файдалы модельләр, җитештерү үрнәкләре, селекция нәтиҗәләре һ.б. керә.  Шәхсиләнү чаралары дигәндә, без кемне дә яки нәрсәне дә булса шәхси яктан аерып күрсәтә торган объектларны күз алдында тотабыз. Болар – фирма атамалары, товар

билгеләре, товарларның килеп чыгышы атамалары, коммерция билгеләре.

Журналист иҗатында матбугатта басылып чыккан материаллар, радио, телевидениедән яңгыраган фонограмма, тапшыру, программалар интеллектуаль хокук объектлары булып тора. Аларны берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

редакциянең штаттагы хезмәткәрләре тудырган материаллар;

штаттан тыш хәбәрчеләр, чит авторлар тудырган материаллар;

фотосурәтләр һәм рәсем, карикатура кебек сынлы сәнгать әсәрләре;

верстка, басманы бизәү өчен кулланылган типография чаралары.

***Интеллектуаль хокук.*** Элеккеге законда кулланылган “интеллектуаль милек хокукы” төшенчәсен яңасындагы “интеллектуаль хокук” алыштыра. Чөнки беренчесендәге “милек” сүзе бу хокукларны милек белән бәйләп куюны күз алдында тота кебек иде, гәрчә аның матди милек белән бернинди уртаклыгы булмаса да. Шуңа да төшенчәнең яңача яңгырашы төгәлрәк, дөреслеккә туры килә, дип әйтә алабыз.

Интеллектуаль хокукка ия булу матди объектка ия булу белән тәңгәл килми, мәсәлән, картинаның интеллектуаль хокукы аның авторында – рәссамда булса да, матди объект, ягъни картина башка кешенең (сатып алган, бүләк ителгән) милке булырга мөмкин. 1227 нче маддәнең 2 нче пункты милки хокук бер кешедән икенчесенә күчкән очракта да, интеллетуаль хокукның күчмәве турында искәртә.

Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсенең авторы була. Бу – әлеге объктны тудырган, аны барлыкка китерү өчен иҗади эшчәнлек алып барган кеше, ягъни физик зат була. Бу очракта интеллектуаль эшчәнлек һәм иҗади эшчәнлек төшенчәләренең тәңгәл килүен күрәбез. Димәк, иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнмәгән, ә бары тик консультация биргән, тормышка ашыру өчен матди яктан ярдәм күрсәткән, эшне оештырган, техник өлешен башкарган, интеллектуаль хезмәт нәтиҗәсенә хокуклар алу һәм нәтиҗәләрне кулланылышка кертү  артыннан йөргән кешеләр бу интеллектуаль хокукка ия була алмый, дигән сүз.

Милеккә бәйле булмаган мондый интеллектуаль хокуклар автор тарафыннан башка кешегә тапшырыла алмый. Бу “ялган авторлар” барлыкка килмәсен өчен шулай эшләнелгән. Гомумән алганда,

авторлык хокукы эшчәнлек нәтиҗәсенә карата чикләнгән (ягъни башка кешенеке була алмый торган) хокук, авторлык хокукы, авторның исемгә хокукы, шулай ук әсәрнең кагылгысызлыгы һәм аны халыкка тарату хокукы берләштерә.

Законның 1258 нче маддәсе автордашлар мәсьәләсен дә карый. Чынлап та, бер әсәрне берничә кешенең уртак хезмәте нәтиҗәсе буларак та карарга мөмкин бит. Әсәр уртак, өлешләргә бүленми торган икән, ул очракта авторларның берсе аның үзе иҗат иткән өлешен генә алып аерым алып куллана алмый.

Берн конвенциясе дә, федераль закон да авторлык хокукы шул әсәр тудырылганнан башланып китә дип саный. Ул авторның бөтен яшәү дәвере буйлап дәвам итә һәм, ул вафат булгач, аннан соң килгән елның 1 гыйнварыннан башлап, тагын 70 ел дәвам итә. Шул вакыт эчендә авторлык хокукына кагылышлы мәсьәләләрне чишү мөмкинлеге бар. Әлеге вакыт узып киткәннән соң, әсәр бөтенхалык кулланылуына күчә, һәм теләсә кем тарафыннан ирекле файдаланырга мөмкин. Әмма Законның 28 нче маддәсе нигезендә, аның авторлыгына, авторы исеменә һәм аның эш дәрәҗәсенә хокук саклана. Бөтенхалык кулланылышына күчә дигәнне түбәндәгечә аңларга кирәк: димәк, теләсә кем, беркемнән дә рөхсәт сорамыйча, ирекле рәвештә аны тарату, күбәйтү кебек эшләр белән шөгыльләнә ала. Әмма бу вакытта сүз әсәрнең милек формасы турында бармый: аңа хәтле картина кемнеке булса, кемдә сакланса, шулай дәвам итәчәк.

Журналист үз әсәрендә фикерен, вакыйгага карата бәясен белдерә ала. Ышануларына каршы килерлек материал әзерләп, үз фамилиясе белән бастыруын таләп итәләр икән, журналистның каршы килү хокукы бар. Моннан кала, редакцияләү вакытында материалының артык үзгәргәнлеге билгеле булса, фамилиясен алып кую хокукы да бар. Журналист әлеге материалны куллануны тыя яки куллануның аерым шартларын билгели ала. Әсәрнең авторы булып бары тик физик зат, ягъни кеше була ала, юридик зат (редакция) автор булып саналмый. Әмма редакция әсәрнең милек буларак хуҗасы булу хокукларына ия.

Бүгенге көндә журналистларның авторлык хокуклары көн саен диярлек бозыла. Мәсәлән, бер газетада басылып чыккан материаллар икенчесендә кулланыла, Интернетка кереп китә. Киресенчә, газета битләрендә Интернет материалларын авторларының хокукларын

бозып куллану очраклары адым саен очрап тора. Һәрбер журналист үз материалларының тагын кайларда аның рөхсәтеннән башка кулланылуын тикшереп тора алмау сәбәпле, чит илләрдә хәзер бер тапкыр бастырылган материалларны кабат кулланырга рөхсәт бирүче авторлык оешмалары барлыкка килде.

***Авторлык хокукы объекты булмый торган материаллар.*** Законның 1259 нчы маддәсендә авторлык хокукы объекты була алмый торган эшчәнлек нәтиҗәләренең исемлеге китерелгән.

Мәсәлән, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафаннан чыгарылган рәсми документлар, шул исәптән законнар, башка норматив актлар, суд карарлары, халыкара оешмаларның рәсми документлары һәм аларның рәсми тәрҗемәләре андый объект булып тора алмый.

Әйе, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга торган һәртөрле законнар, суд карарлары авторлык хокукына ия булмый. Әмма "Суд залыннан" кебек рубрикаларда автор тарафыннан аның фикерләрен, фактка карата үз мөнәсәбәтен белдереп язылган материаллары, әлбәттә, интеллектуаль милек булып хисаплана. Рәсми затларның телдән сөйләгән докладлар һәм чыгышлары да авторлык хокукы объекты булып тора. Аерым бер кешенең аңа булган хокукларын раслау өчен, әлбәттә, ул чыгышларның газетада басылып чыккан, магнитлы тасмага яки компьютер файлы формасында яздырылган булуы шарт. Шул чыгышлардан өземтәләр китергәндә, башка берәү аларны файдалану кагыйдәләрен бозса, чыгышның авторы, бу эш аның намусына һәм дәрәҗәсенә зыян салган дип тапкан очракта, хокукларын яклауны сорап, судка мөрәҗәгать итә ала.

Әлеге таләп флаг, герб, орденнар, акча билгеләре кебек дәүләт символлары һәм билгеләренә, шулай ук аерым муниципаль оешмаларның символ һәм билгеләре өчен дә урнаштырылган. Халык авыз иҗаты әсәрләренең авторлык хокукы объекты була алмавы да аңлашыла.

Массакүләм мәгълүмат чараларында көн саен күпләп көн яңалыклары да бирелеп барыла. Алар газетада басылган башка материаллар рәтендә хисаплана алмый, оригинальлекләре белән аерылып тормый, фактларны анализлау, сурәтләү өчен иҗади көч тә түгелми диярлек, аларда автор фикерләре дә чагылыш тапмый. Андый

яңалыкларның төп максаты көн буена булган хәбәрләрне халыкка җиткерүдән гыйбарәт.

Дөрес, кайчакта яңалыклар җыю өчен аналитик материал язар өченгә караганда күбрәк вакыт та китәргә мөмкин. Шуңа да карамастан, көн яңалыклары интеллектуаль милек дип саналмый. Бу хакта Берн конвенциясенең 2 нче маддәсенең 8 нче өлешендә сүз алып барыла.

***Эргәдәш хокуклар.*** Журналистка күп очракта эргәдәш хокуклар белән очрашырга туры килә. Эргәдәш хокуклар – алар интеллектуаль эшчәнлекнең берничә нәтиҗәгә китергән катлаулы объектларга бәйле хокуклары. Бу объектлар исемлегенә аудиовизуаль әсәрләр, шул исәптән кинофильмнар, театр тамашалары, мультимедиа проектлары һәм бердәм технологияләр керә. Мультимедиа проектлары дигәндә, без газета-журналлар, радио яки телетапшырулар истә тотылганны аңлыйбыз. Әлеге хокуклар гамәлгә керсен өчен, бу объектның оештыручысы булу законда төп таләп итеп күрсәтелгән. Оештыручы булып физик зат та, юридик зат та тора ала. Закон әлеге затның интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен файдалану, куллану хокукына ия булуын күрсәтә.

***Аерым материалларга карата авторлык хокукы.*** Интервью биргән кешенең шул интервьюга хокукы бармы? Бу сорауга закон да, конвенция дә төгәл генә җавап бирми. Әмма хокук белгечләре бу очракта интервью бирүче һәм алучы - автордашлар, алар икесе дә интервьюның авторлары була дип саный. Шул сәбәпле интервьюны аны биргән кешенең ризалыгыннан башка таратырга ярамый.

Аерым очракларда бу интервьюны дөньяга тудыруда кемнең роле зуррак, хезмәте күбрәк керүе истә тотылырга тиеш. Мисал өчен, журналист үз инициативасы белән әңгәмә корып, коры җавапларны бөртекләп җыеп, мөстәкыйль рәвештә текст барлыкка китерсә, әлеге интервью журналистныкы дип саналырга хаклы. Җаваплар хәбәри характерда, бертөсле генә булган очракта да интервью бирүче автор булып саналмый. Әмма кайчакта танылган кешеләр еш кына газеталарга әзер текст алып килә. Журналист ул текстны интервью итеп үзгәртеп язып биргән очракта, аның бу интервьюга бер хокукы да юк, ул бу очракта бары тик редакторлаучы гына булып тора.

Элегрәк фотосурәтләргә карата аларны әзерләү техник хезмәттән генә гыйбарәт, шулай булгач, аларга карата авторлык хокуклары

таралмый, дип санаучылар күп булган. Әмма соңгы вакытта сурәтләрнең фотохәбәрченең шәхси иҗади хезмәт нәтиҗәсе итеп карау гамәлгә керде. Тик оригиналь, сәнгать әсәре булып торырлык фотолардан көндәлек, хәтердә дә калмый торган фотоларны ничек аерырга соң? Мөстәкыйль әсәр сыйфатында файдаланыла алырлык материал авторлык хокукы объекты була ала. Димәк, редакция берәр кеше төшереп, ясап җибәргән фотоны бастырып чыгарган икән, бу аны мөстәкыйль материал итеп кабул итү турында сөйли. Шулай булгач, әлеге фотосурәт тә авторлык хокукына ия, дигән сүз.

Редакциягә килеп тора торган хатлар – мәгълүмат керүнең бер юлы. Хат авторы үз исемен күрсәтмәүләрен таләп итеп куя ала. Бу мәгълүмат чыганагын сер итеп саклау буларак та, авторның үз әсәрен псевдоним белән яки исемсез тәкдим итү хокукыннан файдалану, дип тә кабул итәргә мөмкин.

Авторның редакциягә хат җибәрүе аны бастыруга ризалык белдерүе, дип хисаплана. "ММЧ турындагы" Законның 42 нче маддәсе белән аларны редакцияләү дә автор рөхсәтен таләп итми, бердәнбер шарт – хатның төп фикере, төп эчтәлеге үзгәрмәскә тиеш.

Редакциягә килеп кергән материаллар ике төркемдә хисаплана, дидек: автор әсәрләре һәм хатлар. "ММЧ турындагы" Закон авторлык хокукы шуларның беренчеләренә генә кагыла, дип саный. Редакциянең хатларга җавап бирмәү, андагы проблемаларны тикшертү максатыннан тиешле органнарга юлламау хокукы бар.

## Семинар дәрес өчен сораулар һәм биремнәр

1. Россиядә авторлык хокукына бәйле мәсьәләләр нинди закон тарафаннан контрольдә тотыла?
2. Интеллектуаль хокук нәрсә ул?
3. Интеллектуаль хокук объекты турында сөйләгез.
4. Көн яңалыклары, законнар, суд карарлары ни өчен интеллектуаль милек булмый торган материаллар дип санала?
5. Эргәдәш хокуклар нәрсә ул?

6. Интервьюга, фотосурәтләргә карата авторлык хокукларына кем ия дип санысыз? Мисаллар китерегез.
7. Редакциягә килгән хатлар белән эшләүнең хокукый үзенчәлекләре нәрсәдән гыйбарәт?

***Әдәбият***


Воронкова М.А. Гаврилов Э.П. Охрана авторских прав в СССР. М, 1974.

Гражданский Кодекс РФ (Часть 4) от 18.12.2006 N 230-ФЗ (принят ГД ФС РФ 24.11.2006) // http://www1.fips.ru/wps/wcm/connect/content_ru/ru/documents/russian_laws/codeks_rf/gkrf_ch4

Комментарий к Гражданскому кодексу Российской Федерации (учебно-практический). Части 1, 2, 3, 4 / под ред. Степанова С.А. – М.: Проспект, Институт частного права, 2009 г.

Липцик Д. Авторское право и смежные права = Droit d'auteur et droit voisins. — Пер. с фр.; Предисл. М.А. Федотова. — М.: Ладомир; Изд-во ЮНЕСКО, 2002.

Моргунова Е.А. Авторское право: учебное пособие / Е.А. Моргунова; отв. ред. В.П. Мозолин. — М.: Норма, 2008.

Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики - 2-е изд., испр. и доп. - М.: Изд-во ВК, 2008.

Федеральный закон “О средствах массовой информации” // Сборник законов РФ.

Федотов М.А. Правовые основы журналистики / М.А.Федотов. – М: Владос, 2002.


Эчтәлеккә кире кайтырга!

## IV бүлек. Мөстәкыйль эш формалары

### *Реферат темалары*

“Ирек” төшенчәсен мин ничек аңлыйм.

Матбугат иреге кеше хокукларын саклыймы?

Массакүләм мәгълүмат чараларының җәмгыятьтә тоткан хокукый урыны.

Россия Федерациясенең “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” законының төп положениеләре.

Мәгълүмат – хокукара мөнәсәбәтләр объекты.

Мәгълүмат җитештерү һәм аннан файдалануның төп хокукый шартлары нидән гыйбарәт?

Дәүләт серенең (яки хезмәт сере, тикшерү сере һәм суд сере, коммерция сере, һөнәри сер, дин тоту сере, гаилә серенең) журналист язмасында тоткан урыны.

ММЧ эшчәнлеген билгеләүче редакция уставы шундый булырга тиеш...

Аудио яки видеоязманы теләсә кайсы очракта да әзерләргә ярыймы?

Журналистның мәгълүмат җыярга, эшкәртергә һәм таратырга хокукы бар!

Шәхес намусын, абруен саклау – журналистның бурычы.

Массакүләм мәгълүмат чаралары сайлаулар вакытында да сатылмасын!

Журналистикада милләтара килешүчәнлек һәм ызгышлар мәсьәләсе.

Уңай этник мәгълүмат җиткерүче массакүләм мәгълүмат чаралары.

Этник мәгълүматны килешүчән яки ызгышлы итү ысуллары.

Массакүләм мәгълүмат чараларындагы рекламга куела торган таләпләр.

Авторлык хокукы һәм плагиат.

Россиядә “Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы” законның бәхәсле урыннары.

## *Массакүләм мәгълүмат чараларына кагылышлы законнардан өземтәләр*

### *Россия Федерациясе Конституциясеннән*

*(1993 нче елның 12 декабрендә кабул ителгән)*

(...)

23 нче маддә.

1. Һәркемнең шәхси тормышының кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, намусын һәм матур исемен яклау хокукы бар.

2. Һәркемнең хат алышу, телефоннан сөйләшү, почта, телеграф яки башка төр хәбәрләшү серенә хокукы бар. Бу хокукны бары тик суд карары белән генә чикләү рөхсәт ителә.

24 нче маддә.

1. Кешенең шәхси тормышы турындагы мәгълүматны аның рөхсәтеннән башка җыю, саклау, куллану һәм тарату тыела.

2. Закон белән билгеләнгән очраклардан кала, дәүләт хакимияте һәм җирле хакимият органнары, шулардагы вазыйфа башкаручы затлар һәркемгә дә турыдан-туры аның хокукларына һәм ирегенә кагылышлы документлар белән танышу мөмкинлеге тудырырга тиешләр.

(...)

29 нчы маддә.

1. Һәркемгә дә фикер һәм сүз иреге тәэмин ителә.

2. Социаль, расара, милли яки дини нәфрәт һәм дошманлык уятырлык пропаганда яки агитациягә юл куелмый. Аерым бер социаль, раса, милли, дини һәм тел ягыннан өстенлекне пропагандалау тыела.

3. Беркем дә үз фикерләрен һәм ышануларын белдерергә яки алардан баш тартырга мәҗбүр ителә алмый.

4. Һәркемнең дә теләсә кайсы законлы юл белән ирекле рәвештә мәгълүмат эзләү, табу, тапшыру, җитештерү һәм тарату хокукы бар. Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүмат исемлеге федераль закон белән ачыклана.

5. Массакүләм мәгълүмат ирекле. Цензура тыела.

***Россия Федерациясенең Гражданлык кодексыннан***
*(Дәүләт Думасы тарафыннан 1994 елның 21 октябрендә кабул ителгән)*

(...)

152 нче маддә. Намус, дәрәҗә һәм эш репутациясен яклау

1. Әгәр андый мәгълүматны тараткан кеше аларның чынбарлыкка туры килүен дәлилли алмаса, граждан суд аркылы аның намусына, дәрәҗәсенә яки эш репутациясенә зыян салган мәгълүматны кире кагуны сорап судка мөрәҗәгать итә ала.

(...)

2. Әгәр гражданның намусына, дәрәҗәсенә яки эш репутациясенә зыян салган мәгълүматлар массакүләм мәгълүмат чараларында таратылган булса, алар шул ук массакүләм мәгълүмат чараларында кире кагылырга тиеш.

Әгәр күрсәтелгән мәгълүматлар оешмадан килгән документта булсалар, ул документ алмаштырылырга яки кире кайтарылып алынырга тиеш.

(...)

4. Суд карары үтәлмәгән булса, суд закон бозучыга процессуаль законнарда күрсәтелгән күләмдә һәм тәртиптә Россия Федерациясе керемено алына торган штраф сала ала. Штраф түләү закон бозучыны суд карары белән билгеләнгән эшне үтәүдән азат итми.

5. Намусына, дәрәҗәсенә яки эш репутациясенә зыян салган мәгълүмат таратылган граждан, кире кагу белән беррәттән, аларны таратудан килгән чыгымнарны һәм әхлакый зыянны түләүне таләп итәргә хаклы.

6. Әгәр гражданның намусына, дәрәҗәсенә яки эш репутациясенә зыян салган мәгълүматны тараткан затның кем икәнлеген ачыклау мөмкин булмаса, аның турында мондый мәгълүматлар таратылган зат, таратылган мәгълүматларның чынбарлыкка туры килмәвен тануны сорап, судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

***Россия Федерациясе Җинаять кодексыннан***
*(1996 елның 13 июнендә кабул ителгән,*
*2003 елның 8 декабрендә ясалган редакциядә)*

Махсус өлеш

(...)

17 нче бүлек. Шәхеснең ирегенә, намусына һәм дәрәҗәсенә карата эшләнгән җинаятьләр

129 нчы маддә. Гайбәт

1. Гайбәт, ягъни башка кешенең намусына һәм дәрәҗәсенә зыян салучы яки репутациясен бозучы ялган мәгълүматлар тарату -

сиксән мең сумга кадәр күләмдәге яки алты айга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка төрле кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә йөз егермедән йөз сиксән сәгатькә кадәрле мәҗбүри эш, яисә бер елга төзәтү эшләре белән җәзага тартыла.

2. Халык алдында ясалган чыгыштагы, халыкка күрсәтелгән әсәрдәге яки массакүләм мәгълүмат чараларындагы гайбәт -

йөз егерме мең сумга кадәрге яки бер елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә йөз сиксәннән ике йөз сәгатькә кадәрге мәҗбүри эш, яисә бер елдан ике елга кадәрге төзәтү эшләре, яисә өч айдан алты айга кадәрге иректән мәхрүм итү җәзасына тартыла.

(...)

130 нче маддә. Кимсетү

1. Кимсетү, ягъни башка затның намусын һәм дәрәҗәсен әдәпсез рәвештә түбәнсетү -

кырык мең сум яки өч айга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгән кешенең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка, яисә йөз егерме сәгатьлек мәҗбүри эш, яки алты айлык төзәтү эшләре белән җавапка тартыла.

Халык алдында ясалган чыгыштагы, халыкка күрсәтелгән әсәрдәге яки массакүләм мәгълүмат чараларындагы кимсетү -

йөз сиксән мең сумга кадәрге яки алты айга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге

штрафка тартыла, яисә йөз сиксән сәгатькә кадәрге мәҗбүри эш, яисә бер елга кадәрге төзәтү эшләре белән җавапка тартыла.

(...)

19 нчы бүлек. Кеше һәм гражданның конституцион хокуклары һәм ирекләренә каршы җинаятьләр

137 нче маддә. Шәхси тормышның кагылгысызлыгын бозу

1. Затның шәхси һәм гаилә серен тәшкил иткән шәхси тормышы турындагы мәгълүматларны законсыз рәвештә үзенең ризалыгыннан башка җыю яки бу мәгълүматларны халык алдында ясалган чыгышта, халыкка күрсәтелгән әсәрдә яки массакүләм мәгълүмат чараларындагы тарату -

ике йөз мең сумга кадәрге яки унсигез айга кадәр иреgennән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә йөз егермедән йөз сиксән сәгатькә кадәрге мәҗбүри эш, яисә бер елга кадәрге төзәтү эшләре, яисә дүрт айга кадәр ирегеннән мәхрүм итү җәзасына тартыла.

2. Хезмәт урыныннан файдалану белән башкарылган шул ук эшләр -

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәрге яки бер елдан ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә ике елдан биш елга кадәр аерым хезмәт урыннарында эшли алмау яки аерым эш белән шөгыльләнә алмау, яисә дүрттән алты айга кадәр ирегеннән мәхрүм итү белән җавапка тартыла.

(…)

140 нчы маддә. Гражданга мәгълүмат бирүдән баш тарту

Аерым хезмәт урынын биләүче затның гражданның хокуклары һәм ирегенә катнашы булган, урнаштырылган тәртиптә җыелган документлар һәм материалларны хаксыз рәвештә бирүдән баш тарту, яисә гражданга тулы булмаган яки күрәләтә ялган мәгълүмат бирү, әгәр бу эшләр гражданнарның хокуклары һәм законлы интересларына зыян китергән булса -

ике йөз мең сумга кадәрге яки унсигез айга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә ике елдан биш елга кадәр аерым хезмәт

урыннарында эшли алмау яки аерым эш белән шөгыльләнә алмау белән җавапка тартыла.

(…)

144 нче маддә. Журналистларның законлы һөнәри эшчәнлегенә комачау итү

1. Журналистларның законлы һөнәри эшчәнлегенә аларны мәгълүмат таратуга мәҗбүр итү яки таратуга каршы килү юлы белән комачау итү -

йөз сиксән мең сумга кадәрге яки алты айга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яки йөз сиксән сәгатькә кадәрге мәҗбүри эш, яки бер елга кадәрге төзәтү эшләре белән җаваплылыкка тартыла.

2. Хезмәт урыныннан файдалану белән башкарылган шул ук эшләр -

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәрге яки бер елдан ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә ике елга кадәрге төзәтү эшләре, яисәдан өч елга кадәр аерым хезмәт урыннарында эшли алмау яки аерым эш белән шөгыльләнә алмау белән бергә яки аннан башка гына ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү белән җавапка тартыла.

(…)

25 нче бүлек. Халык сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлакка каршы җинаятьләр

242 нче маддә. Порнографик материаллар һәм предметларны законсыз рәвештә тарату

Порнографик материаллар яки предметларны тарату яки рекламалау максаты белән законсыз рәвештә җитештерү, тарату, рекламалау, шулай ук порнографик характердагы сурәтләре булган басмаларны, кино- яки видеоматериалларны яки башка предметларны законсыз рәвештә сату -

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр яки бер елдан ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү җәзасына тартыла.

(…)

31 нче бүлек. Дөреслек урнаштыруга каршы җинаятьләр

297 нче маддә. Судны хөрмәт итмәү

1. Суд тикшерүендә катнашучыларны кимсетү юлы белән белдерелгән судны хөрмәт итмәү -

сиксән мең сумга кадәрге яки алты айга кадәр ирегеннән мәхрүм ителгәннең хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штрафка тартыла, яисә йөз сиксәннән ике йөз сәгатькә кадәрге мәҗбүри эш, яисә ике айдан дүрт айга кадәр ирегеннән мәхрүм итү җәзасына тартыла.

(…)

***Россия Федерациясенең "Массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы" Законынан***

*(1991 елның 27 декабрендә кабул ителгән, 1995 елның 13 гыйнвары, 6 июне, 19 июле, 27 декабрендә, 1998 елның 2 мартында, 2000 елның 5 августында, 2001 елның 4 августында, 2002 елның 21 мартында, 25 июлендә, 2003 елның 8 декабрендә, 2004 елның 22 августында, 2005 елның 21 июлендә, 2006 елның 16 октябрендә, 2008 елның 25 декабрендә һәм 2009 елның 9 февралендә кертелгән үзгәрешләр белән)*

(...)

II бүлек. Массакүләм мәгълүмат чараларын оештыру

10 нчы маддә. Теркәтү турындагы гариза

Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәтүне сорап язылган гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гамәлгә куючы турындагы әлеге Закон таләпләренә туры килерлек мәгълүматлар;

2) массакүләм мәгълүмат чарасының исеме;

3) теле (телләре);

4) редакция адресы;

5) массакүләм мәгълүмат чарасының даими таралу рәвеше;

6) продукциянең күзалланган таралу территориясе;

7) якынча тематикасы һәм (яки) махсуслашуы;

8) чыгарылышның күзалланган даимилеге, массакүләм мәгълүмат чарасының максималь күләме;

9) финанслау чыганаклары;

10) гариза бирүченең башка массакүләм мәгълүмат чараларына карата гамәлгә куючы, милекче, баш мөхәррир (редакция), нәшир яки таратучы булуы турындагы мәгълүматлар.

(...)

13 нче маддә. Теркәүгә каршы килү

Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәүгә каршы килү бары тик түбәндәге очракларда гына мөмкин:

1) гариза, әлеге Законга туры китереп, массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую хокукына ия булмаган граждан, гражданлык җәмгыятьләре, учреждение, предприятие, оешмадан алынса;

2) гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар чынбарлыкка туры килмәсә;

3) массакүләм мәгълүмат чарасының исеме, якынча тематикасы һәм (яки) махсуслашуы, әлеге Законның 4 нче маддәсенең беренче өлешендә аңлатылганча, массакүләм мәгълүмат ирегеннән явыз рәвештә файдаланудан гыйбарәт булса;

4) теркәүче орган тарафыннан алдарак шул ук исемдәге һәм массакүләм мәгълүматны тарату рәвешендәге башка массакүләм мәгълүмат чарасы теркәлгән булса.

(...)

15 нче маддә. Теркәү турындагы белешмәне дөрес түгел дип тану

Теркәүче орган гаризасы буенча гражданлык суд эше тәртибендә каралып, теркәү турындагы белешмә дөрес түгел дип түбәндәге очракларда гына танылырга мөмкин:

1) теркәү турындагы белешмә ялган юл белән алынган булса;

2) массакүләм мәгълүмат чарасы бер елдан артык вакыт дөньяга (эфирга) чыкмый торса;

3) әлеге массакүләм мәгълүмат чарасының дөньяга (эфирга) чыгуыннан алып өч ай эчендә редакциянең уставы яки аны алыштыручы килешү кабул ителмәгән һәм (яки) расланмаган икән;

4) әлеге массакүләм мәгълүмат чарасын кабат теркәү очрагы булганда.

Теркәү турындагы белешмә дөрес түгел дип танылган очракта, теркәү салымы кире кайтарып бирелми

16 нчы маддә. Эшчәнлекне туктату һәм туктатып тору

Массакүләм мәгълүмат чараларының эшчәнлеге гамәлгә куючы карары буенча яисә теркәүче орган гаризасы буенча суд тарафыннан гражданлык суд эше тәртибендә каралып кына туктатылырга яки туктатылып торылырга мөмкин.

Гамәлгә куючының бары тик редакция уставы яки гамәлгә куючы белән редакция (баш мөхәррир) арасындагы килешүдә күзалланган очракларда һәм тәртиптә генә массакүләм мәгълүмат чарасының эшчәнлеген туктатып тору хокукы бар.

(...)

III бүлек. Массакүләм мәгълүматне тарату

27 нче маддә. Чыгарылыш мәгълүматлары

Даими басмаларның һәрбер чыгарылышында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш:

1) басманың исеме;

2) гамәлгә куючы (гамәлдәшләр);

3) баш мөхәррирнең фамилиясе һәм инициаллары;

4) чыгарылышның тәртип саны һәм дөньяга таралу көне, ә газеталар өчен – шулай ук басылырга кул кую вакыты (график буенча билгеләнгән һәм чынлыкта);

5) элемтә предприятиеләре аша тарала торган басмалар өчен - индекс;

6) тираж;

7) бәясе, яисә "Ирекле бәя", яисә "Бушлай" дигән язулар;

8) редакция, нәшир, типография адресы.

Радио- яки телетапшыру һәрбер чыгарылышында, ә тәүлек буе эшләгәндә дүрттән дә ким итмичә, редакция тапшыруның исемен атап торырга тиеш.

Аудио-, видео- яки кинохроникаль тапшыруларның һәр күчермәсендә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш:

1) тапшыруның исеме;

2) дөньяга (эфирга) таралу вакыты яки чыгарылыш саны;

3) баш мөхәррирнең фамилиясе, инициаллары;

4) тираж;

5) редакция һәм аның адресы;

6) бәясе, яки "Ирекле бәя", яки "Бушлай" дигән язу.

Мәгълүмат агентлыгы хәбәрләре һәм материаллары янында аның исеме күрсәтелергә тиеш. Әгәр массакүләм мәгълүмат чарасы теркәүдән азат ителмәгән икән, чыгарылыш мәгълүматларында шулай ук аны теркәгән орган һәм теркәү саны күрсәтелә.

(...)

37 нче маддә. Эротик басмалар

Эротик характердагы хәбәрләр һәм материаллар буенча махсуслаша торган массакүләм мәгълүмат чарасы дип әлеге Закон өчен тулаем һәм системалы рәвештә секска карата кызыксыну барлыкка китерә торган басма яки тапшыру аңлашыла.

Эротик характердагы махсуслашкан радио- һәм телетапшыруларны сигналны кодлаштырмыйча тарату, җирле хакимият тарафыннан башка таләп булмаса, бары тик җирле вакыт белән 23 сәгатьтән 4 сәгатькә кадәр генә рөхсәт ителә.

Эротик характердагы хәбәрләр һәм материаллар буенча махсуслашкан массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясен ваклап сату бары тик ябыштырылган үтә күренмәле пакетларда һәм җирле хакимият тарафыннан махсус шуның өчен билгеләнеп куелган урыннарда гына сату рөхсәт ителә.

IV бүлек. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән гражданнар һәм оешмалар арасындагы мөнәсәбәтләр

38 нче маддә. Мәгълүмат алу хокукы

Гражданнарның массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы дәүләт органнары һәм оешмалары, иҗтимагый оешмалар, аларда эшләүче кешеләрнең эшчәнлеге турында үз вакытында мәгълүмат алу хокукы бар.

Дәүләт органнары һәм оешмалары, иҗтимагый оешмалар, аларда эшләүче кешеләр үз эшчәнлекләре турындагы мәгълүматларны редакция соравы буенча, шулай ук матбугат конференцияләре уздыру, белешмә һәм статистик материалларын тарату һәм башка формаларда тәкдим итәләр.

39 нчы маддә. Мәгълүмат сорап мөрәҗәгать итү

Редакция дәүләт органнары һәм оешмалары, иҗтимагый оешмалар, аларда эшләүче кешеләр эшчәнлеге турындагы мәгълүматны сорап мөрәҗәгать итә ала. Мәгълүмат сорап мөрәҗәгать итү телдән һәм язма рәвештә була ала. Соралган мәгълүматны күрсәтелгән органнар, оешма һәм берләшмәләрнең җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, матбугат хезмәте хезмәткәрләре яки шуңа хокукы булган башка кешеләр бирә ала.

40 нчы маддә. Мәгълүмат бирүдән баш тарту һәм кичектерү

Мәгълүмат бирүдән баш тарту бары тик ул мәгълүмат эчендә дәүләт, коммерция яки закон белән саклана торган башка серләр булган очракта гына мөмкин. Каршы килү турындагы искәртү редакциягә мәгълүмат соралган язма мөрәҗәгатьне алганнан соң өч көн эчендә тапшырылырга тиеш. Искәртүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) сорала торган мәгълүматның закон белән саклана сорган сердән аерып булмавын аңлаткан сәбәбе;

2) мәгълүматны бирүдән баш тарткан кеше;

3) каршы килү турында карар кабул ителгән дата.

Сорала торган мәгълүматны кичектерү таләп ителгән мәгълүматны җиде көн эчендә бирә алмаган очракта мөмкин. Кичектерү турындагы искәртү редакция вәкиленә мәгълүмат соралган язма мөрәҗәгатьне алганнан соң өч көн эчендә тапшырылырга тиеш. Искәртүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) сорала торган мәгълүматның җиде көн эчендә бирелә алмавын аңлаткан сәбәбе;

2) сорала торган мәгълүмат биреләчәк дата;

3) кичектерүне билгеләгән кеше;

4) кичектерү турында карар кабул ителгән дата.

41 нче маддә. Конфиденциаль мәгълүмат

Редакциянең таратыла морган хәбәрләр һәм материалларында граждан тарафыннан аларны сер итеп саклау шарты белән бирелгән мәгълүматны ачарга хакы юк.

Редакция мәгълүмат чыганагын сер итеп сакларга бурычлы һәм, каралуда булган эшкә бәйле рәвештә суд таләп иткән очрактан кала,

мәгълүматны исемен ачмау шарты белән бирелгән кешенең кем икәнен ачмаска хокуклы.

Редакциянең таратыла торган хәбәрләр һәм материалларда җинаять эшләгән яисә аны эшләүдә шикле дип табылган, шулай ук административ хокук бозган яки җәмгыятьтә булу кагыйдәләрен бозган балигъ булмаган баланың шәхесен турыдан яки читләтеп атаучы мәгълүматларны  балигъ булмаган баланың үзенең яки аның законлы вәкиле рөхсәтеннән башка ачарга хокукы юк.

Редакциянең таратыла торган хәбәрләр һәм материалларда зыян күргән балигъ булмаган баланың шәхесен турыдан яки читләтеп атаучы мәгълүматларны,  балигъ булмаган баланың үзенең яки аның законлы вәкиле рөхсәтеннән башка ачарга хокукы юк.

42 нче маддә. Авторлык әсәрләре һәм хатлар

Редакция кулланыла торган әсәрләргә карата, авторлык, нәширлек,  интеллектуаль милеккә карата башка хокукларны да кертеп, барлык хокукларны да сакларга тиеш. Автор яисә әсәргә карата хокуклары булган башка зат редакциягә тапшырылган әсәрне куллануның аерым шартлары һәм характерын билгели ала.

Редакциягә адресланган хат, төп мәгънәсе бозылмаган һәм әлеге Закон положениеләре үтәлгән очракта, шул массакүләм мәгълүмат чарасының хәбәрләре һәм материалларында кулланыла ала. Редакция гражданнарның хатларына җавап бирмәскә һәм ул хатларны, аларны тикшерү вазыйфасына ия булган органнар, оешмалар һәм шуларда эшләүче затларга җибәрмәскә хокуклы.

Закон белән билгеләнмәгән очракларда, беркемнең дә редакция тарафыннан кире кагылган әсәр, хат, башка хәбәр яки материалны бастыруны таләп итәргә хакы юк.

(...)

V бүлек. Журналистның хокуклары һәм бурычлары

47 нче маддә. Журналист хокуклары

Журналистның түбәндәгеләргә хокукы бар:

1) мәгълүмат эзләү, сорау, алу һәм тарату;

2) дәүләт органнары һәм оешмалары, предприятие һәм учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар яисә аларның матбугат хезмәтләрендә булу;

3) мәгълүмат сорап мөрәҗәгать итүгә бәйле рәвештә вазыйфа биләүче затлар тарафыннан кабул ителү;

4) дәүләт, коммерция яки закон белән сакланыла торган башка сер булган фрагментларыннан кала, документлар һәм материалларга үтеп керү;

5) әлеге Законның 42 нче маддәсенең беренче өлешендәге шартларны үтәгән очракта документлар һәм материаллардан күчермә ясау, бастырып чыгару, хәбәр итү яки башка ысуллар белән тарату;

6) закон белән тыелган очраклардан кала, аудио- һәм видеотехника кулланып, кино- һәм фотога төшереп, язмалар әзерләү;

7) табигый бәла-казалар, һәлакәтләр һәм катастрофалар, массакүләм тәртипсезлекләр һәм гражданнарның массакүләм җыелган махсус саклана торган урыннарында, шулай ук гадәттән тыш хәл игълан ителгән урынннарда, митинглар һәм демонстрацияләрдә булу;

8) аңа хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерү;

9) аның имзасы белән тарату өчен әзерләнгән хәбәрләр һәм материалларда үзенең шәхси фикерләре һәм бәясен күрсәтү;

10) аның ышануларына каршы килгән хәбәрләр һәм материалларны үз имзасы белән әзерләүдән баш тарту;

11) редакцияләү вакытында, аның фикере буенча, эчтәлеге үзгәртелгән дип тапкан хәбәр яки материал астыннан үзенең имзасын алып кую, яисә тыю яки әлеге хәбәр яки материалны, әлеге Законның 42 нче маддәсенең беренче өлеше нигезендә, таратуның аерым шартлары яки характерын билгеләү;

12) үзе тарафыннан әзерләнгән хәбәрләр һәм материалларны үз имзасы астында, псевдоним белән яки имзасыз тарату.

Журналист шулай ук Россия Федерациясе массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законнар биргән башка хокуклардан да файдалана.

48 нче маддә. Аккредитация

Редакциянең дәүләт органнары, оешма, учреждение, иҗтимагый берлек органнарына үз журналистларын аккредитацияләүне сорап мөрәҗәгать итү хокукы бар.

Дәүләт органнары, оешма, учреждение, иҗтимагый берлек органнары, редакцияләр шул органнар, оешмалар, учреждениеләр

тарафыннан урнаштырылган аккредитация кагыйдәләрен үтәгән очракта, мөрәҗәгать ителгән журналистларны аккредитацияли.

Журналистларны аккредитацияләгән шул органнар, оешмалар, учреждениеләр аларга утырыш, киңәшмә һәм башка чаралар турында алдан ук хәбәр итеп торырга, стенограмма, беркетмә һәм башка документлар белән тәэмин итәргә, язмалар алып бару өчен уңайлы шартлар тудырырга бурычлы.

Аккредитацияләнгән журналистның аккредитацияләгән органнар, оешмалар, учреждениеләр тарафыннан үткәрелә торган утырыш, киңәшмә һәм башка чараларда, яшерен чара итеп үткәрү турында карар кабул ителгән очраклардан кала, катнашу хокукы бар.

Журналист яки редакция тарафыннан урнаштырылган аккредитация кагыйдәләре бозылса яисә, законлы көченә кергән суд карары нигезендә, журналистны аккредитацияләгән оешманың намусы һәм дәрәҗәсен бозарлык дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат таратылган дип табылса, журналистны аккредитациядән мәхрүм итә алалар.

Массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренең үз хәбәрчеләрен аккредитацияләве әлеге маддә нигезендә алып барыла.

49 нчы маддә. Журналистның бурычлары

Журналист түбәндәгеләрне үтәргә бурычлы:

1) хезмәт бәйләнешләрендә торган редакциянең уставын үтәү;

2) аңа хәбәр ителгән мәгълүматның дөреслеген тикшерү;

3) мәгълүмат биргән затларның чыганакны күрсәтү, шулай ук өземтә итеп китерелгән фикернең, беренче тапкыр таратылган очракта, авторын күрсәтү таләбен үтәү;

4) мәгълүмат һәм (яки) аның чыганагының конфиденциальлеген саклау;

5) массакүләм мәгълүмат чараларында гражданның шәхси тормышы турында мәгълүмат тарату өчен (җәмгыять интересларын яклау өчен кирәк булган очраклардан кала) гражданның үзеннән яки аның законлы вәкилләреннән рөхсәт алу;

6) граждан яки вазыйфа башкаручы затлардан мәгълүмат алганда, аудио- һәм видеога яздыру, кино- һәм фотога төшерү турында әйтү;

7) әзерләгән хәбәр яки материалны таратуга бәйле исклар һәм закон таләпләренә туры килгән башка таләпләр булачагы турында баш мөхәррирне кисәтеп кую;

8) әгәр бирем яисә аны башкару закон бозу белән бәйле булган очракта баш мөхәррир яки редакция тарафыннан бирелгән биремне үтәүдән баш тарту;

9) һөнәри эшчәнлек алып барганда беренче таләп белән үк редакция таныклыгын яки шәхесне һәм журналист хокукларын раслаучы башка документны күрсәтү.

Журналистның шулай ук Россия Федерациясе массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законнар куйган башка бурычларны да үтәргә тиешле.

Һөнәри эшчәнлек алып барганда журналист граждан һәм оешмаларның хокуклары, законлы интереслары, намус һәм дәрәҗәсен хөрмәт итәргә хокуклы.

Дәүләт һөнәри эшчәнлек алып баруга бәйле рәвештә журналистка, иҗтимагый бурычын үтәүче зат буларак, аның намусы, дәрәҗәсе, сәламәтлеге, тормышы һәм милеген саклауны гарантияли.

50 нче маддә. Яшерен язмалар әзерләү

Яшерен аудио- һәм видеоязмалар, кино- һәм фотога төшерүләр кулланып әзерләнгән хәбәрләр һәм материалларны тарату түбәндәге очракларда гына рөхсәт ителә:

1) әгәр бу кеше һәм гражданның конституцион хокуклары һәм кеше ирекләрен бозмаса;

2) әгәр бу иҗтимагый ихтыяҗларны яклау өчен кирәк булса, һәм чит кешеләрне танып алуга каршы чаралар күрелгән булса;

3) әгәр язмаларны күрсәтү суд карары нигезендә алып барылса.

(...)

## ***Россия Федерациясенең "Дәүләт сере турындагы" законыннан***

*(1993 елның 21 июлендә кабул ителгән)*

(...)

III бүлек. Мәгълүматларны һәм аларны йөртүчеләрне сергә әйләндерү.

7 нче маддә. Сергә әйләндерергә ярамый торган мәгълүматлар.

Түбәндәге мәгълүматларны сергә әйләндерергә ярамый:

гражданнарның куркынычсызлыгына һәм сәламәтлегенә янаучы гадәттән тыш хәлләр һәм фаҗигаләр һәм аларның нәтиҗәләре, шулай ук бәла-казалар, аларның рәсми фаразлары һәм нәтиҗәләре;

экология, сәламәтлек саклау, санитария, демография, мәгариф, мәдәният, авыл хуҗалыгы, шулай ук җинаятчелекнең торышы;

гражданнарга, вазыйфа биләүче затларга, предприятиеләргә, учреждениеләр һәм оешмаларга дәүләт тарафыннан каралган өстенлекләр, компенсация һәм ташламалар;

кеше һәм гражданның хокукларын һәм иреген бозу турындагы фактлар;

Россия Федерациясенең алтын запасы һәм валюта резервлары турында;

Россия Федерациясенең югарыдагы вазыйфа биләүче затларының сәламәтлегенең торышы турында;

Дәүләт хакимияте һәм аларның вазыйфа биләүче затлары тарафыннан законнарны бозу очраклары турында.

Югарыда санап кителгән мәгълүматларны сергә әйләндерү турында карар кабул иткән яки аларны шул максатларда дәүләт серенә керткән өчен, җәмгыятькә, дәүләт һәм гражданнарга китергән матди һәм әхлакый зыян күләменнән чыгып, җинаять, административ яки дисциплинар җаваплылыкка тартылалар. Гражданнарның андый карарларны судка бирергә хакы бар.

(...)

Эчтәлеккә кире кайтырга!

## *Журналистикага кагылышлы хокукый төшенчәләрнең кыскача аңлатмалы сүзлеге*

*Баш мөхәррир* – редакциянең җитәкчесе, массакүләм мәгълүмат чараларын җитештерү һәм чыгаруга бәйле иң ахыргы сүзне әйтүче кеше.

*Гаепсезлек шарты* - суд карары чыкканчы, кешене гаепле дип игълан итәргә ярамау. Аңарчы журналист ул кеше турында "гаепләнүче", "шикле", "тикшерү астында тотылучы" дип кенә әйтә яки яза ала.

*Гражданлык хәлләрен язып бару актлары сере* – кешеләрнең хокуклары барлыкка килү һәм юкка чыгуга китергән, шулай ук гражданлык халәтен сурәтләүче вакыйгалар (мәсәлән, өйләнешү, гражданлык).

*Гражданлык әйләнешендәге мәгълүмат* - аерым кешеләр турындагы һәм шул кешеләргә генә билгеле булган мәгълүмат.

*Дәүләт сере* – аны куллану Россия Федерациясенең куркынычсызлыгына зыян салырга мөмкин булган, хәрби, тышкы сәясәт, икътисад, разведка, контрразведка, тикшерү өлкәләренә кагылышлы, дәүләт тарафыннан саклана торган мәгълүмат.

*Журналист* - исәпкә алынган массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе өчен хәбәрләр һәм материалларны редакцияләү, язу, җыю яки әзерләү белән шөгыльләнүче, әлеге редакция белән хезмәт килешүе яки башка төр килешүләр белән бәйләнгән, яки ул хезмәтләрне редакция кушуы буенча башкаручы кеше.

*Журналист хокукларын явыз ният белән файдалану* - иҗтимагый әһәмияткә ия мәгълүматларны яшереп калдыру яки уйлап чыгару; имеш-мимешләрне расланган хәбәр итеп тарату; чит кеше яки массакүләм мәгълүмат чарасы булмаган башка оешма өчен мәгълүмат җыю максаты белән куллану.

*Интеллектуаль милек объектлары* - гражданлык хокуклары гамәлгә керә торган объектлар - мәгълүмат һәм әсәрләр (редакциянең штаттагы хезмәткәрләре тудырган материаллар; штаттан тыш хәбәрчеләр, чит авторлар тудырган материаллар; фотосурәт, рәсем, карикатура кебек сынлы сәнгать әсәрләре; верстка, басманы бизәү өчен кулланылган типография чаралары).

*Коммерция сере* - коммерция эшчәнлеге белән бәйле, башка кешеләргә билгеле булмавы аркасында потенциаль коммерция кыйммәтенә ия мәгълүмат.

*Конфиденциаль сер* – аерым шәхеснең хокукларын саклау максатыннан, бар кеше өчен дә ачык булмаган мәгълүматлар.

*Массакүләм мәгълүмат* - чикләнмәгән күләмдәге кешеләр өчен әзерләнеп, кәгазьгә басылган, аудио-, аудиовизуаль яки башка төрле хәбәрләр, материаллар.

*Массакүләм мәгълүмат ireген явыз ният белән файдалану* - массакүләм мәгълүмат чараларын җинаять җаваплылыгына тартылырлык эшләр өчен, наркотик чаралар, психотроп матдәләрне пропагандалау максатында куллану һәм массакүләм мәгълүмат чараларында халык аңына тәэсир итәрлек яшерен вставкалар кертү.

*Массакүләм мәгълүмат чаралары* - басма, радио-, теле-, видеопрограмма, кинохроника, массакүләм мәгълүмат таратучы башка чаралар.

*Массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясе* - журналистлар һәм техник хезмәткәрләрнең уртак хезмәте белән аерым бер тираж белән дөньяга таралган периодик басма, эфирга чыккан радио-, телетапшыру.

*Массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен тарату* - массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен сату, абүнәчеләргә яздыртып, почта яки башка хезмәтләр аркылы китертү, заказ буенча китереп бирү, өләшү.

*Мәгълүмати экология бозылу* - социаль, раса, милләт, динара нәфрәт һәм низаглар китереп чыгарырга сәләтле мәгълүмат; сугышка чакыру; нәфрәт, дошманлык, башкалардан өстенлекне пропагандалаучы мәгълүмат; порнография; кешеләрнең намусын, исемен, репутациясен зыян салучы; намуссыз, тикшерелмәгән, әхлаксыз, күрә торып ялган мәгълүмат, яшерен реклама; психикага тәэсир ясаучан мәгълүмат; дәүләт һәм конфиденциаль серләрне таратучы; сайлау алды агитациясе кагыйдәләрен бозучы һ.б. мәгълүматлар җитештерү, тарату.

*Өземтәләр* - аерым кагыйдәләргә туры китереп (авторы һәм кайдан алынганлыгын күрсәтеп, фәнни, тикшеренү, полемик, тәнкыйди һәм мәгълүмати максатларда гына, күләме өземтә китерүнең

максаты белән ярашкан шартларда), башка авторларның әсәрләреннән кулланылган өзекләр.

*Даими басма* - даими исеме, саннарының тәртип номеры булган һәм елына бер тапкыр булса да дөнья күрүче газета, журнал, альманах, бюллетень яки шундый башка чара.

*Радио-, теле-, кинохроникаль программа* - елына бер мәртәбә булса да эфирга чыгучы, даими исеме булган периодик аудио-, аудиовизуаль хәбәрләр, материаллар.

*Редакция* – массакүләм мәгълүмат чараларын җитештерә һәм чыгара торган оешма, учреждение, предприятие, бер кеше яки берничә кеше төркеме.

*Сайлау алды агитациясе* - сайлаучыларны сайлауда катнашырга һәм теркәлгән кандидатлар яклы яки аларга каршы булып тавыш бирергә этәрү максаты белән башкарылган эшчәнлек.

*Сайлаулар вакытында массакүләм мәгълүмат чараларын классификацияләү –*

*1) "вазыйфа йөкләтелгән" массакүләм мәгълүмат чаралары* - гамәлгә куючылары дәүләт органнары, оешмалары һәм учреждениеләре булганнар, сайлауларга хәтле бер ел эчендә барлык тоткан акчаларының 15 процентган да ким булмаган өлешен дәүләт хакимияте яки җирле үзидарә органнары бүлеп бирелгәннәр.

*2) "тайпылучы" массакүләм мәгълүмат чаралары* – сәяси темага катнашмаучы, дәүләтнеке яки аныкы булмаган махсуслашкан массакүләм мәгълүмат чаралары.

*3) "ангажемент алган" массакүләм мәгълүмат чаралары* – кандидатларның яки партияләренең үзләре гамәлгә куйган басмалары.

*4) "түләүле" массакүләм мәгълүмат чараларын* – алдагы төркемнәрнең берсенә дә туры килмәүче массакүләм мәгълүмат чаралары.

*Хезмәт сере* – федераль законнар һәм Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы нигезендә дәүләт органнары тарафыннан тыю салынган серләр.

*Халыкка билгеле тормыш турындагы мәгълүмат* - мәгълүмат субъектының бар халык өчен дә ачык җәмәгать урынында булуы, игътибарны үзенә тарту максатыннан халыкка файда китерә торган яки зыян сала торган эшләр башкаруы турындагы мәгълүмат.

*Шәхси мәгълүматлар* – аерым бер кешенең шәхси тормышында урын алган фактлар, вакыйгалар, очраклар турындагы мәгълүматлар.

*Ябык мәгълүмат* - дәүләткә яки аерым кешеләргә зыян килмәсен өчен, бар кешегә дә ачык булмаган мәгълүмат. Әйтик, дәүләт сере, коммерция сере, суд сере һ.б..

*Һәркемгә дә ачык мәгълүмат* - теләсә кайсы кешегә бернинди тыюларсыз барып ирешергә тиешле мәгълүмат.

*Һөнәри сер* – аерым бер һөнәргә караган кешеләрнең бар кеше өчен дә ачык була алмый торган мәгълүматлары.

Эчтәлеккә кире кайтырга!

***“Журналистиканың хокукый нигезләре” фәненнән***

***белемнәрне тикшерү өчен үрнәк тест сораулары***

**Тест №1**

**Тема** - Россиядә массакүләм мәгълүмат хокукының барлыкка килүе һәм үсеше

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Беренче рәсми хокукый нормалар Россиядә нинди матбугат чарасы белән бергә барлыкка килгән?

**Җавап вариантлары.**

1. "Вести-Куранты" газетасы
2. "Ведомости" газетасы
3. "Правда" газетасы
4. "Русское слово" журналы

**Тест №2**

**Тема** - Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм реклама

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Рекламада түбәндәгеләрдән кайсысын куллану рөхсәт ителми?

**Җавап вариантлары.**

1. Артистларның образлары
2. Сыра шешәсе
3. Җырлар
4. Сыра эчү процессы

**Тест №3**

**Тема** - Массакүләм мәгълүмат җитештерүчеләр арасындагы хокукый мөнәсәбәтләр

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Әгәр гамәлгә куючы материалларны бастырыр алдыннан үзе белән килештерүне таләп итә икән, бу эш ничек дип бәяләнәчәк?

**Җавап вариантлары.**

1. Һөнәри этика кагыйдәләрен үтәмәү
2. Гадәти хәл
3. Закон таләпләрен бозу

**Тест №4**

**Тема** - Журналист һәм адитория арасындагы бәхәсләр

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Массакүләм мәгълүмат чарасында намусы, дәрәҗәсе, репутациясе кимсетелгән дип санаган кеше беренче чиратта кая мөрәҗәгать итәргә тиеш?

**Җавап вариантлары.**

1. Судка
2. Шул массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә
3. Теләсә кайсы массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә
4. Эчке эшләр министрлыгына

**Тест №5**

**Тема** - Журналист һәм адитория арасындагы бәхәсләр

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Кеше хокуклары буенча Европа суды гаилә сере дигәнгә түбәндәгеләрдән кайсылары турында мәгълүматларны кертә?

**Җавап вариантлары.**

1. Законсыз туган балалар
2. Гаилә сатып алган машина
3. Әти-әнинең һөнәре
4. Әти-әнинең эшенә бәйле серләр

**Тест №6**

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Сайлауларга кагылышлы законнар арасында Россиядә кайсы закон юк?

**Җавап вариантлары.**

1. “Россия Федерациясе Президентын сайлау турындагы” Закон
2. “Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына депутатлар сайлау турындагы” Закон
3. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнаша алуына төп гарантияләр турындагы” Закон
4. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары турындагы” Закон

## Тест №7

**Тема** - Журналист һәм авторлык хокукы

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Россиядәге авторлык хокукына бәйле закон ничек атала?

**Җавап вариантлары.**

1. "Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы" РФ Законы
2. "Авторлык хокукы турындагы" РФ Законы
3. "Интеллектуаль милек турындагы" РФ Законы
4. "Патент хокукы турындагы" РФ Законы
5. Гражданлык кодексының 4 нче өлеше

## Тест №8

**Тема** - Журналист һәм авторлык хокукы

**Авырлык дәрәҗәсе** - уртача

**Тип** – бер вариант

**Сорау**. Әдәби һәм сәнгать әсәрләрен саклау турындагы Берн конвенциясенә Россия кайсы елдан кушылды?

**Җавап вариантлары.**

1. 1925
2. 1945
3. 1975
4. 1995

Эчтәлеккә кире кайтырга!